14. В день голосования до наступления времени голосования неиспользованные открепительные удостоверения погашаются. Сведения о погашении неиспользованных открепительных удостоверений с указанием их числа, а также номеров открепительных удостоверений вносятся соответствующей комиссией в акт, составленный по форме, утвержденной Центральной избирательной комиссией Российской Федерации.

15. По предъявлении открепительного удостоверения в день голосования участник голосования по отзыву дополнительно включается в список участников голосования по отзыву на том участке для голосования по отзыву, на котором он будет находиться в день голосования. Участковой комиссией в соответствующей графе списка участников голосования по отзыву делается отметка: «Проголосовал по открепительному удостоверению №» с указанием номера открепительного удостоверения, предъявленного участником голосования по отзыву. После этого открепительное удостоверение изымается у участника голосования по отзыву. Открепи-

тельные удостоверения, на основании которых участники голосования по отзыву включены в список участников голосования по отзыву, хранятся вместе с указанным списком.

16. В случае утраты бланка открепительного удостоверения комиссия, установившая факт такой утраты, незамедлительно составляет соответствующий акт и принимает решение, в котором указываются номер утраченного бланка открепительного удостоверения, факт утраты бланка и причина утраты. Это решение в тот же день доводится до сведения непосредственно вышестоящей комиссии и Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан. На основании этого решения Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан признает соответствующее открепительное удостоверение недействительным, о чем незамедлительно информируются все нижестоящие комиссии. Открепительные удостоверения также могут признаваться недействительными Центральной избирательной комиссией Республики Татарстан в иных случаях, если голосование по таким открепительным удостоверениям повлечет нарушение права граждан на участие в голосовании по отзыву. Недействительное открепительное удостоверение не является основанием для включения участника голосования по отзыву в список участников голосования по отзыву. При предъявлении участником голосования по отзыву такого открепительного удостоверения оно подлежит изъятию.

17. В соответствии с Федеральным законом «Об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации» порядок передачи открепительных удостоверений комиссиям и учета открепительных удостоверений, в том числе с использованием ГАС «Выборы», утверждается Центральной избирательной комиссией Российской Федерации.»;

19) часть 4 статьи 45 дополнить предложением следующего содержания: «В случае использования прозрачных ящиков для голосования форма бюллетеня устанавливается с учетом необходимости защиты тайны голосования, за исключением случая, если по решению Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан в этих целях используются конверты.»;

20) в статье 46:

а) часть 1 после слов «место жительства» дополнить словами «(место пребывания)», дополнить предложением следующего содержания: «Лицам, указанным в части 3 статьи 22 настоящего Закона, доступ в помещения для голосования должен быть обеспечен не менее чем за один час до начала голосования.»;

б) в части 2 слова «О времени» заменить словами «О дне, времени»;

в) дополнить частью $2^1$ следующего содержания:

«$2^1$. На участках голосования по отзыву, образованных в воинских частях, участковая комиссия может объявить голосование законченным раньше времени, установленного в соответствии с частью 1 настоящей статьи, если проголосовали все участники голосования по отзыву, включенные в список участников голосования по отзыву.»;

г) часть 5 изложить в следующей редакции:

«5. Бюллетени выдаются участникам голосования по отзыву, включенным в список участников голосования по отзыву, по предъявлении паспорта или документа, заменяющего паспорт гражданина, а если участник голосования по отзыву голосует по открепительному удостоверению, – по предъявлении также открепительного удостоверения.»;

д) часть 6 дополнить новым четвертым предложением следующего содержания: «В случае голосования по открепительному удостоверению в списке участников голосования по отзыву делаются дополнительные отметки.»;

е) часть 11 дополнить предложением следующего содержания: «Если Центральной избирательной комиссией Республики Татарстан в соответствии с частью 4 статьи 45 настоящего Закона принято решение об использовании конвертов, участник голосования по отзыву вне кабины или иного специально оборудованного места для тайного голосования помещает заполненный бюллетень в конверт, который выдается ему членом участковой комиссии с правом решающего голоса, запечатывает его, после чего опускает этот конверт в ящик для голосования.»;

ж) дополнить частями $11^1$ и $11^2$ следующего содержания:

«$11^1$. Председатель участковой комиссии следит за порядком в помещении для голосования. Распоряжения председателя участковой комиссии, отданные в пределах его компетенции, обязательны для всех присутствующих в помещении для голосования. В отсутствие председателя участковой комиссии его полномочия исполняет заместитель председателя участковой комиссии, а в отсутствие заместителя председателя участковой комиссии – секретарь или иной член участковой комиссии с правом решающего голоса, уполномоченный ею.

$11^2$. При проведении голосования, подсчете голосов участников голосования по отзыву и составлении протокола участковой комиссии об итогах голосования в помещении для голосования, в помещении участковой комиссии вправе находиться лица, указанные в части 3 статьи 22 настоящего Закона. Эти лица вправе осуществлять наблюдение как непрерывно, так и в свободно выбираемые ими промежутки времени в течение всего периода наблюдения, им обеспечивается свободный доступ в помещение (помещения), где проводятся голосование и подсчет голосов участников голосования по отзыву. Список лиц, осуществлявших наблюдение за ходом голосования и подсчетом голосов участников голосования по отзыву, составляется участковой комиссией на основе представленных данными лицами документов.»;

з) часть 12 изложить в следующей редакции:

«12. Член участковой комиссии немедленно отстраняется от участия в ее работе, а наблюдатель и иные лица удаляются из помещения для голосования, если они нарушают закон и факт такого нарушения установлен в судебном порядке. В соответствии с Федеральным законом «Об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации» исполнение соответствующего судебного решения обеспечивают правоохранительные органы. Правоохранительные органы также обеспечивают в соответствии с федеральными законами безопасность граждан и общественный порядок в помещении для голосования и на территории участка для голосования по отзыву.»;

21) в статье $46^1$:

а) часть 2 изложить в следующей редакции:

«2. В случае совмещения дня голосования по отзыву с днем голосования на выборах в федеральные органы государственной власти, в ходе которых законом предусмотрено голосование по открепительным удостоверениям, досрочное голосование, предусмотренное частью 1 настоящей статьи, не проводится. При проведении указанного голосования по отзыву проводится голосование по открепительным удостоверениям.»;

б) часть 9 после слов «предшествующий дню голосования,» дополнить словами «либо не позднее чем в день, предшествующий дню начала досрочного голосования в помещении участковой комиссии,»;

22) в статье 47:

а) в части 1 в первом предложении слова «которые внесены» заменить словами «которые имеют право быть включенными или включены», во втором предложении слово «внесены» заменить словом «включены»;

б) часть 2 после слов «(устные обращения)» дополнить словами «непосредственно в день подачи заявления (устного обращения)»;

в) в части 10 слова «, выезжающие по заявлениям (устным обращениям)» заменить словами «с правом решающего голоса, проводящие голосование вне помещения для голосования», после слов «к моменту выезда» дополнить словами «(выхода) членов комиссии», дополнить новым четвертым предложением следующего содержания: «В список участников голосования по отзыву вносится отметка о том, что к соответствующему участнику голосования по отзыву выехали (вышли) члены участковой комиссии.»;

23) в статье 48:

а) дополнить частью $2^1$ следующего содержания:

«$2^1$. В случае проведения голосования по открепительным удостоверениям в протокол об итогах голосования вносятся также строки:

строка 11а: число открепительных удостоверений, полученных участковой комиссией;

строка 11б: число открепительных удостоверений, выданных участковой комиссией участникам голосования по отзыву на участке для голосования по отзыву до дня голосования;

строка 11в: число участников голосования по отзыву, проголосовавших по открепительным удостоверениям на участке для голосования по отзыву;

строка 11г: число погашенных на участке для голосования по отзыву открепительных удостоверений;

строка 11д: число открепительных удостоверений, выданных территориальной комиссией участникам голосования по отзыву;

строка 11е: число утраченных открепительных удостоверений.»;

б) часть 3 изложить в следующей редакции:

«3. Числа, указанные в частях 2 и $2^1$ настоящей статьи, вносятся в протокол об итогах голосования цифрами и прописью.»;

24) в статье 49:

а) часть 1 дополнить предложением следующего содержания: «Лицам, указанным в части 3 статьи 22 настоящего Закона, должна быть предоставлена возможность присутствовать при подсчете голосов участников голосования по отзыву и наблюдать за подсчетом.»;

б) в части 5:

пункт 1 изложить в следующей редакции:

«1) число участников голосования по отзыву, внесенных в список участников голосования по отзыву на момент окончания голосования (без учета числа участников голосования по отзыву, которым выданы открепительные удостоверения территориальной комиссией и участковой комиссией, а также выбывших по другим причинам);»;

дополнить пунктами $3^2 - 3^4$ следующего содержания:

«$3^2$) число открепительных удостоверений, выданных участковой комиссией участникам голосования по отзыву на участке для голосования по отзыву;

$3^3$) число открепительных удостоверений, выданных территориальной комиссией участникам голосования по отзыву;

$3^4$) число участников голосования по отзыву, проголосовавших по открепительным удостоверениям на участке для голосования по отзыву.»;

в) часть 6 изложить в следующей редакции:

«6. После внесения указанных в части 5 настоящей статьи данных каждая страница списка участников голосования по отзыву подписывается внесшим эти данные членом комиссии, который затем их суммирует, оглашает и сообщает председателю, заместителю председателя или секретарю участковой комиссии и лицам, присутствующим при подсчете голосов. Итоговые данные, определяемые как сумма данных, установленных в соответствии с частью 5 настоящей статьи, председатель, заместитель председателя или секретарь участковой комиссии оглашает, вносит в последнюю страницу списка участников голосования по отзыву, подтверждает своей подписью и заверяет печатью участковой комиссии. Оглашенные данные вносятся в соответствующие строки протокола об итогах голосования и его увеличенной формы, а в случае использования технических средств подсчета голосов – только в соответствующие строки увеличенной формы протокола:

а) в строку 1 – число участников голосования по отзыву, внесенных в список участников голосования по отзыву на момент окончания голосования;

б) в строки 3 и 4 – число бюллетеней, выданных участникам голосования по отзыву, проголосовавшим досрочно;

в) в строку 5 – число бюллетеней, выданных участникам голосования по отзыву, проголосовавшим в помещении для голосования в день голосования;

г) в строку 6 – число бюллетеней, выданных участникам голосования по отзыву, проголосовавшим вне помещения для голосования в день голосования;

д) в строку 11а – число открепительных удостоверений, полученных участковой комиссией;

е) в строку 11б – число открепительных удостоверений, выданных участковой комиссией участникам голосования по отзыву на участке для голосования по отзыву;

ж) в строку 11в – число участников голосования по отзыву, проголосовавших по открепительным удостоверениям на участке для голосования по отзыву;

з) в строку 11г – число погашенных на участке для голосования по отзыву открепительных удостоверений;

и) в строку 11д – число открепительных удостоверений, выданных территориальной комиссией участникам голосования по отзыву.

После осуществления указанных действий проводится проверка следующего контрольного соотношения: число открепительных удостоверений, полученных участковой комиссией, должно быть равно сумме числа открепительных удостоверений, выданных участковой комиссией участникам голосования по отзыву на участке для голосования по отзыву до дня голосования, и числа открепительных удостоверений, погашенных на участке для голосования по отзыву. Если указанное контрольное соотношение не выполняется, участковая комиссия принимает решение о дополнительном подсчете данных, внесенных в список участников голосования по отзыву, и погашенных открепительных удостоверений. Если в результате дополнительного подсчета указанное контрольное соотношение не выполняется снова, участковая комиссия принимает соответствующее решение, которое прилагается к протоколу об итогах голосования, и вносит данные о расхождении в строку 11е протокола об итогах голосования и его увеличенной формы. Если указанное контрольное соотношение выполняется, в строке 11е проставляется цифра «0».

В строки 11а, 11б, 11в, 11г, 11д и 11е протокола об итогах голосования и его увеличенной формы данные вносятся, если законом предусмотрено голосование по открепительным удостоверениям.

После этого со списком участников голосования по отзыву вправе ознакомиться наблюдатели и иные лица, указанные в части 3 статьи 22 настоящего Закона, а члены участковой комиссии с правом совещательного голоса вправе убедиться в правильности произведенного подсчета.»;

г) часть 11 изложить в следующей редакции:

«11. При сортировке бюллетеней участковая комиссия отделяет бюллетени неустановленной формы, то есть изготовленные неофициально либо не заверенные указанной комиссией или не содержащие специального знака (марки) в случае его использования. Бюллетени неустановленной формы при непосредственном подсчете голосов не учитываются. Такие бюллетени упаковываются отдельно и опечатываются.»;

д) в части 20 первое предложение дополнить словами «(за исключением контрольного соотношения, проверка которого проводится в соответствии с частью 6 настоящей статьи) с учетом нумерации строк протокола об итогах голосования, предусмотренной законом»;

е) четвертое предложение части 21 изложить в следующей редакции: «Сложенные таким образом бюллетени, а также бюллетени, упакованные в соответствии с частями 11 и 12 настоящей статьи, упакованные открепительные удостоверения, список участников голосования по отзыву помещаются в мешки или коробки, на которых указываются номер участка для голосования по отзыву, общее число всех упакованных бюллетеней, общее число всех упакованных открепительных удостоверений.»;

ж) часть 27 дополнить предложением следующего содержания: «В случае, если копия протокола изготавливается без применения копировальной техники, указание в копии протокола фамилий, имен и отчеств членов участковой комиссии и проставление их подписей не требуются.»;

25) в статье 50:

а) часть 8 дополнить новым вторым предложением следующего содержания: «В протокол об итогах голосования по отзыву заносятся также данные о числе открепительных удостоверений, полученных соответствующей комиссией, числе открепительных удостоверений, выданных нижестоящим комиссиям, числе неиспользованных открепительных удостоверений, погашенных соответствующей комиссией, и числе утраченных в соответствующей комиссии открепительных удостоверений.»;

б) в части 13 слово «вправе» заменить словом «обязана», слова «в строки 1 – 13 протокола и (или) в сводную таблицу» заменить словами «в строки 1 – 13 (если законом предусмотрено голосование по открепительным удостоверениям, – в строки 11а – 11е) протокола и (или) в сводную таблицу»;

26) в статье 51:

а) часть 1 изложить в следующей редакции:

«1. Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан на основании первых экземпляров протоколов об итогах голосования, полученных из территориальных комиссий, путем суммирования содержащихся в этих протоколах данных не позднее чем через 10 дней со дня голосования определяет результаты голосования по отзыву. Члены Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан с правом решающего голоса определяют результаты голосования по отзыву лично. О результатах голосования по отзыву составляются в двух экземплярах протокол и сводная таблица. Протокол о результатах голосования по отзыву подписывают все присутствующие члены Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан с правом решающего голоса. Сводную таблицу подписывают председатель (заместитель председателя) и секретарь Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан. На основании протокола о результатах голосования по отзыву Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан принимает решение о результатах голосования по отзыву. В протокол о результатах голосования по отзыву заносятся следующие данные:

1) число территориальных комиссий на территории Республики Татарстан;

2) число протоколов территориальных комиссий об итогах голосования;

3) суммарные данные по всем строкам, содержащимся в протоколах территориальных комиссий об итогах голосования.»;

б) дополнить частями $1^1$ и $1^2$ следующего содержания:

«$1^1$. В протокол о результатах голосования по отзыву заносятся также данные о числе открепительных удостоверений, полученных соответствующей комиссией, числе открепительных удостоверений, выданных нижестоящим комиссиям, числе неиспользованных открепительных удостоверений, погашенных соответствующей

комиссией, и числе утраченных в соответствующей комиссии открепительных удостоверений.

1[2]. В сводную таблицу о результатах голосования по отзыву, составляемую Центральной избирательной комиссией Республики Татарстан, заносятся также данные протокола территориальной комиссии о числе открепительных удостоверений, полученных соответствующей территориальной комиссией, числе открепительных удостоверений, выданных участковым комиссиям, числе неиспользованных открепительных удостоверений, погашенных соответствующей территориальной комиссией, и числе открепительных удостоверений, утраченных в соответствующей территориальной комиссии.»;

в) часть 9 после слова «бюллетени» дополнить словами «, открепительные удостоверения»;

27) в части 2 статьи 54 слова «содержащейся в ГАС «Выборы» заменить словами «вводимой в ГАС «Выборы» и выводимой из нее в связи с установлением итогов голосования, определением результатов голосования по отзыву»;

28) дополнить приложением 1[1] следующего содержания:

«Приложение 1[1]
к Закону Республики Татарстан
«О порядке отзыва Президента
Республики Татарстан»

## Голосование по отзыву Президента Республики Татарстан

______________________
(дата голосования)
Открепительное удостоверение N _________

______________________________________________
(фамилия, имя и отчество)

______________________________________________,
(серия и номер паспорта или документа, заменяющего паспорт гражданина)
включенный(ая) в список участников голосования по отзыву на участке для голосования по отзыву N ______________ ______________

______________________________________________,
(адрес участковой комиссии)<1>
образованном на территории ______________________________
(наименование муниципального образования

______________________________________________,
Республики Татарстан) <2>
получил(а) настоящее открепительное удостоверение и имеет право принять участие в голосовании на участке для голосования по отзыву, на котором он (она) будет находиться в день голосования.

______________________________
(председатель, заместитель председателя,
секретарь или член комиссии)

______________________________
(наименование комиссии)

МП
______________ ______________
(подпись) (фамилия и инициалы)

«__» ______________________ ____ г.
(дата выдачи открепительного удостоверения)

Открепительное удостоверение изымается у участника голосования по отзыву по предъявлении его в день голосования.

--------------------------------

<1> Указывается наименование улицы, номер дома и наименование населенного пункта.

<2> В случае если участок для голосования по отзыву находится на территории поселения, также указывается наименование муниципального района. »;

29) приложение 3 изложить в следующей редакции:

«Приложение 3<br>к Закону Республики Татарстан<br>«О порядке отзыва Президента<br>Республики Татарстан»

КОНТРОЛЬНЫЕ СООТНОШЕНИЯ ДАННЫХ, ВНЕСЕННЫХ В ПРОТОКОЛ ОБ ИТОГАХ ГОЛОСОВАНИЯ (ЧИСЛАМИ ОБОЗНАЧЕНЫ СТРОКИ ПРОТОКОЛА, ПРОНУМЕРОВАННЫЕ В СООТВЕТСТВИИ СО СТАТЬЕЙ 48 НАСТОЯЩЕГО ЗАКОНА)

1) 1 больше или равно 3 + 5 + 6;

2) 2 равно 3 – 4 + 5 + 6 + 7 + 12 – 13;

3) 8 + 9 равно 10 + 11;

4) 11 равно 14 + все последующие строки протокола;

5) 11а равно 11б + 11г + 11е (в случае, если при проведении голосования по отзыву предусмотрено использование открепительных удостоверений).».

**Статья 5**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент<br>Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль<br>18 июня 2016 года<br>№ 45-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 31маенда
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6; 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:
а) 1 өлештә "18 яшькә җиткән" сүзләре алдыннан "тавыш бирү көненә" сүзләрен өстәргә;
б) 2 өлештә "30 яшькә җиткән" сүзләрен "тавыш бирү көненә 30 яшькә җиткән" сүзләренә алмаштырырга;
в) 4 өлештә "сайлау һәм сайлану хокукына ия булмый" сүзләрен "сайлау һәм сайлану, сайлауга кагылышлы башка гамәлләрне башкару хокукына ия булмый" сүзләренә алмаштырырга;

2) 6 статьяның 3 өлешендә "якындагы" сүзе татарча текстта үзгәрешсез кала, "икенче якшәмбесендә" сүзләреннән соң ", ә чираттагы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны уздыру елында күрсәтелгән сайлауларда тавыш бирү көнендә" сүзләрен өстәргә;

3) 12 статьяның 10 өлешендә "шәһәр округлары" сүзләреннән соң ", шәһәр эчендәге районнар (шәһәр эчендәге бүленеш белән шәһәр округы)" сүзләрен өстәргә;

4) 14 статьяның 3 өлешендә “югарырак комиссия тарафыннан карар кабул ителгән көннән йә шикаять (гариза) буенча суд карары законлы көченә кергән көннән” сүзләрен “, округ комиссиясенең югарырак комиссия карарын үтәгән йә законлы көченә кергән суд карарын үтәгән көннең иртәгесеннән” сүзләренә алмаштырырга;

5) 16 статьяда:

а) “шикаять (гариза) буенча суд карары законлы көченә кергән” сүзләрен “, участок комиссиясенең югарырак сайлау комиссиясе карарын үтәгән йә законлы көченә кергән суд карарын үтәгән көннең иртәгесеннән” сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 өлештә “югарырак комиссия карар кабул иткән көннән йә шикаять (гариза) буенча суд карары үз көченә кергән көннән” сүзләрен “участок комиссиясенең югарырак сайлау комиссиясе карарын үтәгән йә законлы көченә кергән суд карарын үтәгән көннең иртәгесеннән” сүзләренә алмаштырырга;

в) 7 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:

“$5^1$) “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда һәм әлеге Кодекста каралган очракларда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирә;”;

6) 17 статьяда:

а) 3 өлештә “Даими нигездә эшләүче комиссия,” сүзләреннән соң “шулай ук әлеге Кодексның 16 статьясындагы 1 өлеше нигезендә төзелгән участок комиссиясе” сүзләрен өстәргә;

б) 22 өлештә “эшләрне башкару” сүзләреннән соң “һәм хезмәт күрсәтүләр өчен” сүзләрен өстәргә;

7) 18 статьяда:

а) 1 өлешнең 6 пунктында “судьялар” сүзеннән соң “(отставкадагы судьялардан тыш)” сүзләрен өстәргә;

б) 7 өлештә “әлеге статьяның 1 өлешендәге 9 һәм 10 пунктларында” сүзләрен “әлеге статьяның 1 өлешендәге 7, 9 һәм 10 пунктларында” сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле $16^1$ өлеш өстәргә:

“$16^1$. Комиссиядә даими нигездә (штатта) эшләмәүче, хәлиткеч тавыш хокукына ия комиссия әгъзасына юл, торак урыны наймы чыгымнары, әгәр ул комиссия карары нигезендә комиссия әгъзасы вәкаләтләрен башкару өчен территориясендә комиссия урнашкан торак пункттан читкә җибәрелсә, даими яшәү урыныннан читтә яшәүгә бәйле өстәмә чыгымнар сайлауларны әзерләүгә һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән бюджет акчалары исәбеннән һәм шул чикләрдә компенсацияләнергә мөмкин. Күрсәтелгән компенсация дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында (үткәрелә торган сайлауларның төренә һәм дәрәҗәсенә туры китереп) хезмәт шартнамәсе төзегән хезмәткәрләргә хезмәт командировкаларына бәйле чыгымнарны кайтару өчен каралган тәртиптә һәм

күләмнәрдә башкарыла.";

г) 19 статьяның 4 пунктында "бюллетеньнәрдән," сүзләреннән соң "бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларыннан," сүзләрен өстәргә;

8) 20 статьяда:

а) 2 өлештә "Әлеге Кодексның 18 статьясындагы 1 өлешенең 1, 3 – 6 пунктларында күрсәтелгән затлар, закон көченә кергән суд карары белән хокукый сәләтсез дип танылган гражданнар," сүзләрен " Әлеге Кодексның 18 статьясындагы 1 өлешенең 1 – 6, 12 пунктларында күрсәтелгән затлар" сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлешнең 1 пунктына ", бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары" сүзләрен өстәргә;

в) 4 өлешнең икенче җөмләсендә "Даими нигездә эшләүче" сүзләрен "Әлеге кодексның 16 статьясындагы 1 өлеше нигезендә төзелгән участок комиссиясенең даими нигездә эшләүче" сүзләренә алмаштырырга;

г) 5 өлештә "теркәү бетерелсә яисә кире кагылса" сүзләреннән соң "йә кандидат башка сәбәпләр белән вакытыннан алда китсә," сүзләрен, өлештә "йә кандидат башка сәбәпләр белән вакытыннан алда киткән көннән" сүзләрен өстәргә;

д) 8 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Бу очракта кандидат, кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсе комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзасы вәкаләтләрен туктатырга һәм бер яисә шул ук комиссиягә карата иң күбе биш тапкыр комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия яңа әгъзасын билгеләп куярга хокуклы.";

9) 21 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Комиссиянең барлык утырышларында, шулай ук сайлаучылар тавышларын санаганда һәм участок, территория комиссияләре сайлаучылар исемлекләре, бюллетеньнәр, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары, тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләр һәм җыелма таблицалар белән эшләгәндә югарырак комиссияләр әгъзалары һәм аларның аппарат хезмәткәрләре, әлеге йә югарырак комиссия тарафыннан теркәлгән кандидат яисә финанс мәсьәләләре буенча аның вәкаләтле вәкиле яки ышанычлы заты, кандидатлар исемлеге әлеге йә югарырак комиссия тарафыннан теркәлгән сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле яисә ышанычлы заты яки шушы исемлектәге кандидат катнашырга хокуклы. Кандидатны, кандидатлар исемлекләрен теркәү турындагы мәсьәлә каралачак комиссия утырышында күрсәтелгән кандидат йә финанс мәсьәләләре буенча аның вәкаләтле вәкиле, сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле катнашырга хокуклы. Комиссия утырышларында катнашу өчен һәм күрсәтелгән сайлау документлары белән эшләгәндә әлеге затларга өстәмә рөхсәт алу таләп ителми. Комиссия әлеге затларның үз утырышларына һәм сайлаучыларның тавышларын саный торган һәм күрсәтелгән сайлау документлары белән эшли торган бинага ирекле керә алу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.";

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ һәм $1^2$ өлешләр өстәргә:

"$1^1$. Комиссиянең барлык утырышларында һәм комиссия әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән документлар белән эш иткәндә, шушы статьяның

$1^2$ өлешендә каралган очрактан тыш, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашырга хокуклы.

$1^2$. Комиссия тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә, сайлау нәтиҗәләрен ачыклаганда, шулай ук сайлаучылар тавышларын санаганда комиссия утырышларында сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (публикацияләнгән) көнгә кадәр кимендә ике ай кала төзелгән хезмәт яисә түләүле граждан-хокук шартнамәсе нигезендә массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләрендә эшләүче, әлеге Кодексның 23 статьясындагы 3 өлеше нигезендә аккредитацияләнгән массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашырга хокуклы.";

в) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

"$2^1$. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең рәсми сайты "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон һәм "Сайлаулар" дәүләт автоматлаштырылган системасы турында" 2003 елның 10 гыйнварындагы 20-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча төзелә торган бердәм порталда урнаштырыла.";

г) 3 өлештә "1 өлешендә" сүзләрен "1 һәм $1^2$ өлешләрендә" сүзләренә алмаштырырга;

д) 4 өлештә "шул сайлау участогындагы тавыш бирү бинасына" сүзләреннән соң "һәм сайлаучыларның тавышлары санала торган бинага" сүзләрен өстәргә";

10) 22 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Сайланулы вазыйфаи затлар, депутатлар, Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре), җирле администрацияләр башлыклары, аларның турыдан-туры буйсынуындагы затлар, судьялар, прокурорлар, комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары, комиссияләрнең әлеге Кодексның 18 статьясындагы 7 өлеше нигезендә вәкаләтләре туктатып торылган әгъзаларыннан тыш, күзәтүчеләр итеп билгеләнеп куела алмый.";

б) 3 өлештә бишенче җөмләне төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

"$3^1$. Участок комиссияләренә күзәтүчеләр билгеләгән сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә, теркәлгән кандидат тавыш бирү (вакытыннан алда тавыш бирү) көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча билгеләнгән күзәтүчеләр исемлеген – тиешле территория комиссиясенә, ә җирле үзидарә органнарына сайлаулар үткәрелгәндә муниципаль берәмлекнең тиешле сайлау комиссиясенә тәкъдим итә. Әлеге исемлектә һәр күзәтүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урынының адресы, күзәтүче җибәрелә торган сайлау участогының номеры, комиссиянең исеме күрсәтелә.";

г) 4 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

д) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә, теркәлгән кандидат яисә федераль законда каралган очракларда теркәлгән кандидатның ышанычлы заты һәр комиссиягә тавыш бирү бинасында күзәтүне чират буенча башкарырга хокуклы иң күбе ике күзәтүче билгеләргә хокуклы. Бер үк зат күзәтүче итеп бары тик бер генә комиссиягә билгеләнергә мөмкин. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән юллама үзе билгеләнгән комиссиягә тавыш бирү (вакытыннан алда тавыш бирү) көненә кадәрге көндә йә турыдан-туры тавыш бирү (вакытыннан алда тавыш бирү) көнендә тәкъдим ителергә тиеш. Участок комиссиясенә юллама әлеге статьяның $3^1$ өлешендә каралган исемлектә күрсәтелгән күзәтүче тарафыннан гына тәкъдим ителергә мөмкин. “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда, әлеге Кодекста тавыш бирү бинасында күзәтүчеләрнең булуына, тавыш бирүне, сайлаучылар тавышларын санауны, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәләр төзүне, шулай ук мондый беркетмәләрнең күчермәләрен бирүне күзәтүгә кагылышлы күрсәтелгән чикләүләрдән тыш, башка чикләүләр билгеләү тыела.”;

е) 6 өлештә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) сайлаучылар исемлекләре, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирү реестры, комиссиядәге бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары, тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү турындагы гаризалар (мөрәҗәгатьләр) реестры белән танышырга;”;

түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

“11) тавыш бирү бинасында (участок комиссиясе рәисе билгеләгән урыннан), алдан ук участок комиссиясе рәисенә, рәис урынбасарына яисә секретарена хәбәр итеп, фотога һәм (яисә) видеога төшерергә.”;

11) 23 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“23 статья. **Массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре**

1. Массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре, сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне мәгълүмати яктыртуда катнашып, түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсе, шулай ук тавыш бирү йомгаклары турында, сайлауларның нәтиҗәләре турында башка комиссияләрнең беркетмәләре белән, кабат төзелгәннәрен дә кертеп, танышырга, тиешле комиссиядән күрсәтелгән беркетмәләрнең күчермәләрен алырга;

2) агитация чараларында катнашырга, аларны үткәрүне яктыртырга.

2. Әлеге Кодексның 21 статьясындагы $1^2$ өлешендә күрсәтелгән массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре тавыш бирү көнендә, вакытыннан алда тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында булырга, шулай ук, алдан участок комиссиясе рәисенә, рәис урынбасарына яисә секретарена хәбәр итеп, фотога һәм (яисә) видеога төшерергә хокуклы.

3. Әлеге Кодексның 21 статьясындагы $1^2$ һәм 3 өлешләрендә, әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе яисә аның кушуы

буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аккредитацияләнәләр. Әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен аккредитациягә гаризалар массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре тарафыннан тавыш бирү (вакытыннан алда тавыш бирү) көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча комиссиягә бирелергә тиеш.

4. Әлеге статьяның 3 өлеше нигезендә аккредитацияләнгән массакүләм мәгълүмат чарасы вәкиленә, әгәр тиешле мәгълүматны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) турында закон таләпләре үтәлгән булса, комиссия чарасын үткәрү турында хәбәр ителгән дип санала.";

12) 24 статьяның 2 өлешендә беренче җөмләгә "йә аның вәкаләтләрен тиешле территория комиссиясенә йөкли" сүзләрен өстәргә;

13) 26 статьяда:

1 өлештә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1) һәр сайлау округының номеры;";

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4) һәр сайлау округында сайлаучылар саны, ә күпмандатлы сайлау округлары өчен – шулай ук округта урнаштырыла торган мандатлар саны;";

14) 28 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"28 статья. **Сайлаучыларны теркәү (исәпкә алу)**

1. Барлык сайлаучылар теркәлергә (исәпкә алынырга) тиеш.

2. Тиешле муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче сайлаучылар муниципаль район, шәһәр округы администрациясе башлыгы тарафыннан теркәлә (исәпкә алына). Сайлаучыларның яшәү урыны тиешле территориядә булу факты (күченеп килергә мәҗбүр булганнарга карата – вакытлыча тору факты) сайлаучыларны муниципаль берәмлек территориясендә теркәү (исәпкә алу) өчен нигез була. Күрсәтелгән факт Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә тору урыны һәм яшәү урыны буенча теркәүне гамәлгә ашыручы органнар тарафыннан бирелә торган белешмәләр нигезендә билгеләнә.

3. Сайлаучылар – хәрби хезмәткәрләр, аларның гаилә әгъзалары һәм хәрби частьнең урнашу чикләрендә яшәүче башка сайлаучылар, хәрби часть командиры тарафыннан теркәлә (исәпкә алына). Сайлаучыларның шушы категориясен теркәү (исәпкә алу) өчен аларның яшәү урыны хәрби частьнең урнашу чикләрендә булу факты нигез була, ул хәрби частьнең тиешле хезмәте тарафыннан бирелә торган мәгълүматларга нигезләнеп билгеләнә.

4. "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны һәм яшәү урыны буенча теркәүне, Россия Федерациясе территориясендә Россия Федерациясе гражданының шәхесен таныклаучы документлар бирүне һәм алмаштыруны гамәлгә ашыручы органнар айга кимендә бер тапкыр үзләренең

урнашкан урыны буенча муниципаль район, шәһәр округы администрациясе башлыгына Россия Федерациясе гражданы паспортын бирү һәм алмаштыру, Россия Федерациясе гражданнарын яшәү урыны (күченеп килергә мәҗбүр булганнарга карата – булу урыны) буенча теркәү һәм теркәүне исәпкә алудан төшерү, Россия Федерациясе гражданы паспортын билгеләнгән тәртипне бозып бирү фактлары турында белешмәләрне, гражданның персональ белешмәләрен: фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, туган көнен, туган урынын, җенесен, гражданлыгын, яшәү урыны (күченеп килергә мәҗбүр булганнарга карата – тору урыны) адресын, шәхесне таныклаучы документ төрен, бу документның сериясен һәм номерын, документны биргән органның исемен яисә кодын, документны бирү көнен күрсәтеп, тапшыралар.

5. "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон нигезендә граждан хәле актларын теркәү органнары айга кимендә бер тапкыр үзләренең урнашкан урыны буенча муниципаль район, шәһәр округы администрациясе башлыгына Россия Федерациясе гражданнарының вафат булуы фактлары турында белешмәләр тапшыра.

6. "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон нигезендә өч айга кимендә бер тапкыр хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыручы органнар хәрби хезмәткә чакырылган (контракт буенча кергән; хәрби хезмәттән азат ителгән) Россия Федерациясе гражданнары, җинаять-үтәү системасы органнары (учреждениеләре) суд хөкеме буенча ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнар турында гражданның яшәү урыны буенча муниципаль район, шәһәр округы администрациясе башлыгына хәбәр итәләр.

7. "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон нигезендә суд, гражданны хокукка сәләтсез дип тану турында карар, шулай ук элек суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип танылган гражданны хокукка сәләтле дип тану хакында карар кабул иткәч, кабул ителгән карар турында гражданның яшәү урыны буенча муниципаль район, шәһәр округы җирле администрациясе башлыгына хәбәр итә.

8. Әлеге статьяның 4 – 7 өлешләрендә күрсәтелгән белешмәләр айга кимендә бер тапкыр муниципаль район, шәһәр округы администрациясе башлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә сайлаучылар регистрын булдыру һәм алып бару өчен тапшырыла.

9. Сайлаучыларны теркәү һәм Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән сайлаучыларның санын билгеләү "Сайлаулар" ДАСтан файдаланып һәр елның 1 гыйнварына һәм 1 июленә гамәлгә ашырыла.

10. "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон нигезендә сайлаучыларны теркәү (исәпкә алу), теркәлгән сайлаучыларның санын билгеләү, сайлаучылар регистрын булдыру һәм алып бару сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны дәүләт теркәвенә алу (исәпкә алу) системасы

турында Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе раслый торган нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

11. Сайлаучы үзе турында документлаштырылган мәгълүматтан (персональ белешмәләрдән), шул исәптән машинада укыла торган чыганаклардагы мәгълүматтан тоткарлыксыз файдалана алырга, әлеге мәгълүматның тулылыгын һәм дөреслеген тәэмин итү максатларында аны төгәлләштерергә хокуклы, шулай ук әлеге мәгълүматны кем һәм нинди максатларда файдалануын яисә файдаланганын, аның кем тарафыннан һәм кемгә бирелгәнлеген белергә хокуклы.";

15) 29 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"29 статья. **Сайлаучылар исемлекләрен төзү**

1. Сайлаучыларның хокукларын гамәлгә ашыру максатларында сайлаучыларны теркәүнең (исәпкә алуның) дәүләт системасыннан файдаланып алынган һәм әлеге статьяның 7 пункты нигезендә бирелә торган белешмәләр нигезендә тиешле комиссияләр тарафыннан сайлаучылар исемлекләре төзелә.

2. Сайлау участокларында сайлаучылар исемлекләренә тавыш бирү көненә актив сайлау хокукына ия Россия Федерациясе гражданнары кертелә.

3. Әгәр Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә чит ил гражданнары җирле үзидарә органнарына сайлауларда катнашу хокукына ия булсалар, күрсәтелгән сайлаулар үткәрелгәндә сайлаучылар исемлекләренә тавыш бирү көненә 18 яшькә җиткән һәм әлеге Кодексның 4 статьясындагы 4 өлешендәге гамәлләргә кагылышы булмаган, күрсәтелгән сайлаулар үткәрелә торган муниципаль берәмлек территориясендә даими яшәүче чит ил гражданнары кертелә.

4. Конкрет сайлау участогы территориясендә Россия Федерациясе гражданының яшәү урыны булу факты, ә "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законда, әлеге Кодекста, башка законда каралган очракларда – гражданның әлеге участок территориясендә булу (вакытлыча булу) факты (граждан актив сайлау хокукына ия булганда) йә гражданның бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы булу аны шушы участок территориясендә сайлаучылар исемлегенә кертү өчен нигез була. Гражданның аерым сайлау участогы территориясендә яшәү урыны йә булу (вакытлыча булу) урыны булу факты Россия Федерациясе территориясе чикләрендә Россия Федерациясе гражданнарының булу урыны һәм яшәү урыны буенча теркәлүен исәпкә алучы органнар тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә, ә "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законда, әлеге Кодекста, башка законда каралган очракларда шуңа вәкаләтле органнар, оешмалар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан билгеләнә.

5. Тиешле муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан хәрби частьләрдә, хәрби оешмаларда һәм учреждениеләрдә чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләр, әгәр шушы хәрби хезмәткәрләрнең хәрби хезмәткә чакырылуга кадәрге яшәү урыны муниципаль берәмлек территориясендә урнашмаган булса, сайлаучылар исемлекләренә кертелми һәм җирле үзидарә органнарына сайлауларда сайлаучылар санын билгеләгәндә исәпкә алынмый.

6. Тиешле сайлауларда актив сайлау хокукына ия, тавыш бирү көненә кадәр кимендә өч ай кала тиешле сайлау участогы территориясендә тору урыны буенча теркәлгән сайлаучы, шул исәптән көндезге бүлектә укучы, тавыш бирү көненә кадәр 60 – 21 көн кала тиешле территория комиссиясенә бирелгән шәхси язма гаризасы нигезендә әлеге сайлау участогында сайлаучылар исемлегенә кертелергә мөмкин. Гаризада сайлаучының яшәү урыны адресы күрсәтелә. Гариза биргән сайлаучы участок комиссиясенә исемлек тапшырылганчыга кадәр әлеге сайлау участогында сайлаучылар исемлегенә кертелә. Участок комиссиясе тарафыннан сайлаучылар исемлеге төзелгән очракта, сайлаучы сайлаучылар исемлегенә территория комиссиясеннән тапшырылган гариза нигезендә кертелә. Бу хакта мәгълүмат әлеге сайлаучы яшәү урыны буенча сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлау участогының участок комиссиясенә территория комиссиясе аша тапшырыла. Участок комиссиясе сайлаучылар исемлегенең тиешле юлында, сайлау участогы номерын һәм муниципаль район (шәһәр округы) исемен күрсәтеп, “номерлы сайлау участогында сайлаучылар исемлегенә кертелде” дигән тамга куя.

7. Сайлаучылар турында белешмәләрне муниципаль район, шәһәр округы администрациясе башлыгы төзи һәм төгәлләштерә. Хәрби частьтәге сайлаучы хәрби хезмәткәрләр турында, аларның гаилә әгъзалары һәм башка сайлаучылар турында белешмәләр, әгәр алар хәрби часть урнашкан территориядә яшәсәләр йә хәрби частьтәге хезмәт итү урыны буенча билгеләнгән тәртиптә теркәлгән булсалар, хәрби часть командиры тарафыннан барлана һәм төгәлләштерелә. Вакытлыча булу урыннарындагы сайлаучылар турындагы белешмәләрне сайлау комиссиясенә сайлаучы вакытлыча торган оешманың җитәкчесе тапшыра. Күрсәтелгән белешмәләр шуңа вәкаләтле орган яисә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан территория комиссияләренә (муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләренә), андыйлар булмаганда – округ сайлау комиссияләренә тавыш бирү көне билгеләнгәннән соң яисә әлеге комиссияләр төзелгәннән соң ук җибәрелә.

8. Сайлаучылар исемлеге тиешле комиссия тарафыннан, шул исәптән “Сайлаулар” ДАСтан файдаланып, билгеләнгән рәвеш буенча шуңа вәкаләтле орган яисә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан бирелә торган белешмәләр нигезендә һәр сайлау участогы буенча аерым төзелә.

9. Сайлаучылар турында белешмәләр бирүче затлар бу белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылыгы өчен, шулай ук аларны вакытында тапшыру өчен җаваплы булалар.

10. Россия Федерациясе гражданы бары тик бер сайлау участогында гына сайлаучылар исемлегенә кертелә. Территория комиссиясе (округ сайлау комиссиясе, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе) тарафыннан Россия Федерациясе гражданын бер үк сайлауларда төрле сайлау участокларында сайлаучылар исемлекләренә кертү факты ачыкланганда, тиешле комиссия сайлаучылар исемлекләрен участок комиссияләренә тапшырганчы күрсәтелгән исемлекләрдәге хаталарны яисә төгәлсезлекләрне бетерү эшләрен башкара.

11. Сайлаучылар исемлеге ике нөсхәдә төзелә. Сайлаучылар исемлегенә кертелүче сайлаучылар турындагы белешмәләр алфавит тәртибендә яисә бүтән тәртиптә (торак пунктлар, урамнар, йортлар, фатирлар буенча) урнаштырыла. Исемлектә сайлаучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы (18 яшьтә

булса – өстәмә рәвештә туган көне һәм ае), яшәү урынының адресы күрсәтелә. Сайлаучылар исемлегендә сайлаучыга һәр алган бюллетененә үзе имза салу, үз паспортының яисә граждан паспортын алмаштыра торган документының сериясен һәм номерын кую өчен, шулай ук һәр сайлау төре буенча суммар күрсәткечләр кертү өчен һәм сайлаучыга бюллетень биргән участок комиссиясе әгъзасына имза салу өчен урыннар булырга тиеш.

12. Сайлаучылар исемлегенең беренче нөсхәсенә исемлекне төзегән комиссия рәисе һәм секретаре имза сала. Хәрби часть территориясендә оештырылган сайлау участокларында сайлаучылар исемлегенә участок комиссиясе рәисе һәм секретаре имза сала. Сайлаучылар исемлеге тиешенчә территория комиссиясенең (округ сайлау комиссиясенең, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең) һәм (яисә) участок комиссиясенең мөһерләре белән таныклана. Сайлаучылар исемлегенең икенче нөсхәсен төзү, куллану, аны тиешле участок комиссиясенә тапшыру, таныклау һәм төгәлләштерү тәртибе һәм сроклары сайлауларны оештыручы комиссия тарафыннан билгеләнә.

13. Тиешле территория комиссиясе (округ сайлау комиссиясе, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе) конкрет сайлау участогының сайлаучылар исемлегенең беренче нөсхәсен, тавыш бирү көненә 10 көннән дә соңга калмыйча, акт буенча участок комиссияләренә тапшыра. Участок комиссиясе сайлаучылар исемлегенең беренче нөсхәсен аерым китапларга бүләргә хокуклы. Һәр шундый китап, тавыш бирү көненә бер көннән дә соңга калмыйча, брошюралар итеп тегелергә һәм тиешле участок комиссиясенең мөһере һәм аның рәисенең имзасы белән таныкланырга тиеш.

14. Участок комиссиясе комиссияләрнең җирле үзидарә органнары белән, сайлаучыларны теркәүче (исәпкә алучы) учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген оештыруның билгеләнгән тәртибе нигезендә сайлаучылар исемлеген төгәлләштерә. Тикшерелгән һәм төгәлләштерелгән сайлаучылар исемлеге, тавыш бирү көненә бер көннән дә соңга калмыйча, участок комиссиясе рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана һәм участок комиссиясе мөһере белән таныклана.

15. Участок комиссиясе тавыш бирү көненә кадәр 10 көн кала сайлаучыларны таныштыру һәм өстәмә төгәлләштерүләр өчен сайлаучылар исемлеген тапшыра.

16. Актив сайлау хокукына ия Россия Федерациясе гражданы үзен сайлаучылар исемлегенә кертү турындагы, үзе хакында сайлаучылар исемлегенә кертелгән белешмәләрдәге теләсә нинди хата яисә төгәлсезлек турындагы гариза белән участок комиссиясенә мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Мөрәҗәгать алынганнан соң 24 сәгать эчендә, ә тавыш бирү көнендә ике сәгать эчендә, әмма тавыш бирү тәмамлану мизгеленнән дә соңга калмыйча, участок комиссиясе мөрәҗәгать итүче тарафыннан хәбәр ителгән белешмәләрне һәм тапшырылган документларны тикшерергә һәм йә хатаны яки төгәлсезлекне бетерергә, йә гаризаны кире кагу турында, кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, карар кабул итәргә, бу карарның таныкланган күчермәсен мөрәҗәгать итүчегә тапшырырга тиеш. Россия Федерациясе гражданын сайлаучылар исемлегенә кертү турындагы гаризаны кире кагу хакында участок комиссиясе карарына карата югарырак комиссиягә яисә судка (участок комиссиясе урнашкан урын буенча) шикаять белдерелергә мөмкин, алар

шикаятьне (гаризаны) өч көн эчендә, ә тавыш бирү көненә кадәр өч көн һәм аннан да азрак вакыт калганда һәм тавыш бирү көнендә кичекмәстән карарга тиеш. Шикаятьне (гаризаны) канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән очракта, сайлаучылар исемлегендә участок комиссиясе тарафыннан кичекмәстән төзәтүләр ясала. Тиешле комиссияләрнең рәисләре һәм секретарьлары әлеге статьяның 12 өлешендә каралган тәртиптә сайлаучылар исемлегенә имза салганнан һәм ул таныкланганнан соң, Россия Федерациясе гражданы сайлаучылар исемлегеннән бары тик рәсми документлар, шул исәптән сайлаучыны бүтән сайлау участогында сайлаучылар исемлегенә кертү турында югарырак комиссия хәбәре нигезендә, шулай ук сайлаучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән очракта гына төшереп калдырыла. Бу чакта сайлаучылар исемлегендә, шулай ук "Сайлаулар" ДАС күрсәткечләре базасында Россия Федерациясе гражданын исемлектән төшереп калдыру датасы, шулай ук мондый төшереп калдыруның сәбәбе күрсәтелә. Сайлаучылар исемлегендәге язу участок комиссиясе рәисенең имзасы, ә бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгәндә бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы биргән комиссия әгъзасының имзасы белән, бу имзаны куйган датаны күрсәтеп, таныклана. Россия Федерациясенең һәр гражданы тиешле участокта сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар хакындагы әлеге Кодексның 28 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрнең үзгәрүе турында участок комиссиясенә хәбәр итәргә хокуклы.

17. Вакытлыча булу урыннарындагы, өзлексез циклда эшләүче предприятиеләрдә һәм эш (смена) дәвамын киметеп тору мөмкин булмаган аерым төр эшләр белән шөгыльләнүче сайлаучылар, шулай ук хәрби часть урнашкан урыннан читтәге хәрби хезмәткәрләр булып торучы сайлаучылар тавыш бирү көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча участок комиссиясенә шәхсән бирелгән язма гаризалары буенча, участок комиссиясе карары белән аларның вакытлыча тору урыны буенча сайлау участогында сайлаучылар исемлегенә кертелергә мөмкин. Бу турыдагы мәгълүмат тиешле территория комиссиясе (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе) аша әлеге сайлаучының яшәү урыны буенча сайлаучылар исемлегенә кертелгән участок комиссиясенә тапшырыла. Участок комиссиясе сайлаучылар исемлегенең тиешле юлында: " __ номерлы сайлау участогында сайлаучылар исемлегенә кертелде" дигән тамга куя, сайлау участогының номерын күрсәтә.

18. Тавыш бирү тәмамланганнан соң һәм сайлаучыларның тавышларын санау башланганнан соң сайлаучылар исемлегенә нинди дә булса үзгәрешләр кертү тыела.

19. Сайлау нәтиҗәләре рәсми басылып чыкканнан соң сайлаучылар исемлекләрендәге сайлаучылар турындагы мәгълүмат сайлаучылар регистрында сайлаучылар турындагы белешмәләрне төгәлләштерү өчен файдаланылырга мөмкин.";

16) 30 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

17) 32 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: "Сайлау бюллетенендә, тавыш бирү йомгаклары, сайлау нәтиҗәләре турындагы беркетмәдә, әгәр җиде сүздән артык булмаса, сәяси партиянең, иҗтимагый берләшмәнең исеме

кулланыла. Әгәр сәяси партиянең, иҗтимагый берләшмәнең исеме җиде сүздән артык булса, ә кыскартылган исеме җиде сүздән артмаса, сайлау бюллетенендә, тавыш бирү йомгаклары, сайлау нәтиҗәләре турындагы беркетмәдә сәяси партиянең, иҗтимагый берләшмәнең кыскартылган исеме кулланыла. Әгәр сәяси партиянең, иҗтимагый берләшмәнең тулы исеме дә, кыскартылган исеме дә җиде сүздән артмаса, кандидат яисә кандидатны, кандидатлар исемлеген күрсәткән сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә органы законда каралган тәртиптә кыска (җиде сүздән артмаган) исемне килештерә, ул сайлау бюллетенендә, тавыш бирү йомгаклары, сайлау нәтиҗәләре турындагы беркетмәдә кулланыла. Монда сәяси партиянең, иҗтимагый берләшмәнең кыска исеме “Сәяси партияләр турында” Федераль законның 6 статьясында, “Иҗтимагый берләшмәләр турында” 1995 елның 19 маендагы 82-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрендә каралган таләпләрне үтәгән хәлдә һәм сәяси партиянең, иҗтимагый берләшмәнең уставында күрсәтелгән исемен тәшкил итүче сүзләрдән генә төзелә.”;

18) 36 статьяның 3 өлешендәге 4 пунктына “(билгеләнгән очракта)” сүзләрен өстәргә;

19) 37 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Кандидат бердәм сайлау округы буенча кандидатлар исемлегендә бер генә тапкыр күрсәтелә ала.”;

20) 39 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“39 статья. **Үз-үзен күрсәтү тәртибендә күрсәтелгән кандидатлар тарафыннан сайлау комиссияләренә документлар тапшыру тәртибе**

1. Бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округы яисә бердәм сайлау округы буенча үз кандидатурасын күрсәткән гражданин тиешле округ комиссиясенә (яисә тиешле округ комиссиясе вәкаләтләре йөкләнгән комиссиягә) йә сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясенә, тиешенчә, сайланган очракта – депутат статусына яисә бүтән сайлаулы вазыйфаны биләүгә туры килми торган эшчәнлеген туктату йөкләмәсе белән, бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округы яисә бердәм сайлау округы буенча күрсәтелергә ризалык бирүе турында кандидат гаризасын тапшыра. Гаризада шулай ук түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы һәм урыны, яшәү урынының адресы, паспортының яисә гражданин паспортын алмаштыручы документының сериясе, номеры һәм бирү датасы, паспортын яисә гражданин паспортын алмаштыручы документны биргән органның исеме яисә коды, салым түләүченең идентификация номеры (булган очракта), гражданлыгы, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманы күрсәтеп, һөнәри белем турында белешмәләр (булган очракта), аны тәмамлау елы, белем һәм квалификация турындагы документының реквизитлары, төп эш яисә хезмәт итү урыны, биләгән вазыйфасы (төп эш яисә хезмәт итү урыны булмаган очракта – шөгыльләренең төре);

2) әгәр кандидат депутат булып торса һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкарса, бу хакта белешмәләр һәм тиешле вәкиллекле органның исеме;

3) әгәр кандидат элек хөкем ителгән булса яисә аның хөкем ителүе гамәлдә булса, – кандидатның хөкем ителүе турында белешмәләр, әгәр хөкем ителүе юкка чыгарылган яисә кире алынган булса, – шулай ук хөкем ителүне юкка чыгару яисә кире алу датасы турында белешмәләр.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган гариза белән бергә түбәндәгеләр тапшырыла:

1) паспортының (паспортның Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән аерым битләренең) яисә граждан паспортын алмаштыручы документының кандидат таныклаган күчермәсе;

2) кандидатның белеме, төп эш яисә хезмәт итү урыны, били торган вазыйфасы (шөгыльләренең төре) турында, шулай ук кандидатның депутат булуы турында гаризада күрсәтелгән белешмәләрне раслаучы документларның депутат тарафыннан таныкланган күчермәләре;

3) кандидат фамилиясен, йә исемен, йә атасының исемен үзгәрткән булса, – тиешле документларның күчермәләре;

4) кандидатның керемнәре күләме һәм аларның чыганаклары турында, шулай ук милек хокукында (шул исәптән уртак милек) кандидатныкы булган мөлкәте турында, банклардагы кертемнәре, кыйммәтле кәгазьләре турындагы белешмәләр. Күрсәтелгән белешмәләр “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда билгеләнгән рәвештә тапшырыла. Сайлау округлары сайлаучылар саны биш меңнән артмаган уртача вәкиллек нормасы нигезендә төзелә торган муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлаганда кандидатлар тиешле сайлау комиссиясенә әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләрне тапшырмаска тиеш. “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 73 статьясындагы $2^1$ өлеше нигезендә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы таркатылуга бәйле рәвештә билгеләнгән муниципаль берәмлек вәкиллекле органына сайлауларда әлеге орган депутаты булып торган һәм бу муниципаль берәмлек вәкиллекле органының рәттән өч ай дәвамында тулы хокуклы утырышын үткәрмәгән өчен гаепсезлеге факты суд тарафыннан билгеләнгән затлар арасыннан булган кандидат законлы көченә кергән күрсәтелгән суд карарын өстәмә рәвештә тапшырырга тиеш;

5) финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкилгә карата нотариаль таныкланган ышанычнамә (әлеге Кодекс нигезендә ул вәкил кандидат тарафыннан билгеләнеп куелган очракта).

3. Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны уздырганда кандидат әлеге статьяның 1 өлешендә каралган гариза белән бергә сайлау комиссиясенә шулай ук Россия Федерациясе Президенты указы белән каралган форма буенча түбәндәгеләрне тапшыра:

1) кандидатка, аның хатынына (иренә) һәм балигъ булмаган балаларына карый торган Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан күчемсез мөлкәт турында, шул мөлкәт сатып алынган акчаларны алу чыганаклары хакында,

кандидатның Россия Федерациясе территориясеннән читтә мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының шундый йөкләмәләре хакында белешмәләрне;

2) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алуга кагылышлы алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары һәм, әгәр алыш-биреш суммасы кандидатның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчыга кадәр соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса, алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләрне.

4. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне тикшерү тәртибе Россия Федерациясе Президенты указы белән билгеләнә.

5. Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны уздырганда кандидат кандидатны теркәү өчен кирәкле документлар бирү вакытына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларындагы счетларын (кертемнәрен) ябарга, акчалар һәм кыйммәтле әйберләрен саклауны туктатырга һәм (яисә) чит ил финанс инструментларыннан читләштерүне гамәлгә ашырырга тиеш.

6. Кандидат гаризада кайсы сәяси партиядән булуын йә тавыш бирү көненә кадәр бер елдан да соңга калмыйча законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән бер генә иҗтимагый берләшмәдән булуын һәм үзенең шушы сәяси партиядәге, шушы иҗтимагый берләшмәдәге статусын күрсәтергә хокуклы, гариза белән бергә әлеге белешмәләрне раслаучы һәм сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең вәкаләтле заты йә сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең тиешле структур бүлекчәсенең вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган документның тапшырылуы шарт.

7. Үз кандидатурасын үзе күрсәткән кандидат әлеге статьяның 1 – 3 өлешләрендә каралган документларны сайлау комиссиясенә шәхсән илтеп тапшырырга тиеш. Кандидат авыру булган, шик белдерелгән һәм гаепләнүче затлар сак астында тотыла торган урыннарда булган очракта, федераль законда билгеләнгән башка очракларда әлеге документлар кандидат үтенече буенча башка затлар тарафыннан (бу чакта язма гаризадагы кандидат имзасының дөреслеге нотариаль рәвештә йә кандидат дәвалана торган стационар дәвалау-профилактика учреждениесенең администрациясе, шик белдерелгән һәм гаепләнүче зат буларак сак астында тоту учреждениесе администрациясе тарафыннан расланырга тиеш) тапшырылырга мөмкин.

8. Инвалид булган һәм шуңа бәйле рәвештә тиешле сайлау округы буенча чыгарга ризалык бирү турындагы гаризаны мөстәкыйль язу, имза кәгазен таныклау, законда каралган башка документларны тутыру яисә таныклау мөмкинлеге булмаган зат үз кандидатурасын күрсәткән очракта, әлеге зат моның өчен башка зат ярдәменнән файдаланырга хокуклы. Мондый чакта әлеге статьяның 1 өлешендә, 2 өлешендәге 1 – 4 пунктларында, 3 өлешендә күрсәтелгән документларны тутырганда яисә таныклаганда ярдәм күрсәтүче затның вәкаләтләре нотариаль таныкланган булырга тиеш.

9. Кандидат күрсәтелгән мизгелгә округ комиссиясе төзелмәгән булса, кандидатның чыгу өчен ризалык бирүе турындагы гаризасы һәм әлеге статьяның 1 һәм 3 өлешләрендә күрсәтелгән башка документлар округ комиссиясе төзелгәнчегә кадәр тапшырылган документлар белән эшләү буенча округ комиссиясе функцияләрен башкара торган сайлауларны оештыручы комиссиягә тапшырыла. Сайлауларны оештыручы комиссия күрсәтелгән документларны округ комиссиясе төзелгәннән һәм аның рәисе билгеләп куелганнан соң округ комиссиясенә тапшыра.

10. Әлеге статьяның 1 һәм 3 өлешләрендә каралган документлар тиешле сайлау комиссиясе тарафыннан кандидатның шәхесен таныклаучы документ (паспорты яисә граждан паспортын алмаштыручы документ) күрсәтелгәндә кабул ителә. Әгәр документлар кандидат яисә башка зат үтенече белән бирелсә, кандидатның шәхесен таныклаучы документның (граждан паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының) нотариаль таныкланган күчермәсе күрсәтелә.

11. Тиешле сайлау комиссиясе шул документларны тапшырган затларга әлеге статьяның 1 һәм 3 өлешләрендә күрсәтелгән документларның алынуы турында язма раслама бирергә тиеш. Күрсәтелгән язма раслама шул документлар тапшырылганнан соң кичекмәстән бирелә.";

21) 40 статьяда:

а) 3 өлештә:

1 пунктта "39 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында" сүзләрен "39 статьясындагы 1 өлешендә" сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта "(паспортның Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән аерым битләренең) яисә" сүзләреннән соң "кандидат яисә сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле тарафыннан таныкланган" сүзләрен өстәргә, "39 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында" сүзләрен "39 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында" сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

"$2^1$) әгәр кандидат фамилиясен яисә исемен, яисә атасының исемен алыштырган булса, – тиешле документларның күчермәләрен.";

б) $3^2$ өлештә:

"39 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында" сүзләрен "39 статьясындагы 1 өлешендә" сүзләренә, "39 статьясындагы $1^1$ өлешендә" сүзләрен "39 статьясындагы 3 өлешендә"сүзләренә алмаштырырга;

в) $4^1$ өлештә "сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиленең" сүзләрен "сайлау берләшмәсе уставы яисә сайлау берләшмәсенең вәкаләтле органы карары белән вәкаләт бирелгән зат" сүзләренә алмаштырырга;

г) $5^1$ өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"$5^1$. Кандидатның әлеге Кодексның 39 статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында, 2 өлешенең 4 пунктында, 6 өлешендә (Дәүләт Советына сайлаулар үткәрелгәндә – шулай ук 3 өлешендә) каралган документларының булмавы әлеге кандидатны, ул таныкланганчыга кадәр, сайлауларны оештыручы сайлау

комиссиясе тарафыннан кандидатлар исемлегеннән төшереп калдыру өчен нигез булып тора.";

22) 41 статьяда:

а) 1 өлештә:

1 пунктта "39 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында" сүзләрен "39 статьясындагы 1 өлешендә" сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта "39 статьясындагы 1 өлешенең $1^1$, 2 һәм 3 пунктларында" сүзләрен "39 статьясындагы 2 өлешенең 1 – 4 пунктларында" сүзләренә алмаштырырга;

б) $1^2$ өлештә:

"39 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында" сүзләрен "39 статьясындагы 1 өлешендә" сүзләренә алмаштырырга;

"39 статьясындагы $1^1$ өлешендә" сүзләрен "39 статьясындагы 3 өлешендә"сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 өлештә "39 статьясындагы $1^1$ өлешендә" сүзләрен "39 статьясындагы 3 өлешендә" сүзләренә алмаштырырга;

г) 5 өлештә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

23) 42 статьяда:

а) 2 өлештә:

1 пунктта "39 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында" сүзләрен "39 статьясындагы 1 өлешендә" сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта "39 статьясындагы 1 өлешенең 2 һәм 3 пунктларында" сүзләрен "39 статьясындагы 2 өлешенең 1 – 4 пунктларында" сүзләренә алмаштырырга;

б) $2^1$ өлештә "39 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында" сүзләрен "39 статьясындагы 1 өлешендә" сүзләренә, "39 статьясындагы $1^1$ өлешендә" сүзләрен "39 статьясындагы 3 өлешендә" сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлештә "39 статьясындагы $1^1$ өлешендә" сүзләрен "39 статьясындагы 3 өлешендә" сүзләренә алмаштырырга;

г) 4 өлештә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

24) $42^1$ статьяда:

а) 8 өлештә "сайтта" сүзләрен "рәсми сайтта" сүзләренә алмаштырырга;

б) 9 өлештә "сайтта" сүзләрен "рәсми сайтта" сүзләренә алмаштырырга;

25) 43 статьяның 4 өлешендәге икенче җөмләсендә "кирәкле имзалар саны" сүзләреннән соң "күпмандатлы сайлау округлары схемасында күрсәтелгән" сүзләрен өстәргә;

26) 44 статьяда:

а) 1 өлештә "комиссиягә хәбәр ителгән" сүзләреннән соң ", кандидатлар исемлеген таныклаган" сүзләрен өстәргә;

б) 7 өлештә "39 статьясындагы 2 өлешендә" сүзләрен "39 статьясындагы 6 өлешендә" сүзләренә алмаштырырга;

в) 14 өлештә "һәм машинадан укыла торган саклагычларда" сүзләрен төшереп калдырырга;

27) 45 статьяда:

3 өлешнең 4 пунктында:

"в" пунктчасында ", шулай ук гариза язылган датага кадәрге биш ел дәвамында яшәү урыны адресы турындагы белешмәләр" сүзләрен төшереп калдырырга;

"е" пунктчасында ", шулай ук Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләрен бирү өчен кандидат итеп күрсәтелгәнгә кадәр тулаем алганда биш ел били торган дәүләт вазыйфалары яисә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары турында белешмәләр" сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле "$е^1$" пунктчасын өстәргә:

"$е^1$) әлеге затның Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәве турында "Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советын төзү тәртибе турында" 2012 елның 3 декабрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 өлешендә каралган таләпләргә йә күрсәтелгән статьяның 3 өлешендәге таләпләргә җавап бирүен раслый торган белешмәләр;";

28) 46 статьяда:

а) $4^1$ өлештә "39 статьясындагы ә" сүзләрен "39 статьясындагы ә" сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^2$ – $4^7$ өлешләр өстәргә:

"$4^2$. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, кандидатлар биргән, шул исәптән башка сайлау комиссияләреннән алынган белешмәләрнең дөреслеген тикшергәндә, кредит оешмаларыннан кандидатларның счетлары, кертемнәре турында, ә федераль законда каралган очракларда – кандидатларның ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының счетлары, кертемнәре турында аларда булган белешмәләрне соратып ала.

$4^3$. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, кандидатлар биргән, шул исәптән башка сайлау комиссияләреннән алынган белешмәләрнең дөреслеген тикшергәндә, реестр һәм депозитарий тотучылардан кандидатларга карый торган кыйммәтле кәгазьләр турында, ә федераль законда каралган очракларда – кандидатларның ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының кыйммәтле кәгазьләре турында аларда булган белешмәләрне соратып ала.

$4^4$. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе кредит оешмаларына, реестр һәм депозитарий тотучыларга кандидатларның, аларның ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының счетлары, кертемнәре турында, шулай ук күрсәтелгән затларга карый торган кыйммәтле кәгазьләр турында белешмәләр бирү хакында запрослар җибәрә һәм күрсәтелгән белешмәләрне, Россия Федерациясе Үзәк банкы мәгълүмат ресурсларыннан файдаланып, электрон документлар рәвешендә ала.

$4^5$. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең кредит оешмаларына, реестр һәм депозитарий тотучыларга белешмәләр бирүне сорап җибәргән запросында кандидатлар, аларның ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балалары турында түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш: фамилиясе, исеме, атасының исеме

(булганда), паспортының яисә граждан паспортын алмаштыра торган документының сериясе һәм номеры, туу датасы, туган урыны, яшәү урыны адресы.

4[6]. "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон нигезендә кредит оешмалары, реестр һәм депозитарийлар тотучылардан белешмәләр соратып алу турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясеннән запрослар алу тәртибе һәм кредит оешмалары, реестр һәм депозитарийлар тотучылар тарафыннан аларда булган белешмәләрне җибәрү тәртибе, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе белән килештереп, Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнә.

4[7]. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең кредит оешмаларыннан, реестр һәм депозитарий тотучылардан алынган әлеге статьяның 4[2] һәм 4[3] өлешләрендә күрсәтелгән белешмәләрне тикшерү нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә кандидатлар, аларның ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балалары турында кандидатлар биргән белешмәләрнең дөреслеген тикшергәндә тиешле мәгълүмат биргән сайлау комиссияләренә тапшырыла.";

в) 8 өлештә "Территориаль бүленеше булмаган шәһәр округы, муниципаль район" сүзләреннән соң ", шәһәр эчендәге район (шәһәр эчендәге бүленеш белән шәһәр округы)" сүзләрен өстәргә;

г) 10 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10. Тиешле сайлау комиссиясе карары буенча сайлаучыларның бирелгән барлык имзалары яисә әлеге имзаларның бер өлеше, ләкин тикшерү өчен очраклы аралап алынган (шобага салу юлы белән) теркәлү өчен кирәк булган сайлаучылар имзалары санының кимендә 20 проценты, тикшерелергә тиеш. Тикшерү өчен һәр кандидатны, кандидатлар исемлеген хуплап җыелган сайлаучылар имзалары бертигез санда алына. Теркәлү өчен кирәкле сайлаучылар имзалары саны 200дән артмаган очракта, сайлаучыларның барлык имзалары да тикшерелә. Аралап сайлап алуны үткәрү процедурасы тиешле сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.";

д) 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"11. Аралап алу сайлау комиссиясенең үзендә кандидатка, сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиленә имзалар кәгазьләренең кабул итеп алынуын раслый торган документ тапшырылганнан соң уздырыла.";

е) 12 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"12. Аралап алу үткәрелгәндә һәм имзалар кәгазьләрен тикшергәндә билгеләнгән санда имзалар тапшырган кандидатлар, кандидатларның, кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәләренең ышанычлы затлары яисә вәкаләтле вәкилләре катнашырга хокуклы. Билгеләнгән санда сайлаучылар имзаларын тапшырган кандидатларга, сайлау берләшмәләренең вәкаләтле вәкилләренә аралап алу һәм тикшерү үткәрелү турында хәбәр ителергә тиеш. Сайлаучыларның барлык имзалары һәм тикшерү өчен сайлап алынган имзалар кәгазьләрендәге сайлаучылар турында аларга туры килә торган белешмәләр тикшерелергә тиеш.";

ж) 21 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

з) 22 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

и) 23 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“23. Имзалар кәгазьләрен тикшерү тәмамланганнан соң һәр кандидат, кандидатлар исемлеге буенча йомгаклау беркетмәсе төзелә, аңа эшче төркем җитәкчесе – тиешле сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы имза сала, һәм ул сайлау комиссиясе тарафыннан карар кабул ителү өчен тәкъдим ителә. Беркетмәдә сайлаучыларның алдан белдерелгән имзалары саны, тапшырылган имзалары һәм тикшерелгән имзалары саны, шулай ук дөрес түгел һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип танылган имзалар саны һәм аларны шундыйлар дип тануның нигезләре (сәбәпләре) күрсәтелә.”;

к) 24 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“24. Беркетмәнең күчермәсе, кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү турындагы мәсьәлә каралырга тиешле комиссия утырышына кадәр кимендә ике тәүлектән дә соңга калмыйча, кандидатка, сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиленә тапшырыла. Әгәр комиссиянең имзалар кәгазьләрен тикшерүе әлеге Кодексның 47 статьясындагы 6 өлешенең $6^1$ һәм 7 пунктларында яисә 7 өлешенең $2^2$ һәм $2^3$ пунктларында каралган нәтиҗәләргә китерсә, кандидат, сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле комиссиядә йомгаклау беркетмәсенең күчермәсе белән бергә имзалар кәгазьләрен тикшерү ведомостьларының таныкланган күчермәләрен алырга хокуклы, аларда сайлаучыларның имзаларын дөрес түгел һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип тану нигезләре (сәбәпләре), шундый имзалар булган папкаларның, имзалар кәгазенең номерлары һәм имзалар кәгазендәге юллар күрсәтелә, шулай ук кандидат тиешле имзаларны дөрес түгел һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез була торган рәсми документларның күчермәләрен алырга хокуклы.”;

29) 47 статьяда:

а) 6 өлешнең $1^2$ пунктында “39 статьясындагы $1^3$ өлешендә” сүзләрен “39 статьясындагы 5 өлешендә” сүзләренә алмаштырырга;

б) 8 өлешнең 5 пунктында “йә бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округында үз-үзен күрсәтү тәртибендә яисә башка сайлау берләшмәсе тарафыннан күрсәтелү нигезендә” сүзләрен өстәргә;

30) 52 статьяның 2 өлешендә “өч“ сүзен “биш“ сүзенә алмаштырырга;

31) 53 статьяның 5 өлешендә “китүе яисә аларны төшереп калдыру” сүзләрен “китүе, шул исәптән аларны төшереп калдыру,” сүзләренә алмаштырырга;

32) 55 статьяда:

а) 1 өлештә “массакүләм мәгълүмат чараларын” сүзләреннән соң “Интернет” челтәре басмалары редакцияләрен” сүзләрен өстәргә;

б) 4 һәм 5 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Массакүләм мәгълүмат чаралары чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмаларның, “Интернет” челтәре басмалары редакцияләренең сайлаучыларга федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла торган мәгълүмат бирү эшчәнлеге ирекле башкарыла. Массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар, “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре әлеге статьяның 2 өлеше

нигезендә кандидатлар белән интервьюны бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), кандидатлар, сайлау берләшмәләре турында башка хәбәрләр һәм материаллар, кандидатлар катнашында тапшырулар чыгарырга (эфирга) хокуклы. Телерадиотапшырулар оешмалары, электрон челтәрләр басмалары редакцияләре әлеге статьяның 2 өлеше нигезендә кандидатлар катнашында уртак чаралар оештырырга һәм телерадиотапшырулар оешмалары каналларында аларны трансляцияләргә (халыкка җиткерергә) хокуклы.

5. Мәгълүмат бирүче телепрограммаларда һәм радиопрограммаларда, вакытлы матбугат басмаларындагы язмаларда, "Интернет" челтәре басмасы саннарында йә яңартылган саннарында сайлау алды чараларын уздыру турындагы хәбәрләр бары тик аерым мәгълүмат блогы рәвешендә, комментарийларсыз гына бирелергә тиеш. Мондый мәгълүмат блоклары өчен сайлау берләшмәләре, кандидатлар тарафыннан түләнми. Аларда кандидатка, сайлау берләшмәсенә өстенлек бирелмәскә, дискриминациягә (хокукларны кысрыклауга) юл куелмаска тиеш, моңа аларның сайлау алды эшчәнлеген яктырту вакыты, мондый хәбәрләр өчен бирелгән матбугат мәйданының күләме дә керә.";

в) 6 өлештә "катнашкан журналист, башка иҗади хезмәткәр, массакүләм мәгълүмат чараларын" сүзләрен "катнашучы (катнашкан) журналист, башка иҗади хезмәткәр, массакүләм мәгълүмат чараларын, "Интернет" челтәре басмалары редакцияләрен" сүзләренә алмаштырырга;

33) 57 статьяда:

а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар үткәрелгәндә региональ дәүләт һәм муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары, региональ дәүләт һәм муниципаль вакытлы матбугат басмалары исемлеге, ә җирле үзидарә органнарына сайлаулар үткәрелгәндә муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары һәм муниципаль вакытлы матбугат басмалары исемлеге массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле башкарма хакимият органы тәкъдиме буенча сайлауларны оештыручы комиссия тарафыннан сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырылган) көннән соң унбиш көннән дә соңга калмыйча чыгарыла. Күрсәтелгән исемлек тиешле сайлау комиссиясенә "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда тиешле сайлау комиссиясенә тапшырыла.";

б) түбәндәге эчтәлекле 4 һәм 5 өлешләр өстәргә:

"4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар үткәрелгәндә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән органы "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон нигезендә, сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырылган) көннән соң бишенче көннән дә соңга калмыйча, федераль башкарма хакимият органының массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле

территориаль органына Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм оешмалары гамәлгә куючылары (уртак гамәлгә куючылары) яисә редакцияләрен гамәлгә куючылар (уртак гамәлгә куючылар) булып торган һәм (яисә) сайлауларны билгеләү турында карар рәсми бастырып чыгарылган (басылган) көнгә кадәрге елда Татарстан Республикасы бюджетыннан аларның эшләве өчен каралган бюджет ассигнованиеләре (шул исәптән субсидияләр рәвешендә) бирелгән (мондый ассигнованиеләрнең төре һәм күләме турында белешмәләрдә күрсәтелә), һәм (яисә) сайлауларны билгеләү турында карар рәсми бастырып чыгарылган (бастырылган) көнгә устав (җыелма) капиталында Татарстан Республикасының өлеше (кертеме), Россия Федерациясенең башка субъектлары белән Татарстан Республикасының уртак өлеше (кертеме) булган телерадиотапшырулар оешмаларының һәм вакытлы басма матбугатларның исемлеген тапшыра.

5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлаулар үткәрелгәндә җирле үзидарә органы сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырылган) көннән соң бишенче көннән дә соңга калмыйча федераль башкарма хакимиятнең массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле органының территориаль органына “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законның 47 статьясындагы 3 пунктының гамәли көче кагыла торган телерадиотапшырулар һәм вакытлы матбугат басмалары оешмаларының исемлеген тапшыра, сайлауларны билгеләү хакындагы карар рәсми басылып чыккан (бастырылган) көнгә кадәрге елда җирле бюджеттан эшләү өчен бюджет ассигнованиеләре (шул исәптән субсидияләр рәвешендә) бүлеп бирелгән телерадиотапшырулар оешмаларына һәм вакытлы матбугат басмаларына карата мондый ассигнованиеләрнең төре һәм күләме күрсәтелә.”;

34) 58 статьяда:

а) 3 өлештә “Массакүләм мәгълүмат чараларын,” сүзләреннән соң “һәм “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре вәкилләре” сүзләрен өстәргә;

б) 4 өлешнең 1 пунктында “һәм вакытлы матбугат басмаларында” сүзләрен “, вакытлы матбугат басмаларында һәм “Интернет” челтәре басмаларында” сүзләренә алмаштырырга;

в) 7 өлештә “, әлеге статьяның 10 өлешендәге 5 пунктында каралган очрактан тыш“ сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 8 өлештә:

2 пунктта “(югары идарә органы җыелыш булган оешмаларда – шул оешмаларның эшчәнлегенә җитәкчелек итүче органнар әгъзаларына);” сүзләрен “(югары идарә органы җыелыш булган оешмаларда – шул оешмаларның эшчәнлегенә җитәкчелек итүче органнар әгъзаларына). Агитация материалында мондый затның вазыйфасын күрсәтү әлеге тыюны бозу булмый;” сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта “оешмалар вәкилләренә” сүзләреннән соң “һәм “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре вәкилләренә” сүзләрен өстәргә;

д) түбәндәге эчтәлекле $9^1$ пункт өстәргә:

“$9^1$. Әлеге Кодекс нигезендә сайлау алды агитациясе алып бару хокукына ия булмаган физик затның бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округлары буенча кандидатлар исемлеген, кандидатлар күрсәткән сайлау берләшмәсе турында, кандидат (кандидатлар) турында әйткән фикерләрен агитация материалларында куллану рөхсәт ителми.”;

е) 10 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“10. Әлеге статьяның $9^1$ өлешендә күрсәтелмәгән физик затның кандидат, сайлау берләшмәсе турында әйткән фикерләрен агитация материалларында куллану бары тик шушы физик затның язма ризалыгы белән генә рөхсәт ителә. Мондый ризалыкны раслый торган документ сайлау комиссиясенә әлеге Кодексның 64 статьясындагы 4 өлеше нигезендә бирелә торган агитация материалларының нөсхәләре белән бергә тапшырыла. Агитация материалын теле- радиотапшырулар оешмасы каналында йә вакытлы матбугат басмасында урнаштырган очракта күрсәтелгән документ сайлау комиссиясенә аның таләбе буенча тапшырыла. Күрсәтелгән документны тапшыру түбәндәге очракларда таләп ителми:

а) сайлау берләшмәсе үзләре күрсәткән кандидатларның фикерләрен тиешле сайлауларда файдаланганда;

б) кандидатлар, сайлау берләшмәләре турында халыкка җиткерелгән фикерләрдән файдаланганда, мондый фикерләрне халыкка җиткерү датасын (вакыт чорын) һәм аларны җиткергән массакүләм мәгълүмат чарасы исемен күрсәтеп;

в) сайлау берләшмәсе турында, кандидат турында башка сайлау берләшмәләренең, кандидатларның тиешле сайлауларда халыкка җиткерелгән фикерләреннән закон нигезендә әзерләнгән һәм таратылган агитация материалларында өзекләр китергәндә.”;

ж) түбәндәге эчтәлекле $10^1 – 10^2$ өлешләр өстәргә:

“$10^1$. Сайлаулар үткәргәндә агитация материалларында физик затның сурәтләрен куллану бары тик түбәндәге очракларда гына рөхсәт ителә:

а) сайлау берләшмәсе тарафыннан тиешле сайлауларда алар күрсәткән кандидатларның (шул исәптән кандидатлар исемлеге составында), билгесез затлар даирәсе арасыннан кандидатларны кертеп, сурәтләреннән файдаланганда;

б) кандидат үз сурәтеннән файдаланганда, шул исәптән билгесез затлар даирәсе арасыннан.

$10^2$. Әлеге статьяның $10^1$ өлешендә күрсәтелгән очракларда тиешле сурәтләрдән файдалану өчен ризалык алу таләп ителми.”;

35) 59 статьяда:

а) 1 һәм 2 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Сайлау берләшмәсе өчен агитация чоры аның тарафыннан кандидатны, кандидатларны, кандидатлар исемлеген күрсәтү турында карар кабул ителгән көннән башлана. Кандидатлар исемлеге составында күрсәтелгән кандидат өчен агитация чоры тиешле сайлау комиссиясенә кандидатлар исемлеген биргән көннән башлана. Турыдан-туры күрсәтелгән кандидат өчен агитация чоры сайлау комиссиясенә кандидат булып күрсәтелергә ризалык бирү турында гариза биргән көннән башлана. Агитация чоры тавыш бирү көненә кадәрге көннең җирле вакыт

белән ноль сәгатендә туктатыла.

2. Сайлау алды агитациясе телерадиотапшырулар оешмалары каналларында, вакытлы матбугат басмаларында һәм “Интернет” челтәре басмаларында тавыш бирү көненә 28 көн кала башлана һәм тавыш бирү көненә кадәрге көннең җирле вакыт белән ноль сәгатендә туктатыла.”;

б) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә элек әзерләнгән һәм законда билгеләнгән тәртиптә әлеге Кодексның 64 статьясындагы 8 өлешендә күрсәтелгән махсус урыннарга, әлеге Кодексның 64 статьясындагы 9 һәм 11 өлешләре нигезендә реклама конструкцияләренә яисә башка тотрыклы урнашкан объектларга урнаштырылган басма агитация материаллары (листовкалар, плакатлар һәм башка материаллар) тавыш бирү көнендә шул ук урыннарда сакланырга мөмкин.”;

в) түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

“5. Кабат тавыш бирү үткәрелгән очракта агитация чоры тиешле комиссия тарафыннан кабат тавыш бирү көне билгеләнгән көннән яңартыла һәм әлеге статьяның 2 өлеше нигезендә туктатыла.”;

36) 60 статьяда:

а) исемендә “һәм вакытлы матбугат басмаларында” сүзләрен “, вакытлы матбугат басмаларында һәм “Интернет” челтәре басмаларында” сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 – 9 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Сайлау кампаниясе башланырга кимендә бер ел кала теркәлгән массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы дәүләтнеке булмаган телерадиотапшырулар оешмалары, шулай ук басмаларның теркәлү срогына бәйсез рәвештә сайлау берләшмәләре (шул исәптән аларның структур бүлекчәләре) тарафыннан гамәлгә куелган дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре һәм “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре, күрсәтелгән оешмалар һәм редакцияләр, әлеге статьяның 5 һәм 6 өлешләрендә каралган таләпләрне үтәгән очракта, теркәлгән кандидатларга, сайлау берләшмәләренә түләүле эфир вакыты, түләүле матбугат мәйданы бирергә, “Интернет” челтәре басмаларында агитация материалларын урнаштыру буенча түләүле хезмәтләр күрсәтергә хокуклы. Дәүләтнеке булмаган башка телерадиотапшырулар оешмалары, дәүләтнеке булмаган бүтән вакытлы матбугат басмалары редакцияләре, “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре теркәлгән кандидатларга, сайлау берләшмәләренә эфир вакыты, матбугат мәйданы бирергә хокуксыз.

5. Дәүләтнеке булмаган башка телерадиотапшырулар оешмалары, дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре һәм “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре тарафыннан бирелә торган эфир вакыты, матбугат мәйданы, агитация материалларын урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү шартлары теркәлгән кандидатларга, сайлау берләшмәләренә бертөрле булырга тиеш. Бу таләп кандидатлар, сайлау берләшмәләре тарафыннан гамәлгә куелган

дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләренә, “Интернет” челтәре басмалары редакцияләренә кагылмый.

6. Эфир вакыты, матбугат мәйданы, агитация материалларын урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү күләме (Россия Федерациясе валютасында) һәм башка шартлар турындагы белешмәләр сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырылган) көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча телерадиотапшырулар оешмасы, вакытлы матбугат басмасы редакциясе, “Интернет” челтәре басмасы редакциясе тарафыннан бастырып чыгарылырга тиеш. Күрсәтелгән белешмәләр, аларны бастырып чыгару датасы һәм чыганагы турында мәгълүмат, теркәү номеры һәм массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү хакында таныклыкны бирү турындагы белешмәләр һәм сайлау алды агитациясе алып бару өчен эфир вакыты, матбугат мәйданы бирергә, “Интернет” челтәре басмасында агитация материалларын урнаштыру хезмәте күрсәтергә әзерлеге хакындагы хәбәрнамә белән бергә сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясенә тапшырылырга тиеш.

7. Әлеге статьяның 6 өлешендә күрсәтелгән хәбәрнамәне тиешле комиссиягә шушы өлештә билгеләнгән срокларда тапшырмау юлы белән белдереп, сайлау алды агитациясе алып бару өчен эфир вакыты, матбугат мәйданы, “Интернет” челтәре басмасында агитация материалларын урнаштыру хезмәтләре күрсәтүдән түбәндәгеләр баш тарта ала:

а) дәүләтнеке булмаган телерадиотапшырулар оешмалары һәм дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре;

б) атнага бер мәртәбәдән дә кимрәк чыга торган дәүләт вакытлы матбугат басмалары редакцияләре;

в) махсуслаштырылган телеканаллар, радиоканаллар, телепрограммалар, радиопрограммалар чыгаручы телерадиотапшырулар оешмалары һәм махсуслаштырылган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре;

г) “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре;

д) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар үткәрелгәндә – муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары һәм муниципаль вакытлы матбугат басмалары редакцияләре.

8. Массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар, “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре, милек рәвешенә карамастан, сайлау алды агитациясе алып бару өчен бирелгән эфир вакытының һәм матбугат мәйданының күләмнәрен һәм бәясен, “Интернет” челтәре басмаларында агитация материалларын урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләрнең күләмнәрен һәм бәясен исәпкә алуның тиешле сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән рәвешләре нигезендә аерым исәпкә алып барырга һәм тавыш биргән көннән алып ун көннән дә соңга калмыйча мондый исәпкә алу күрсәткечләрен шушы комиссиягә тапшырырга тиеш.

9. Массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар, “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре түләүсез һәм түләүле рәвештә эфир вакыты һәм матбугат мәйданы бирү, “Интернет” челтәре басмаларында агитация материалларын урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләр турында әлеге статьяның

8 һәм 11 өлешләрендә күрсәтелгән документларны тавыш бирү көненнән алып кимендә өч ел дәвамында сакларга тиеш.";

в) 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"11. Сайлау алды агитациясе алып бару өчен телерадиотапшырулар оешмалары каналларында эфир вакыты һәм вакытлы матбугат басмаларында матбугат мәйданы бирү, "Интернет" челтәре басмаларында агитация материалларын урнаштыру хезмәте күрсәтү телерадиотапшырулар оешмасы, вакытлы матбугат басмасы редакциясе, "Интернет" челтәре басмасы редакциясе белән кандидат, сайлау берләшмәсе арасында күрсәтелгән эфир вакыты, матбугат мәйданы бирелгәнче, хезмәтләр күрсәтелгәнче язма рәвештә төзелгән шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.";

37) 61 статьяда:

а) 4 өлештә икенче һәм өченче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Сайлау берләшмәләренә әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән эфир вакыты бирелгәндә, әгәр күрсәтелгән эфир вакыты күләме, кандидатлар исемлеген теркәгән һәр сайлау берләшмәсенә биш минут яисә аннан артыграк вакыт туры килеп, бер тапкыр булса да уртак агитация чарасы үткәрү өчен җитмәсә, шулай ук тиешле бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округы буенча теркәлгән кандидатларга әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән эфир вакыты күләме һәр кандидатка биш минут яисә аннан артыграк вакыт туры килеп, бер тапкыр булса да уртак агитация чарасы үткәрү өчен җитмәсә, әлеге кагыйдә кулланылмый. Кандидатлар исемлеген теркәгән сайлау берләшмәсе, теркәлгән кандидат уртак агитация чараларында катнашырга тиеш.";

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

"$4^1$. Уртак агитация чараларында теркәлгән кандидатлар шәхсән генә (шул исәптән сайлау берләшмәсе исеменнән тиешле сайлауларда әлеге сайлау берләшмәсе күрсәткән теркәлгән кандидатлар гына) катнаша ала, моңа федераль законда каралган очраклар керми.";

в) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Сайлау берләшмәсе, теркәлгән кандидат тарафыннан әлеге статьяның 4 өлеше таләпләре үтәлмәсә, сайлау берләшмәсенә, теркәлгән кандидатка уртак агитация чарасында катнашу өчен бирелгән эфир вакыты өлеше, федераль законда каралган очраклардан тыш, шушы уртак агитация чарасында башка катнашучылар (шул исәптән, әгәр әлеге чарада бер генә катнашучы катнаша алса да) арасында бүленә.".

г) 9 өлешнең өченче җөмләсендә "Резервланучы" сүзе алдыннан "Әгәр федераль законда башкасы каралмаган булса," сүзләрен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Түләүле эфир вакытын болай бүлгәннән соң бүленмәгән эфир вакыты калса, ул түләү хисабына мондый эфир вакытын бирүгә гариза биргән сайлау берләшмәләренә, теркәлгән кандидатларга бертигез шартларда бирелергә мөмкин.";

38) 62 статьяда:

а) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле икенче яңа җөмлә өстәргә: “Өстәмә яисә кабат сайлаулар үткәрелгәндә түләүсез матбугат мәйданының атналык минималь күләме төп сайлауларда тиешле сайлау округында теркәлгән һәр кандидатка сайлау алды агитациясе үткәрү өчен бирелгән түләүсез матбугат мәйданы күләменнән ким булмаска тиеш.”;

б) 5 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Түләүле матбугат мәйданын болай бүлгәннән соң бүленмәгән матбугат мәйданы калса, ул түләү хисабына мондый матбугат мәйданын бирүгә гариза биргән сайлау берләшмәләренә, теркәлгән кандидатларга бертигез шартларда бирелергә мөмкин.”;

39) 63 статьяның 6 өлешендә “кандидатлар” сүзеннән соң “, кандидатлар исемлеген күрсәткән” сүзләрен өстәргә;

40) 64 статьяда:

а) 1 өлештә “кандидатлар” сүзеннән соң “, кандидатлар исемлеген күрсәткән” сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Басма агитация материаллары әзерләү эшләрен башкаручы яисә аларны әзерләү буенча хезмәт күрсәтүче оешмалар, индивидуаль эшкуарлар кандидатларга, кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләренә шушы материалларны әзерләү өчен түләүнең бертигез шартларын тәэмин итәргә тиеш. Күрсәтелгән оешмаларның, индивидуаль эшкуарларның басма агитация материалларын әзерләү эшләре яисә аларны әзерләү буенча хезмәт күрсәтүләре өчен түләү күләме (Россия Федерациясе валютасында) һәм башка шартлар турындагы белешмәләр тиешле оешма, тиешле индивидуаль эшкуар тарафыннан сайлауларны билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан (бастырып чыгарылган) көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарылырга һәм шул ук срокта сайлауларны оештыручы комиссиягә тапшырылырга тиеш. Күрсәтелгән белешмәләр белән бергә сайлауларны оештыручы комиссиягә шулай ук оешманың исеме, юридик адресы һәм салым түләүченең идентификация номеры (индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның яшәү урыны урнашкан Россия Федерациясе субъекты, район, шәһәр, башка торак пункт исеме) булган белешмәләр тапшырылырга тиеш.”;

в) 4 өлештә “фотографияләре” сүзеннән соң “яисә нөсхәләре” сүзләрен, икенче җөмләдә “белешмәләр” сүзеннән соң “һәм шушы агитация материалын әзерләү өчен тиешле сайлау фондыннан түләү хакындагы документның күчермәсе” сүзләрен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле яңа җөмлә өстәргә: “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар үткәрелгәндә, шулай ук җирле үзидарә органнарына сайлаулар үткәрелгәндә күрсәтелгән материаллар белән бергә комиссиягә әлеге сайлау алды агитациясе материалларының машинада укырлык электрон рәвешләре дә тапшырылырга тиеш.”;

г) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6. Басма агитация материалларын әлеге статьяның 2 өлешендә каралган таләпләрне үтәмәгән оешмаларда һәм индивидуаль эшкуарларда, йә индивидуаль эшкуарлар булмаган физик затлар белән шартнамә нигезендә әзерләү, шулай ук

агитация материалларын тиешле сайлау фонды акчалары исәбеннән алдан түләмичә, әлеге Кодексның 58 статьясындагы 7, 8, һәм $9^1$ һәм $10^1$ өлешләрендә, әлеге статьяның 3 өлешендә билгеләнгән таләпләрне бозып әзерләү тыела.";

д) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7. Әлеге статьяның 6 өлешен бозып һәм (яисә) әлеге статьяның 4 өлешендә, әлеге Кодексның 58 статьясындагы 10 өлешендә каралган таләпләрне бозып әзерләнгән агитация материалларын тарату тыела.";

е) 9 өлештә "эленергә (ябыштырылырга, урнаштырылырга)" сүзләрен "урнаштырылырга" сүзенә алмаштырырга;

ж) 10 һәм 11 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10. Агитация материалларын әзерләү һәм урнаштыру эшләрен башкаручы (алар буенча хезмәт күрсәтүче) оешмалар, индивидуаль эшкуарлар кандидатларга, сайлау берләшмәләренә үз эшләре (хезмәт күрсәтүләре) өчен түләүнең бертигез шартларын тәэмин итәргә тиеш.

11. Агитация материалларын һәйкәлләрдә, обелискларда, тарихи, мәдәни яисә архитектура ягыннан әһәмияткә ия биналарда, корылмаларда һәм урыннарда урнаштыру тыела. Агитация материалларын сайлау комиссияләре, тавыш бирү урыннары урнашкан биналарда һәм аларга кереп йөрү юлларыннан 50 метрдан кимрәк булган урыннарда урнаштыру тыела.";

41) 66 статьяда:

а) 4 өлештә "ә алар булмаган очракта, – Россия Федерациясе Саклык банкы филиалларында" сүзләрен "ә сайлау комиссиясе урнашкан торак пункт чикләрендә алар булмаган очракта, "Россия Саклык банкы" гавами акционер җәмгыяте филиалларында" сүзләренә алмаштырырга;

б) 12 өлештә "бюллетеньнәрне, махсус билгеләрне (маркаларны)" сүзләрен "бюллетеньнәрне, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын, махсус билгеләрне (маркаларны), сайлау комиссияләре урыннарында һәм тавыш бирү урыннарында урнаштырыла торган мәгълүмати материалларны, референдум әзерләүгә һәм уздыруга бәйле документларны, сайлау комиссияләренең башка җибәрелгән әйберләрен китереп кую буенча хезмәт күрсәтүләрне" сүзләренә алмаштырырга, "бюллетеньнәр" сүзеннән соң "бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары" сүзләрен өстәргә;

42) 69 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Сайлау фондын барлыкка китерүче барлык акчалар тиешле комиссия рөхсәте белән кандидат йә аның финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкиле, сайлау берләшмәсенең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкиле тарафыннан "Россия Саклык банкы" гавами акционер җәмгыятенең филиалында, ә ул сайлау округы территориясендә булмаганда (муниципаль сайлаулар үткәргәндә – ул тиешле муниципаль район, шәһәр округы территориясендә булмаганда) тиешенчә сайлау округы, муниципаль район, шәһәр округы территориясендә урнашкан башка кредит оешмасында ачылган махсус сайлау счетына күчерелә. Тиешенчә сайлау округы, муниципаль район, шәһәр округы территориясендә кредит оешмалары

булмаган очракта, кандидат, сайлау берләшмәсе, тиешле комиссия белән килештереп, кредит оешмасын билгели, анда махсус сайлау счеты ачыла.";

б) 4 өлешнең беренче абзацында "сайтына" сүзен "рәсми сайтына" сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә::

"6. Законда каралган һәм анда билгеләнгән тәртип нигезендә рәсмиләштерелгән документларны күрсәткәч, "Россия Саклык банкы" гавами акционер җәмгыятенең, ә "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законда билгеләнгән очракларда – башка кредит оешмасының филиаллары кичекмәстән махсус сайлау счетын ачарга тиеш. Счет ачу һәм счет буенча операцияләр башкару буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү алынмый. Счеттагы акчалардан файдаланган өчен процентлар исәпләнми һәм түләнми. Барлык акчалар счетка Россия Федерациясе валютасында күчерелә.";

43) 70 статьяда:

а) 4 өлештә ", әлеге Кодексның 69 статьясындагы 1 өлеше нигезендә сайлау фонды махсус сайлау счеты ачмыйча төзелгән очрактан тыш" сүзләрен өстәргә;

б) 9 өлештә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Кандидат әлеге Кодексның 67 статьясындагы 1 өлеше нигезендә сайлау фонды төземәгән очракта аннан финанс хисаплары тапшыру таләп ителми.";

44) 72 статьяда:

а) 1 өлештә "39 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты һәм $1^1$ өлеше" сүзләрен "39 статьясындагы 2 өлешенең 4 пункты һәм 3 өлеше" сүзләренә, "39 статьясындагы $1^3$ өлешендә" сүзләрен "39 статьясындагы 5 өлешендә" сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә "Россия Федерациясе Саклык банкы" сүзләрен "Россия Саклык банкы" гавами акционер җәмгыяте" сүзләренә алмаштырырга;

в) 5 өлешнең 2 пунктында "39 статьясындагы $1^3$ өлешендә" сүзләрен "39 статьясындагы 5 өлешендә" сүзләренә алмаштырырга;

45) 73 статьяның 3 өлешендә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5) кандидатларның сайлауларны оештыручы комиссия тарафыннан билгеләнгән күләмдә керемнәре һәм мөлкәте турында белешмәләр;";

6 пунктта "39 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләре" сүзләрен "39 статьясындагы 1 өлешендә, 2 өлешендәге 4 пунктында һәм 6 өлешендә" сүзләренә алмаштырырга;

46) түбәндәге эчтәлекле $73^1$ статья өстәргә:

"$73^1$ статья. **Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы**

1. Әлеге Законның $76^1$ статьясындагы 2 өлешендә каралган очракларда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү уздырыла.

2. Үзе сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлау участогының тавыш бирү бинасына тавыш бирү көнендә килү мөмкинлеге булмаган сайлаучы тиешле

федераль законда билгеләнгән срокларда территория комиссиясендә (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә, округ сайлау комиссиясендә) йә участок комиссиясендә бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын алырга һәм, сайлаучы актив сайлау хокукына ия булган сайлау округы чикләрендә тавыш бирү көнендә кайсы сайлау участогында булса, шул сайлау участогында тавыш бирүдә катнашырга хокуклы. Кабат тавыш бирү үткәрелгән очракта, сайлаучы кабат тавыш бирү көне билгеләнгән көннән тиешле участок комиссиясендә кабат тавыш бирү көненә бер көн кала өзелмә талоннан башка бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын алырга хокуклы.

3. Закон нигезендә бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү каралган төрле дәрәҗәдәге сайлаулар һәм референдумнар уздырылганда әлеге тавыш бирү көннәре берләштерелгән очракта, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары югарырак дәрәҗәдәге сайлаулар һәм (яисә) референдумнар уздыру тәртибен җайга сала торган законда билгеләнгән срокларда бирелә.

4. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары катгый хисаплылык документлары булып тора һәм сайлаулар уздыруның бөтен территориясендә бердәй нумерациягә ия була. Кабат сайлаулар үткәрү каралган сайлауларда файдаланыла торган бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының өзелмә талоны булырга тиеш. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законның 2 нче яисә 3 нче кушымтасы нигезендәге рәвеш буенча әзерләнә. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы тексты, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының рәвеше, тавыш бирү көненә кадәр 60 көннән дә соңга калмыйча, сайлауларны оештыручы комиссия тарафыннан раслана. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын әзерләгәндә шулай ук аларны охшатып ясаудан саклау алымнары да күрсәтелгән комиссия тарафыннан билгеләнә.

5. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын охшатып ясаудан саклау максатларында, аларны әзерләгәндә су билгеләре булган һәм (яисә) типография ысулы белән төшерелгән микрошрифтлы язу һәм (яисә) саклау челтәре булган кәгазь һәм (яисә) бүтән махсус саклау элементлары кулланыла.

6. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын сатып алу сайлауларны оештыручы комиссия тарафыннан аның карары нигезендә үзәкләштерелгән рәвештә гамәлгә ашырыла.

7. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән сайлау комиссиясе сайлаучының бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы таләп ителүнең сәбәбе күрсәтелгән язма гаризасы нигезендә бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын сайлаучының шәхсән үзенә йә нотариаль таныкланган ышанычнамә нигезендә аның вәкиленә тапшыра. Ышанычнамә шулай ук стационар дәвалау-профилактикалау учреждениесе администрациясе тарафыннан (әгәр сайлаучы шул учреждениедә дәвалана торган булса), шик белдерелгән яисә гаепләнүче затлар сак астында тотыла торган учреждение администрациясе тарафыннан да (әгәр сайлаучы шик белдерелгән яисә гаепләнүче зат буларак шул учреждениедә тотылса) таныкланырга мөмкин.

8. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын бирүче комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы әлеге таныклыкка сайлаучының фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын, сайлаучы сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлау участогының номерын, участок комиссиясенең адресын, муниципаль берәмлекнең һәм Россия Федерациясе субъектының исемнәрен, территориясендә сайлау участогы төзелгән бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округының номерын һәм (яисә) исемен (сайлаулар бермандатлы һәм (яисә) күпмандатлы сайлау округлары буенча үткәрелсә), бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын биргән комиссиянең исемен кертә. “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон һәм әлеге Кодекс нигезендә сайлауларда кабат тавыш бирү үткәрелергә мөмкин булса, сайлаучы, сайлау участогы һәм тиешле комиссия турында күрсәтелгән белешмәләр шулай ук бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының өзелмә талонына кертелә. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын бирүче комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгында үзенең фамилиясен һәм инициалларын, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән датаны күрсәтә, имза сала һәм тиешле комиссиянең мөһерен суга.

9. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын (сайлауларда кабат сайлаулар үткәрелгән очракта – өзелмә талоннан башка бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын) алганда, сайлаучы бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының тиешле графаларында үз паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын күрсәтә һәм имза сала. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрында сайлаучының яшәү урыны адресы күрсәтелергә тиеш. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын сайлаучы вәкиле ышанычнамә нигезендә алган очракта, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының яисә сайлаучылар исемлегенең тиешле графаларында сайлаучы паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясе һәм номеры күрсәтелә, бу чакта сайлаучы вәкиле үзенең фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын күрсәтә һәм имза сала. Шуннан соң сайлаучы вәкиленнән ышанычнамә алына һәм тиешенчә бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрына, сайлаучылар исемлегенә кушып куела.

10. Сайлаучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын биргән территория комиссиясе (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе) рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының тиешле графаларында бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтә һәм имза сала. Территория комиссиясе (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе) тавыш бирү көненә кадәр участок комиссияләренә сайлаучылар исемлегенең беренче нөсхәсе белән бергә бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрыннан таныкланган өземтәләрне

җибәрә, аларда тиешле сайлау участоклары территорияләрендә теркәлгән, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары алган сайлаучылар турында белешмәләр күрсәтелә. Тиешле өземтә нигезендә участок комиссиясе әгъзасы сайлаучылар исемлегенең тиешле графасында, бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтеп, "Территория комиссиясендә (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә, округ сайлау комиссиясендә)_____ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы алды" дигән тамга куя һәм имза сала.

11. Участок комиссиясендә сайлаучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгәндә, сайлаучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын биргән участок комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтеп, "_____ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы алды" дигән тамга куя һәм имза сала.

12. Үзенә бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән сайлаучы (шул исәптән ышанычнамә нигезендә аның вәкиле аша) шушы сайлауларда участок комиссиясе тарафыннан тиешле сайлау участогында сайлаучылар исемлегеннән төшереп калдырыла һәм, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсе төзелгәндә, теркәлгән сайлаучылар рәтендә исәпкә алынмый.

13. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын кабат бирү рөхсәт ителми. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын югалткан очракта, аның дубликаты бирелми.

14. Файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары тавыш бирү көнендә тавыш бирү вакыты башланганчы юкка чыгарыла. Кабат тавыш бирү үткәрелгән очракта, тиешле сайлау комиссиясе кабат тавыш бирү көнен билгеләгән көннән алып кабат тавыш бирү көненнән алдагы көнгә кадәр чорда сайлаучыларга бирелгән файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының өзмә талоннары юкка чыгарыла. Кабат тавыш бирү көнендә тавыш бирү вакыты башланганчы файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары өзмә талоннары белән бергә юкка чыгарыла. Файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын һәм өзмә талоннарны юкка чыгару турында тиешле сайлау комиссиясе тарафыннан, мондый таныклыкларның һәм талоннарның санын күрсәтеп, акт төзелә. Әгәр теркәлгән кандидат гомуми сайлаулар нәтиҗәсендә сайланган булса йә гомуми сайлаулар булмаган яисә гамәлдә түгел дип танылса, файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары өзмә талоннары белән бергә гомуми сайлаулар нәтиҗәләре рәсми басылып чыкканнан соң өченче көнне юкка чыгарыла. Файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын һәм өзмә талоннарны юкка чыгару турындагы белешмәләр, аларның санын һәм бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының номерларын күрсәтеп, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе раслаган рәвештә төзелгән актка тиешле сайлау комиссиясе тарафыннан кертелә.

15. Сайлаучы, тавыш бирү көнендә бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын күрсәткәч, тавыш бирү көнендә булачак сайлау участогында өстәмә рәвештә сайлаучылар исемлегенә кертелә. Участок комиссиясе сайлаучылар исемлегенең тиешле графасында, сайлаучы тарафыннан күрсәтелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтеп, "____ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш бирде" дигән тамга куя. Шуннан соң, сайлауларда

кабат тавыш бирү каралган очрактан тыш, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы сайлаучыдан кире алына. Мондый очракта гомуми сайлаулар уздырылганда сайлаучыдан өзмә талон, ә кабат тавыш бирү үткәрелгәндә бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы кире алына. Сайлаучыларны сайлаучылар исемлегенә кертү өчен нигез булган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары (өзмә талоннар) шушы исемлек белән бергә саклана.

16. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының бланкы югалган очракта, мондый югалу фактын билгеләгән комиссия кичекмәстән тиешле акт төзи һәм карар кабул итә, анда бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының югалган бланкы номеры, бланкның югалу факты һәм югалу сәбәбе күрсәтелә. Бу карар шул ук көнне турыдан-туры югарырак комиссиягә һәм сайлауларны оештыручы комиссиягә җиткерелә. Сайлауларны оештыручы комиссия шушы карар нигезендә тиешле бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын гамәлгә яраксыз дип таный, шул хакта барлык түбәнгерәк комиссияләргә кичекмәстән хәбәр ителә. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү гражданнарның сайлау хокукы бозылуга китергән башка очракларда, мондый бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары сайлауларны оештыручы комиссия тарафыннан шулай ук гамәлгә яраксыз дип танылырга мөмкин. Гамәлгә яраксыз бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы сайлаучыны сайлаучылар исемлегенә кертү өчен нигез була алмый. Сайлаучы мондый бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын күрсәткәндә, бу таныклык кире алынырга тиеш.

17. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын комиссияләргә тапшыру һәм бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын исәпкә алу тәртибе, шул исәптән “Сайлаулар” ДАС кулланып, “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана.”;

47) 75 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $5^2$ өлеш өстәргә:

“$5^2$. Тавыш бирү өчен үтә күренмәле тартмалардан файдаланган очракта, бюллетень рәвеше тавыш бирү серен саклау зарурлыгын истә тотып билгеләнә, моңа сайлауларны оештыручы комиссия карары белән әлеге максатларда конвертлар куллану очрагы керми.”;

б) 6 өлештә:

1 пунктта “атасының исеме;” сүзләрен “атасының исеме. Әгәр ике һәм аннан күбрәк кандидатның фамилиясе, исеме һәм аталарының исеме тулысынча туры килсә, кандидатлар турында белешмәләр бюллетеньгә кандидатларның туган көннәре буенча урнаштырыла (беренче булып өлкәнрәк кандидат турында белешмәләр күрсәтелә), шул ук вакытта кандидат сайлау кампаниясе чорында йә сайлауларны билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан (бастырып чыгарган) көннән алып бер ел эчендә фамилиясен, яисә исемен, яисә атасының исемен үзгәрткән булса, бюллетеньдә шулай ук кандидатның элеккеге фамилиясе, исеме, атасының исеме күрсәтелә;” сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“б) әгәр кандидат сайлау берләшмәсе тарафыннан күрсәтелгән булса, – тиешле сәяси партия, әлеге Кодексның 32 статьясындагы 2 өлеше нигезендә башка иҗтимагый берләшмә исеме күрсәтелеп, “тарафыннан күрсәтелде” сүзләре;

в) 7 өлештә “39 статьясындагы 2 өлеше” сүзләрен “39 статьясындагы 6 өлеше” сүзләренә алмаштырырга, “шул сәяси партиянең, башка иҗтимагый берләшмәнең кыскача исеме” сүзләрен “шул сәяси партиянең, әлеге Кодексның 32 статьясындагы 2 өлеше нигезендә башка иҗтимагый берләшмәнең исеме” сүзләренә алмаштырырга;

г) 8 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

д) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9. Кандидатлар исемлеге өчен тавыш бирү үткәрелгәндә, бюллетеньдә шобага салу ярдәмендә билгеләнгән тәртиптә сайлау берләшмәләренең кыскача исемнәре, шулай ук исемлектәге кимендә беренче өч кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм сайлау берләшмәләренең эмблемалары (әгәр алар тиешле комиссиягә тапшырылган булса) бер төстә эшләнеп күрсәтелә.”;

е) 20 өлештә “әлеге үзгәрешләр” сүзен “йә әлеге статьяның 12 өлешендә каралган очракта тиешле үзгәрешләр” сүзләренә алмаштырырга;

48) 76 статьяда:

а) 1 өлештә “яшәү урынындагы” сүзләреннән соң “(тору урынындагы)” сүзләрен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Әлеге Кодексның 21 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән затларга тавыш бирү бинасына керү мөмкинлеге тавыш бирү башланырга кимендә бер сәгать алдан тәэмин ителергә тиеш.”;

б) 2 өлештә “Тавыш бирү вакыты” сүзләрен “Тавыш бирү көне, вакыты” сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

“$2^1$. Хәрби частьләрдә оештырылган сайлау участокларында сайлаучылар исемлегенә кертелгән барлык сайлаучылар тавыш биргән булса, участок комиссиясе тавыш бирүнең әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә билгеләнгән вакыттан алданрак тәмамлануын игълан итәргә мөмкин.”;

г) 5 өлешкә түбәндәге сүзләр өстәргә: “, әгәр сайлаучы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш бирсә, шулай ук бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы да күрсәтелә”;

д) 9 өлешкә түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче җөмлә өстәргә: “Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш биргән очракта, сайлаучылар исемлегендә өстәмә тамгалар салына.”;

е) 13 өлештә “сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле,” сүзләреннән соң “финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкиле,” сүзләрен өстәргә;

ж) 14 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Сайлауларны оештыручы комиссия тарафыннан әлеге Кодексның 75 статьясындагы $5^2$ өлеше нигезендә конвертлардан файдалану турында карар кабул ителгән булса, сайлаучы тутырылган бюллетеньне (тутырылган бюллетеньнәрне) кабинадан яисә яшерен тавыш бирү өчен махсус җиһазландырылган башка урыннан читтә участок комиссиясенең

хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы биргән конвертка сала, ябыштыра, шуннан соң шул конвертны тавыш бирү әрҗәсенә төшерә.";

з) түбәндәге эчтәлекле $14^1$ һәм $14^2$ өлешләр өстәргә:

"$14^1$. Участок комиссиясе рәисе тавыш бирү бинасында тәртипне күзәтеп тора. Участок комиссиясе рәисенең үз компетенциясе чикләрендә бирелгән күрсәтмәләре тавыш бирү бинасында булганнарның барысы өчен дә мәҗбүри. Участок комиссиясе рәисе булмаганда аның вәкаләтләрен участок комиссиясе рәисе урынбасары, ә участок комиссиясе рәисе урынбасары булмаганда – секретарь яисә участок комиссиясенең ул вәкаләт биргән хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы башкара.

$14^2$. Тавыш бирүне үткәргәндә, сайлаучылар тавышын санаганда һәм тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсен төзегәндә тавыш бирү бинасында, участок комиссиясе бинасында әлеге Кодексның 21 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән затлар булырга хокуклы. Күзәтеп тору вакыты дәвамында бу затлар өзлексез, шулай ук үзләре сайлаган вакыт аралыгында ирекле күзәтеп торырга хокуклы, тавыш бирү үткәрелә һәм сайлаучылар тавышы исәпләнә торган бинага (биналарга) аларга иркен кереп йөрү мөмкинлеге бирелә. Тавыш бирү барышын һәм сайлаучылар тавышын санауны күзәтеп торучы затлар исемлеге әлеге затлар тапшырган документлар нигезендә участок комиссиясе тарафыннан төзелә.";

и) 15 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"15. Участок комиссия әгъзасы, күзәтүче һәм башка затлар тарафыннан сайлаулар турындагы законнар бозылса һәм мондый факт суд тәртибендә расланса, участок комиссиясе әгъзасы комиссия эшендә катнашудан шунда ук читләштерелә, ә күзәтүче һәм башка затлар тавыш бирү бинасыннан чыгарыла. Тиешле суд карарын үтәү "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон нигезендә хокук саклау органнары тарафыннан тәэмин ителә. Хокук саклау органнары шулай ук тавыш бирү бинасында һәм сайлау участогы территориясендә федераль законнар нигезендә гражданнарның иминлеген һәм җәмәгать тәртибен тәэмин итәргә тиеш.";

49) $76^1$ статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда, җирле үзидарә органнарына сайлауларда тавыш бирү көне законда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү каралган федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда тавыш бирү көне белән берләштерелгән очракта, әлеге статьяның 1 өлешендә каралган алдан тавыш бирү үткәрелми. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына күрсәтелгән сайлауларны, җирле үзидарә органнарына сайлауларны үткәргәндә, сайлау округының чикләре бер сайлау участогы кысаларына туры килгән сайлаулардан тыш, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш бирү уздырыла.";

б) 9 өлештә “соңга калмыйча” сүзләреннән соң “йә участок комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш бирү көненә кадәрге көннән дә соңга калмыйча” сүзләрен өстәргә”;

50) 77 статьяда:

а) 1 өлештәге беренче җөмләдә “исемлегенә кертелгән” сүзләрен “исемлегенә кертелүгә хокуклы яисә кертелгән” сүзләренә алмаштырырга, татарча текстта икенче җөмлә үзгәрешсез кала;

б) 2 өлештә “(телдән мөрәҗәгатьләрне)” сүзләреннән соң “гариза (телдән мөрәҗәгать) бирелгән көнне үк” сүзләренә алмаштырырга;

в) 9 өлештә “гаризалар (телдән мөрәҗәгатьләр) буенча чыгучы” сүзләрен “тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне үткәрүче хәлиткеч тавыш хокукына ия” сүзләренә алмаштырырга, “китү мизгеленә” сүзләрен “комиссия әгъзаларының китү (чыгу) мизгеленә” сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче җөмлә өстәргә: “Тиешле сайлаучыга участок комиссиясе әгъзалары китү (чыгу) турында сайлаучылар исемлегенә тамга ясала.”;

51) 78 статьяга түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

“$4^1$. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү уздырылганда тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә шулай ук түбәндәге юллар өстәлә:

11а юл: участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

11б юл: тавыш бирү көненә кадәр сайлаучыларга участок комиссиясе тарафыннан сайлау участогында бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

11в юл: сайлау участогында бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән сайлаучылар саны;

11г юл: сайлау участогында юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

11д юл: сайлаучыларга территория комиссиясе (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе) тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

11е: юкка чыккан бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары.”;

52) 79 статьяда:

а) 1 өлештә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Әлеге Кодексның 21 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән затларга сайлаучылар тавышын санаганда шунда булу һәм санауны күзәтеп тору мөмкинлеге бирелергә тиеш.”;

б) 3 өлештә түбәндәге эчтәлекле икенче җөмлә өстәргә: “Шуннан соң участок комиссиясе әгъзалары файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын саныйлар, игълан итәләр һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 11г юлына язып куялар.”, “юкка чыгарылган бюллетеньнәр” сүзләреннән соң “һәм бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары” сүзләрен өстәргә;

в) 4 өлештә беренче җөмләгә түбәндәге сүзләрне өстәргә: “, шулай ук участок сайлау комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары санын игълан итә һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 11а юлына язып куя”;

г) 5 өлештә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) тавыш бирү тәмамланган мизгелгә сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар санын (территория комиссиясе (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе) һәм участок комиссиясе тарафыннан бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирелгән сайлаучыларны, шулай ук башка сәбәпләр аркасында киткән сайлаучыларны исәпкә алмыйча);”;

түбәндәге эчтәлекле $3^2$–$3^4$ пунктлар өстәргә:

“$3^2$) сайлаучыларга участок комиссиясе тарафыннан сайлау участогында бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

$3^3$) сайлаучыларга территория комиссиясе (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе) тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

$3^4$) сайлау участогында бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән сайлаучылар саны.”;

д) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6. Әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән күрсәткечләр кертелгәннән соң сайлаучылар исемлегенең һәр битенә комиссиянең әлеге күрсәткечләрне керткән әгъзасы имза сала, аннан соң ул шушы күрсәткечләрне кушып берләштерә, игълан итә һәм участок комиссиясе рәисенә, рәис урынбасарына яисә секретарена һәм тавышларны санаганда шунда булган затларга хәбәр итә. Әлеге статьяның 5 өлеше нигезендә билгеләнгән күрсәткечләр суммасы буларак билгеләнүче йомгаклау күрсәткечләрен участок комиссиясе рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре игълан итә, сайлаучылар исемлегенең соңгы битенә кертә, аларны үз имзасы һәм участок комиссиясе мөһере белән таныклый. Игълан ителгән күрсәткечләр тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең тиешле юлларына, тавышларны санауның техник чаралары кулланылган очракта – беркетмәнең зурайтылган рәвешенең түбәндәге тиешле юлларына гына кертелә:

1) 1 юлга – тавыш бирү тәмамланган мизгелгә сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар саны;

2) 3 һәм 4 юлларда – вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

3) 5 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

4) 6 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

5) 11а юлга – участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

6) 11б юлга – сайлаучыларга участок комиссиясе тарафыннан сайлау участогында бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

7) 11в юлга – сайлау участогында бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән сайлаучылар саны;

8) 11г юлга – сайлау участогында юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

9) 11д юлга – сайлаучыларга территория комиссиясе (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе) тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны.

Әлеге гамәлләрне башкарганнан соң түбәндәге контроль чагыштырманы тикшерү уздырыла: участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны тавыш бирү көненә кадәр сайлау участогында сайлаучыларга участок комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны һәм сайлау участогында юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны суммасына тигез булырга тиеш. Әгәр әлеге контроль чагыштырма үтәлмәсә, участок комиссиясе сайлаучылар исемлегенә кертелгән күрсәткечләрне һәм юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын өстәмә санау турында карар кабул итә. Әгәр өстәмә санау нәтиҗәсендә әлеге контроль чагыштырма тагын да үтәлмәсә, участок комиссиясе тиешле карар кабул итә, карар тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кушып бирелә, һәм участок комиссиясе аерма турындагы күрсәткечләрне тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 11е юлына кертә. Әгәр әлеге контроль чагыштырма үтәлсә, 11е юлында “0” цифры куела.

Бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү каралган булса, тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 11а, 11б, 11в, 11г, 11д, һәм 11е юлларына күрсәткечләр кертелә.

Шуннан соң күзәтүчеләр һәм әлеге Кодексның 21 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затлар сайлаучылар исемлеге белән танышырга хокуклы, ә участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары башкарылган санауның дөреслегенә инанырга хокуклы.”;

е) 12 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“12. Бюллетеньнәрне сортировкалаганда участок комиссиясе билгеләнмәгән рәвештәге, ягъни рәсми булмаган рәвештә әзерләнгән йә күрсәтелгән комиссия тарафыннан таныкланмаган яисә махсус билгесе (маркасы) булмаган (ул кулланылган очракта) бюллетеньнәрне аерып куя. Билгеләнмәгән рәвештәге бюллетеньнәр тавышларны санаганда исәпкә алынмый. Мондый бюллетеньнәр аерым төреп куела һәм аларга мөһер сугыла.”;

ж) 22 өлештә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларын һәм күзәтүчеләрне сортировкаланган бюллетеньнәр белән таныштырганнан соң тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләргә кертелгән күрсәткечләрнең контроль чагыштырмаларына (әлеге статьяның 6 өлеше нигезендә тикшерү үткәрелә торган контроль чагыштырмалардан тыш), әлеге Кодекста каралган тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең юллары нумерациясен истә тотып, әлеге Кодексның 2 нче кушымтасы нигезендә тикшерү үткәрелә.”;

з) 23 өлешнең дүртенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Шул рәвешле җыеп куелган бюллетеньнәр, шулай ук әлеге статьяның 12 һәм 13 өлешләре нигезендә төргәкләнгән бюллетеньнәр, төргәкләнгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары, сайлаучылар исемлеге капчыкларга яисә тартмаларга тутырыла, аларда сайлау участогы номеры, төргәкләнгән барлык бюллетеньнәрнең гомуми саны, төргәкләнгән барлык бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының гомуми саны күрсәтелә.”;

и) 28 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Беркетмәнең күчермәсе күчермә ясау техникасын кулланмыйча әзерләнгән очракта, беркетмәнең күчермәсендә участок комиссиясе әгъзаларының фамилияләрен, исемнәрен һәм аталарының исемнәрен күрсәтү һәм аларның имзаларын кую таләп ителми.”;

53) 80 статьяда:

а) 7 өлештә түбәндәге эчтәлекле икенче һәм өченче җөмләләр өстәргә: “Тавыш бирү йомгаклары турындагы (сайлауларның нәтиҗәләре турындагы) беркетмәгә шулай ук тиешле комиссия тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, түбәнгерәк комиссияләргә бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, тиешле комиссия тарафыннан юкка чыгарылган файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны һәм тиешле комиссиядә югалган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны хакында күрсәткечләр кертелә. Комиссия (участок комиссиясенә караганда турыдан-туры югарырак комиссиядән тыш) тарафыннан төзелә торган тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы (сайлауларның нәтиҗәләре турындагы) җыелма таблицага шулай ук тиешле комиссия тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, түбәнгерәк комиссияләргә бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, тиешле комиссия тарафыннан юкка чыгарылган файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны һәм тиешле комиссиядә югалган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны хакында түбәнгерәк комиссия беркетмәсе күрсәткечләре кертелә.”;

б) 9 өлештәге икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Җыелма таблица ике нөсхәдә төзелә һәм комиссия рәисе (рәис урынбасары) һәм секретаре тарафыннан имзалана.”;

в) 13 өлештә:

“хокуклы» сүзен “тиеш” сүзенә алмаштырырга;

“беркетмәнең 1 – 13 юлларына һәм (яисә) җыелма таблицага” сүзләрен “беркетмәнең 1 – 13 юлларына (законда бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш бирү каралган очракта 11а – 11е юлларына) һәм (яисә) җыелма таблицага” сүзләренә алмаштырырга”;

54) 82 статьяда:

а) “бюллетеньнәрне” сүзеннән соң “, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын” сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлештә “бюллетеньнәрне” сүзеннән соң “, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын” сүзләрен өстәргә;

55) “Сайлаулар” ДАСтагы” сүзләрен “Сайлаулар” ДАСка кертелә торган һәм тавыш бирү йомгакларын, сайлаулар нәтиҗәләрен билгеләүгә бәйле рәвештә аннан чыгарыла торган” сүзләренә алмаштырырга;

56) 91 статьяга түбәндәге эчтәлекле 12[1] пункт өстәргә:

“12[1]) “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда һәм әлеге Кодекста каралган очракларда Дәүләт Советы депутатларын сайлауларда тавыш бирү өчен бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары текстын билгели, күрсәтелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын әзерләүне һәм сайлау комиссияләрендә аларның булуын тәэмин итә;”;

57) 93 статьяда:

а) 10 пунктта “әлеге Кодексның 28 статьясындагы 3 һәм 4 өлешләрендә каралган очраклардан гайре,” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 13[1] пункт өстәргә:

“13[1]) “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда һәм әлеге Кодекста каралган очракларда сайлаучыларга бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирә;”;

58) 95 статьяның 4 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 2[1] пункт өстәргә:

“2[1]) территория комиссиясе тарафыннан сайлаучыларга бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирү турында, аларны участок комиссияләренә тапшыру турында, шулай ук файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын юкка чыгару турында бу таныклыкларның саны һәм номеры күрсәтелгән актлар;”;

59) 102 статьяның 2 өлешендә “Татарстан Республикасы Дәүләт Советына төп сайлаулар сентябрьнең икенче якшәмбесендә уздырылса һәм аларның нәтиҗәләре буенча” сүзләрен төшереп калдырырга;

60) 103 статьяда:

а) 1 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 1[3] өлеш өстәргә:

“1[3]. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карар кабул иткән көннән алып 14 көн эчендә сәяси партия, аның региональ бүлекчәсе әлеге статьяның 1[1] өлешендә каралган хокукыннан файдаланмаса, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе вакантлы депутат мандатын әлеге Кодексның 98 статьясындагы 6 өлешендә каралган тәртиптә кандидатларның составында вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган Дәүләт Советы депутаты сайланган шул ук республика исемлегеннән теркәлгән башка кандидатка тапшыра.”;

в) 5 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

“7) теркәлгән кандидатны депутат буларак, шул исәптән бермандатлы яисә күпмандатлы сайлау округы буенча теркәү турында тиешле сайлау комиссиясе тарафыннан карар кабул ителгән.”;

61) 104 статьяның 2 өлешендә “исәпкә алып, сентябрьнең икенче якшәмбесенә” сүзләреннән соң “, ә чираттагы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны уздыру елында шушы сайлауларда тавыш бирү көненә” сүзләрен өстәргә;

62) $104^5$ статьяның 3 өлешендә “челтәрендәге үз” сүзләрен “челтәрендә үзенең рәсми” сүзләренә алмаштырырга;

63) $104^8$ статьяга түбәндәге эчтәлекле $11^1$ пункт өстәргә:

“$11^1$) “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда һәм әлеге Кодекста каралган очракларда Татарстан Республикасы Президентын сайлауларда тавыш бирү өчен бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы текстын билгели, күрсәтелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын әзерләүне һәм сайлау комиссияләрендә аларның булуын тәэмин итә;”;

64) $104^9$ статьяда:

а) 10 пунктта “әлеге Кодексның 28 статьясындагы 3 һәм 4 өлешләрендә каралган очраклардан гайре,” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $13^1$ пункт өстәргә:

“$13^1$) “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда һәм әлеге Кодекста каралган очракларда сайлаучыларга бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирә;”;

65) $104^{11}$ статьяның 4 өлешендә түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

“$2^1$) территория комиссиясе тарафыннан сайлаучыларга бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирү турында, аларны участок комиссияләренә тапшыру турында, шулай ук файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының өзмә талоннарын юкка чыгару турында бу таныклыкларның саны һәм номерлары күрсәтелгән (кабат тавыш бирү үткәрелгәндә – файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын юкка чыгару турында бу таныклыкларның саны һәм номерлары күрсәтелгән) актлар;”;

66) $104^{16}$ статьяның 2 өлешендә “Татарстан Республикасы Президентын төп сайлаулар сентябрьнең икенче якшәмбесендә уздырылса һәм аларның нәтиҗәләре буенча” сүзләрен төшереп калдырырга;

67) 108 статьяда түбәндәге эчтәлекле $16^1$ пункт өстәргә:

“$16^1$) “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда

һәм әлеге Кодекста каралган очракларда муниципаль сайлаулар үткәргәндә тавыш бирү өчен бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы текстын билгели, күрсәтелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын әзерләүне һәм сайлау комиссияләрендә аларның булуын тәэмин итә;";

68) 122 статьяда:

а) 1 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $3^3$ өлеш өстәргә:

"$3^3$. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карар кабул иткән көннән алып 14 көн эчендә сәяси партия, аның региональ бүлекчәсе әлеге статьяның $3^1$ өлешендә каралган хокукыннан файдаланмаса, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе вакантлы депутат мандатын әлеге Кодексның 118 статьясындагы 6 өлешендә каралган тәртиптә кандидатларның составында вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган муниципаль берәмлек вәкаләтле органы депутаты сайланган шул ук исемлектән теркәлгән башка кандидатка тапшыра.";

в) 6 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

"7) теркәлгән кандидатны депутат буларак, шул исәптән бермандатлы яисә күпмандатлы сайлау округы буенча теркәү турында тиешле сайлау комиссиясе тарафыннан карар кабул ителгән.";

69) 123 статьяның 2 өлешендә "исәпкә алып, сентябрьнең икенче якшәмбесенә" сүзләреннән соң ", ә чираттагы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны уздыру елында – шушы сайлауларда тавыш бирү көненә" сүзләрен өстәргә;

70) 129 статьяның 2 өлешендә "муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын, муниципаль берәмлекнең сайланулы органы әгъзаларын төп сайлаулар йә муниципаль берәмлекнең сайланулы вазыйфаи затын төп сайлаулар сентябрьнең икенче якшәмбесендә уздырылса һәм аларның нәтиҗәләре буенча" сүзләрен төшереп калдырырга;

71) 1 нче кушымтага искәрмәдә "39 статьясындагы 2 өлеше" сүзләрен "39 статьясындагы 6 өлеше" сүзләренә алмаштырырга;

72) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2 нче кушымта

# ТАВЫШ БИРҮ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ БЕРКЕТМӘЛӘРГӘ КЕРТЕЛГӘН КҮРСӘТКЕЧЛӘРНЕҢ КОНТРОЛЬ ЧАГЫШТЫРМАСЫ (САННАР БЕЛӘН БЕРКЕТМӘЛӘРНЕҢ ӘЛЕГЕ КОДЕКСНЫҢ 78 СТАТЬЯСЫ НИГЕЗЕНДӘ НОМЕР СУГЫЛГАН ЮЛЛАРЫ БИЛГЕЛӘНДЕ)

1) 1 күбрәк яисә тигез 3 + 5 + 6;

2) 2 тигез 3 – 4 + 5 + 6 + 7 + 12 – 13;

3) 8 + 9 тигез 10 + 11;

4) 11 тигез 14 + беркетмәнең калган юллары (күпмандатлы сайлау округлары төзелгән очраклардан тыш);

5) 11а тигез 11б + 11г + 11е (сайлаулар үткәрелгәндә башка участокта тавыш таныклыкларыннан файдалану каралган булса).

Муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарына депутатлар сайлауларны үткәргәндә күпмандатлы сайлау округлары төзелсә, әлеге кушымтаның 4 пунктында каралган контроль чагыштырмалар урынына түбәндәге контроль чагыштырмалар тикшерелә:

6) 11 кимрәк яисә 14 тигез 14 + беркетмәнең калган юллары;

7) 11 х М күбрәк яисә 14 + беркетмәнең калган барлык юлларына тигез, монда М – сайлау округында бүленергә тиешле мандатлар саны (округларында мандатлар саны тигез булган күпмандатлы сайлау округлары өчен, һәрбер сайлаучының мандатлар санына тигез тавышлар саны булу шарты белән);

8) 11 х В күбрәк яисә 14 + беркетмәнең калган барлык юлларына тигез, монда В – мандатлар саны иң аз булган сайлау округында бүленергә тиешле мандатлар саны йә, законда һәрбер сайлаучы бер тавышка ия булу каралган булса, “1” күрсәткече (округларында мандатлар саны төрле булган күпмандатлы сайлау округлары өчен йә округларында мандатлар саны тигез булган күпмандатлы сайлау округлары өчен, һәрбер сайлаучы бер тавышка ия булу шарты белән);

9) 11 күбрәк яисә I тигез, монда I – сайлаучыларның һәрбер кандидат өчен бирелгән тавышлары.”.

**2 статья**

“Татарстан Республикасы референдумы турында” 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); № 12 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015 № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 пунктында беренче җөмлә башына “Тавыш бирү көненә” сүзләрен өстәргә, “граждан” сүзеннән соң “билгеләнгән” сүзен өстәргә, түбәндәге

эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Референдум билгеләнгәнче референдумны әзерләү һәм үткәрү гамәлләрендә 18 яше тулган граждан катнашырга хокуклы.”;

2) 17 статьяга түбәндәге эчтәлекле д$^{1}$ пунктчасы өстәргә:

“д$^{1}$) Федераль законда һәм әлеге Законда каралган очракларда референдумда тавыш бирү өчен бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының текстын раслый, референдумда тавыш бирү өчен бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын әзерләүне тәэмин итә һәм аларны территория комиссияләренә тапшыра;”;

3) 19 статьяга түбәндәге эчтәлекле д$^{1}$ пунктчасы өстәргә:

“д$^{1}$) Федераль законда һәм әлеге Законда каралган очракларда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирә;”;

4) 22 статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Референдум комиссиясенең барлык утырышларында, шулай ук референдумда катнашучылар тавышларын санаганда һәм участок, территория комиссияләре тарафыннан референдумда катнашучылар исемлекләре, бюллетеньнәр, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары, тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләр һәм җыелма таблицалар белән эш алып барылганда югарырак комиссия әгъзалары һәм аның аппараты хезмәткәрләре, инициатив төркем әгъзасы яисә вәкаләтле вәкиле булырга хокуклы. Комиссия утырышларында һәм референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле күрсәтелгән документлар белән эш алып барылганда шунда булу өчен әлеге затларга өстәмә рөхсәт таләп ителми. Референдум комиссиясе күрсәтелгән затларга үз утырышлары турында хәбәр итүне һәм аларның комиссия утырышларына һәм референдумда катнашучыларның тавышларын санау башкарыла торган, референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле күрсәтелгән документлар белән эш алып барыла торган урынга ирекле рәвештә керү мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.”;

б) түбәндәге эчтәлекле 1$^{1}$ һәм 1$^{2}$ пунктлар өстәргә:

“1$^{1}$. Комиссиянең барлык утырышларында һәм аның тарафыннан әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән документлар белән эш башкарылганда, әлеге статьяның 1$^{2}$ пунктында каралган очрактан тыш, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре шунда булырга хокуклы.

1$^{2}$. Комиссия утырышларында аның тарафыннан тавыш бирү йомгаклары, референдум нәтиҗәләре билгеләнгәндә, шулай ук референдумда катнашучыларның тавышларын санаганда референдум билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан (бастырып чыгарган) көнгә кадәр кимендә ике ай кала төзелгән хезмәт шартнамәсе яисә түләүле граждан-хокукый шартнамәсе нигезендә массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләрендә эшләүче, әлеге статьяның 11$^{2}$ пункты нигезендә аккредитацияләнгән массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашырга хокуклы.”;

в) түбәндәге эчтәлекле 2$^{1}$ пункт өстәргә:

“2$^{1}$. “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең рәсми сайты Федераль закон һәм

“Сайлаулар” Россия Федерациясе дәүләт автоматлаштырылган системасы турында” 2003 елның 10 гыйнварындагы 20-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары белән булдырыла торган бердәм порталга урнаштырыла.”;

г) 3 пунктта “1 пунктында” сүзләрен “1 һәм $1^2$ пунктларында” сүзләренә алмаштырырга;

д) 4 пунктның икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Сайланулы вазыйфаи затлар, депутатлар, Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органнары җитәкчеләре), җирле администрация башлыклары, шушы вазыйфаи затларга турыдан-туры буйсына торган затлар, судьялар, прокурорлар, Федераль законның 29 статьясындагы 7 пункты нигезендә вәкаләтләре туктатып торылган комиссия әгъзаларыннан тыш, комиссияләрнең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары күзәтүчеләр итеп билгеләнеп куела алмый.”;

е) 5 пунктта “тавыш бирү бинасына” сүзләреннән соң “һәм референдумда катнашучыларның тавышы санала торган бинага” сүзләрен өстәргә;

ж) 7 пунктта бишенче җөмләне төшереп калдырырга;

з) түбәндәге эчтәлекле $7^1$ пункт өстәргә:

“$7^1$. Участок комиссияләренә күзәтүчеләр билгеләп куйган инициатив төркем, әлеге статьяның 4 пунктында күрсәтелгән иҗтимагый берләшмә билгеләнеп куелган күзәтүчеләр исемлеген тавыш бирү (вакытыннан алда тавыш бирү) көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча тиешле территория комиссиясенә тапшыра. Әлеге исемлектә һәр күзәтүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, яшәү урыны адресы, референдум участогының номеры, күзәтүче җибәрелгән комиссиянең исеме күрсәтелә.”;

и) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“8. Инициатив төркем, әлеге статьяның 4 пунктында күрсәтелгән иҗтимагый берләшмә һәр комиссиягә иң күбе ике күзәтүче билгеләп куярга хокуклы, алар тавыш бирү бинасында чиратлашып күзәтергә хокуклы. Бер үк зат бер генә комиссиягә күзәтүче булып билгеләнергә мөмкин. Әлеге статьяның 7 пунктында күрсәтелгән юллама күзәтүче тарафыннан үзе билгеләнгән комиссиягә тавыш бирү (вакытыннан алда тавыш бирү) көненә кадәрге көндә йә тавыш бирү (вакытыннан алда тавыш бирү) көнендә тапшырылырга тиеш. Участок комиссиясенә юллама әлеге статьяның $7^1$ пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән күзәтүче тарафыннан гына тапшырылырга мөмкин. Федераль законда, әлеге Законда күрсәтелгәннәрдән гайре, тавыш бирү бинасында күзәтүчеләр булуга, тавыш бирүне үткәрүне, референдумда катнашучыларның тавышларын санауны, тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрне төзүне күзәтүгә, шулай ук бу беркетмәләрнең күчермәләрен бирүгә кагылышлы башка чикләүләр билгеләү рөхсәт ителми.”;

к) 9 пунктта:

“а” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“а) референдумда катнашучылар исемлеге, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестры, комиссиядәге бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары, тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү турындагы гаризаларның (мөрәҗәгатьләрнең) реестры белән танышырга;”;

түбәндәге эчтәлекле “к” пунктчасы өстәргә:

“к) участок комиссиясе рәисенә, рәис урынбасарына яисә секретарена алдан хәбәр итеп, тавыш бирү бинасында (участок комиссиясе рәисе билгеләгән урыннан) фотога һәм (яисә) видеога төшерергә.”;

л) 11 пунктта:

“а” пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

“б” пунктчасында “һәм аларга өстәп бирелгән документларның” сүзләрен төшереп калдырырга;

“г” пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

м) түбәндәге эчтәлекле $11^1$ – $11^3$ пунктлар өстәргә:

“$11^1$. Әлеге статьяның $1^2$ пунктында күрсәтелгән массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре тавыш бирү көнендә, вакытыннан алда тавыш бирү көннәрендә тавыш бирү бинасында булырга, шулай ук, тиешле комиссиянең рәисенә, рәис урынбасарына яисә секретарена алдан хәбәр итеп, фотога һәм видеога төшерергә хокуклы.

$11^2$. Әлеге статьяның $1^2$, 3, $11^1$ пунктларында күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән яисә аның йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аккредитацияләнәләр. Күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен аккредитацияләүгә гаризалар массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре тарафыннан комиссиягә тавыш бирү (вакытыннан алда тавыш бирү) көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча бирелергә тиеш.

$11^3$. Әлеге статьяның $11^2$ пункты нигезендә аккредитацияләнгән массакүләм мәгълүмат чарасы вәкиленә, әгәр тиешле мәгълүматны бастырып чыгару (игълан итү) турында закон таләпләре үтәлгән булса, комиссия чарасын үткәрү хакында хәбәр ителгән дип санала.”;

5) 25 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“25 статья. **Референдумда катнашучыларны теркәү (исәпкә алу)**

1. Референдумда барлык катнашучылар теркәлергә (исәпкә алынырга) тиеш.

2. Тиешле муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче референдумда катнашучыларны теркәү (исәпкә алу) муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы тарафыннан башкарыла. Референдумда катнашучыларның яшәү урыны тиешле территориядә булу факты (күченеп килергә мәҗбүр булганнарга карата – тиешле территориядә вакытлыча тору факты) референдумда катнашучыларны муниципаль берәмлек территориясендә теркәү (исәпкә алу) өчен нигез булып тора. Күрсәтелгән факт Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны һәм яшәү урыны буенча теркәүне гамәлгә ашыра торган органнар тарафыннан бирелә торган белешмәләр нигезендә билгеләнә.

3. Референдумда катнашучыларны – хәрби хезмәткәрләрне, аларның гаилә әгъзаларын һәм хәрби частьнең урнашу чикләрендә яшәүче референдумда башка катнашучыларны теркәү (исәпкә алу) хәрби часть командиры тарафыннан

башкарыла. Хәрби частьнең тиешле хезмәте тарафыннан бирелә торган мәгълүматлар нигезендә билгеләнә торган референдумда катнашучыларның шушы категориясенең яшәү урыны хәрби частьнең урнашу чикләрендә булу факты аларны теркәү (исәпкә алу) өчен нигез булып тора.

4. Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны һәм яшәү урыны буенча теркәүне, Россия Федерациясе территориясендә Россия Федерациясе гражданының шәхесен таныклаучы документлар бирүне һәм алмаштыруны гамәлгә ашыручы органнар Федераль закон нигезендә айга кимендә бер тапкыр үзләренең урнашу урыны буенча муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгына Россия Федерациясе гражданы паспортын бирү һәм алмаштыру, Россия Федерациясе гражданнарын яшәү урыны (көчләп китерелгән килергә мәҗбүр булганнарга карата – тору урыны) буенча теркәү һәм теркәп исәпкә алудан төшерү, Россия Федерациясе гражданының паспортын билгеләнгән тәртипне бозып бирү фактлары турында гражданның түбәндәге персональ белешмәләрен: фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган көнен, туган урынын, җенесен, гражданлыгын, яшәү урыны (күченеп килергә мәҗбүр булганнарга карата – булу урыны) адресын, шәхесне таныклаучы документ төрен, бу документның сериясен һәм номерын, документны биргән органның исемен яисә кодын, документны бирү көнен күрсәтеп, белешмәләр тапшыра.

5. Граждан хәле актларын теркәү органнары Федераль закон нигезендә айга кимендә бер тапкыр үзләренең урнашу урыны буенча муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгына Россия Федерациясе гражданнарының вафат булу фактлары турында белешмәләр тапшыра.

6. Хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыручы органнар хәрби хезмәткә чакырылган (контракт буенча кергән) (хәрби хезмәттән азат ителгән) Россия Федерациясе гражданнары, ә җинаять-үтәү системасы органнары (учреждениеләре) суд хөкеме буенча ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнар турында Федераль закон нигезендә өч айга кимендә бер тапкыр гражданның яшәү урыны буенча муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгына хәбәр итәләр.

7. Суд гражданны хокукка сәләтсез дип тану турында карар, шулай ук элек суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип танылган гражданны хокукка сәләтле дип тану хакында карар кабул итсә, кабул ителгән карар турында Федераль закон нигезендә гражданның яшәү урыны буенча муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгына хәбәр итә.

8. Әлеге статьяның 4 – 7 пунктларында күрсәтелгән белешмәләр референдумда катнашучылар регистрын булдыру һәм алып бару өчен айга кимендә бер тапкыр муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырыла.

9. Референдумда катнашучыларны теркәү һәм Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән референдумда катнашучыларның санын билгеләү "Сайлаулар" ДАСтан файдаланып, һәр елның 1 гыйнварына һәм 1 июленә гамәлгә ашырыла.

10. Референдумда катнашучыларны теркәү (исәпкә алу), референдумда катнашучыларның теркәлгән санын билгеләү, референдумда катнашучылар регистрын булдыру һәм алып бару Федераль закон нигезендә сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны дәүләт теркәве (исәпкә алуы) системасы турында Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе раслый торган нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

11. Референдумда катнашучы үзе турында документлаштырылган мәгълүматтан (персональ белешмәләрдән), шул исәптән машинада укыла торган чыганаклардагы мәгълүматтан тоткарлыксыз файдаланырга, әлеге мәгълүматның тулылыгын һәм дөреслеген тәэмин итү максатларында аны төгәлләштерергә хокуклы, шулай ук әлеге мәгълүматны кем һәм нинди максатларда файдалануын яисә файдаланганын, аның кем тарафыннан һәм кемгә бирелгәнлеген белергә хокуклы.";

б) 26 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"26 статья. **Референдумда катнашучылар исемлекләрен төзү**

1. Референдумда катнашучыларның хокукларын гамәлгә ашыру максатларында сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны дәүләт теркәве (исәпкә алуы) системасыннан файдаланып алынган һәм әлеге статьяның 5 пункты нигезендә бирелә торган белешмәләргә таянып, тиешле комиссияләр тарафыннан референдумда катнашучылар исемлекләре төзелә.

2. Референдум участокларында референдумда катнашучылар исемлекләренә тавыш бирү көненә референдумда катнашу хокукына ия Россия Федерациясе гражданнары кертелә.

3. Конкрет референдум участогында Россия Федерациясе гражданын референдумда катнашучылар исемлегенә кертү өчен – аның яшәү урыны шушы участок территориясендә булу факты, ә Федераль законда, әлеге Законда, башка законда каралган очракларда – гражданның әлеге участок территориясендә булу (вакытлыча булу) факты (гражданның референдумда катнашу хокукы булганда) йә гражданның бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы булу нигез булып тора. Гражданның яшәү йә булу (вакытлыча булу) урыны референдумның аерым бер участогы территориясендә булу факты Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны буенча һәм яшәү урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәп исәпкә алу органнары, ә Федераль законда, әлеге Законда, башка законда каралган очракларда шуңа вәкаләтле органнар, оешмалар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан билгеләнә.

4. Референдумда катнашу хокукына ия референдумда катнашучы, шул исәптән тавыш бирү көненә кадәр кимендә өч ай кала тиешле референдум участогы территориясендә булу урыны буенча теркәлгән көндезге бүлектә укучы, тавыш бирү көненә кадәр 60 – 21 көн кала тиешле территория комиссиясенә шәхсән бирелгән язмача гаризасы нигезендә әлеге референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертелергә мөмкин. Гаризада референдумда катнашучының яшәү урыны адресы күрсәтелә. Гариза биргән референдумда катнашучы әлеге референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә

участок комиссиясенә исемлек тапшырылганчы ук кертелә. Референдумда катнашучылар исемлеге участок комиссиясе тарафыннан төзелгән очракта, референдумда катнашучы референдумда катнашучылар исемлегенә территория комиссиясеннән тапшырылган гариза нигезендә кертелә. Бу хакта мәгълүмат әлеге референдумда катнашучы яшәү урыны буенча референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдум участогының участок комиссиясенә территория комиссиясе аша тапшырыла. Участок комиссиясе референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле юлында, референдум участогы номерын һәм муниципаль район (шәһәр округы) исемен күрсәтеп, "__ номерлы референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертелде" дигән тамга куя.

5. Референдумда катнашучылар турындагы белешмәләрне муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы төзи һәм төгәлләштерә. Хәрби частьтә булучы референдумда катнашучы хәрби хезмәткәрләр, аларның гаилә әгъзалары турында һәм референдумда башка катнашучылар турындагы белешмәләр, әгәр алар хәрби часть урнашкан территориядә яшәсәләр йә хезмәт итү урыны буенча билгеләнгән тәртиптә хәрби частьтә теркәлгән булсалар, хәрби часть командиры тарафыннан төзелә һәм төгәлләштерелә. Вакытлыча булу урыннарындагы референдумда катнашучылар турындагы белешмәләрне референдум комиссиясенә референдумда катнашучы вакытлыча булган оешманың җитәкчесе тапшыра. Күрсәтелгән белешмәләр моңа вәкаләтле орган яисә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан территория комиссияләренә җибәрелә.

6. Референдумда катнашучылар исемлеге территория комиссиясе тарафыннан, шул исәптән "Сайлаулар" ДАСтан файдаланып, билгеләнгән рәвештә шуңа вәкаләтле орган яисә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан бирелә торган белешмәләр нигезендә һәр референдум участогы буенча аерым төзелә.

7. Референдумда катнашучылар турында белешмәләр бирүче затлар бу белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылыгы өчен, шулай ук аларны вакытында тапшыру өчен җаваплы булалар.

8. Россия Федерациясе гражданы бары тик бер референдум участогында гына референдумда катнашучылар исемлегенә кертелә. Территория комиссиясе Россия Федерациясе гражданының бер үк референдумда төрле референдум участокларында референдумда катнашучылар исемлекләренә кертелү фактын ачыклаганда, тиешле комиссия референдумда катнашучылар исемлекләрен участок комиссияләренә тапшырганчы әлеге исемлекләрдәге хаталарны яисә төгәлсезлекләрне бетерү эшләрен башкара.

9. Референдумда катнашучылар исемлеге ике нөсхәдә төзелә. Референдумда катнашучылар исемлегенә кертелүче референдумда катнашучылар турындагы белешмәләр алфавит тәртибендә яисә бүтән тәртиптә (торак пунктлар, урамнар, йортлар, фатирлар буенча) урнаштырыла. Исемлектә референдумда катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы (18 яшьтә булса – өстәмә рәвештә туган көне һәм ае), яшәү урыны адресы күрсәтелә. Референдумда катнашучылар исемлегендә һәр алынган бюллетененә референдумда катнашучы тарафыннан имза салу, үз паспортының яисә граждан паспортын алмаштыра торган документының сериясен һәм номерын кую өчен, шулай ук референдумның һәр төре буенча суммар

күрсәткечләр кертү өчен һәм референдумда катнашучыга бюллетень биргән участок комиссиясе әгъзасына имза салу өчен урыннар булырга тиеш.

10. Референдумда катнашучылар исемлегенең беренче нөсхәсенә исемлекне төзегән комиссия рәисе һәм секретаре имза сала. Хәрби часть территориясендә оештырылган референдум участокларында референдумда катнашучылар исемлегенә участок комиссиясе рәисе һәм секретаре имза сала. Референдумда катнашучылар исемлеге тиешенчә территория комиссиясенең һәм (яисә) участок комиссиясенең мөһерләре белән таныклана. Референдумда катнашучылар исемлегенең икенче нөсхәсен төзү, куллану, аны тиешле участок комиссиясенә тапшыру, таныклау һәм төгәлләштерү тәртибе Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

11. Тиешле территория комиссиясе конкрет референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенең беренче нөсхәсен, тавыш бирү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, акт буенча участок комиссияләренә тапшыра. Участок комиссиясе референдумда катнашучылар исемлегенең беренче нөсхәсен аерым кенәгәләргә бүләргә хокуклы. Һәр шундый кенәгә, тавыш бирү көненә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча, брошюралар итеп ясалырга (тегелергә), тиешле участок комиссиясе мөһере һәм рәисе имзасы белән таныкланырга тиеш.

12. Участок комиссиясе комиссияләрнең җирле үзидарә органнары белән, референдумда катнашучыларны теркәүче (исәпкә алучы) учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итүне оештыруның билгеләнгән тәртибе нигезендә референдумда катнашучылар исемлеген төгәлләштерә. Тикшерелгән һәм төгәлләштерелгән референдумда катнашучылар исемлеге, тавыш бирү көненә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча, участок комиссиясе рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана һәм участок комиссиясе мөһере белән таныклана.

13. Участок комиссиясе тавыш бирү көненә кадәр 10 көн кала референдумда катнашучыларны таныштыру һәм өстәмә рәвештә төгәлләштерү өчен референдумда катнашучылар исемлеген тапшыра.

14. Референдумда катнашу хокукына ия Россия Федерациясе гражданы үзен референдумда катнашучылар исемлегенә кертү турындагы, үзе хакында референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән белешмәләрдәге теләсә нинди хата яисә төгәлсезлек турындагы гариза белән участок комиссиясенә мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Мөрәҗәгать алынганнан соң 24 сәгать эчендә, ә тавыш бирү көнендә ике сәгать эчендә, әмма тавыш бирү тәмамлану мизгеленнән дә соңга калмыйча, участок комиссиясе мөрәҗәгать итүче тарафыннан хәбәр ителгән белешмәләрне һәм тапшырылган документларны тикшерергә һәм йә хатаны яки төгәлсезлекне бетерергә, йә гаризаны кире кагу турында, аның кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, карар кабул итәргә, бу карарның таныкланган күчермәсен мөрәҗәгать итүчегә тапшырырга тиеш. Россия Федерациясе гражданын референдумда катнашучылар исемлегенә кертү турындагы гаризаны кире кагу хакында участок комиссиясе карарына карата югарырак комиссиягә яисә судка (участок комиссиясе урнашкан урын буенча) шикаять белдерелергә мөмкин, алар шикаятьне (гаризаны) өч көн эчендә, ә тавыш бирү көненә кадәр өч көн һәм аннан да азрак вакыт калганда һәм тавыш бирү көнендә кичекмәстән карарга тиеш. Шикаятьне (гаризаны) канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән очракта, референдумда

катнашучылар исемлегендә участок комиссиясе тарафыннан кичекмәстән төзәтүләр кертелә. Тиешле референдум комиссияләре рәисләре һәм секретарьлары референдумда катнашучылар исемлегенә имза салганнан соң һәм ул әлеге статьяның 10 пунктында каралган тәртиптә таныкланганнан соң Россия Федерациясе гражданы референдумда катнашучылар исемлегеннән бары тик рәсми документлар, шул исәптән референдумда катнашучыны бүтән референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертү турында югарырак комиссия хәбәре нигезендә, шулай ук референдумда катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән очракта гына төшереп калдырыла. Бу чакта референдумда катнашучылар исемлегендә, шулай ук “Сайлаулар” ДАС белешмәләре базасында Россия Федерациясе гражданын исемлектән төшереп калдыру датасы, шулай ук мондый төшереп калдыруның сәбәбе күрсәтелә. Референдумда катнашучылар исемлегендәге язу участок комиссиясе рәисенең имзасы, ә бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгәндә – бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы биргән комиссия әгъзасының имзасы белән, бу имзаны куйган датаны күрсәтеп, таныклана. Россия Федерациясенең һәр гражданы тиешле участокта референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучылар хакындагы әлеге Законның 25 статьясындагы 4 пунктында күрсәтелгән белешмәләрнең үзгәрүе турында участок комиссиясенә хәбәр итәргә хокуклы.

15. Вакытлыча булу урыннарындагы, өзлексез циклда эшләүче предприятиеләрдә һәм эш (смена) дәвамын киметеп тору мөмкин булмаган аерым төр эшләрдә шөгыльләнүче референдумда катнашучылар, шулай ук хәрби часть урнашкан урыннан читтәге хәрби хезмәткәрләр саныннан булган референдумда катнашучылар тавыш бирү көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча участок комиссиясенә шәхсән бирелгән язмача гаризалары нигезендә аларның вакытлыча булу урыны буенча референдум участогында участок комиссиясе карары белән референдумда катнашучылар исемлегенә кертелергә мөмкин. Бу турыдагы мәгълүмат тиешле территория комиссиясе аша әлеге референдумда катнашучының яшәү урыны буенча референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән участок комиссиясенә тапшырыла. Участок комиссиясе референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле юлында: “__ номерлы референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертелде” дигән тамга куя, референдум участогының номерын күрсәтә.

16. Тавыш бирү тәмамланганнан һәм референдумда катнашучыларның тавышларын санау башланганнан соң референдумда катнашучылар исемлегенә нинди дә булса үзгәрешләр кертү тыела.

17. Референдум нәтиҗәләре рәсми басылып чыкканнан соң референдумда катнашучылар турында референдумда катнашучылар исемлекләрендәге мәгълүматтан референдумда катнашучылар регистрында референдумда катнашучылар турындагы белешмәләрне төгәлләштерү өчен файдаланырга мөмкин.”;

7) 31 статьяда:

а) 1 пунктта “оешмалар,” сүзеннән соң “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре,” сүзләрен өстәргә;

б) 4 һәм 5 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Массакүләм мәгълүмат чаралары чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмаларның, “Интернет” челтәре басмалары редакцияләренең референдумда катнашучыларга федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла торган мәгълүмат бирү эшчәнлеге ирекле башкарыла.

5. Хәбәри телетапшыруларда һәм радиотапшыруларда, вакытлы матбугат басмаларындагы язмаларда, “Интернет” челтәре басмалары саннарында яки аларның яңартылган саннарында референдумга бәйле чараларны үткәрү турындагы хәбәрләр бары тик аерым мәгълүмат блогы рәвешендә, комментарийларсыз генә бирелергә тиеш. Мондый мәгълүмат блоклары өчен инициатив төркем, референдумда катнашучыларның башка төркеме акча түләми. Аларда инициатив төркемгә, референдумда катнашучыларның башка төркемнәренә өстенлек бирелмәскә тиеш, дискриминациягә (хокукларны кысуга) юл куелмаска тиеш, моңа аларның референдум үткәрүгә бәйле эшчәнлеген яктырту вакыты, мондый хәбәрләр өчен бирелгән матбугат мәйданы күләме дә керә.”;

в) 6 пунктта “, референдумны мәгълүмати тәэмин итү эшчәнлегендә катнашкан журналист, башка иҗади хезмәткәр, урындагы зат” сүзләрен “оешманың, “Интернет” челтәре басмасы редакциясенең референдумны мәгълүмати тәэмин итү эшчәнлегендә катнашкан журналисты, башка иҗади хезмәткәре, вазыйфаи заты” сүзләренә алмаштырырга;

8) 33 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 һәм 5 пунктлар өстәргә:

“4. Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы референдум билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырып чыгарылган) көннән соң бишенче көннән дә соңга калмыйча массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органына референдум билгеләү хакында карар рәсми басылып чыккан (бастырып чыгарылган) көнгә гамәлгә куючылары (уртак гамәлгә куючылары) яисә аларның редакцияләрен гамәлгә куючылары (уртак гамәлгә куючылары) Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм оешмалары булган, референдум билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырып чыгарылган) көнгә кадәрге елда Татарстан Республикасы бюджетыннан аларның эшләве өчен бюджет ассигнованиеләре (шул исәптән субсидияләр рәвешендә) бирелгән, мондый ассигнованиеләрнең төре һәм күләме турында белешмәләрне күрсәтеп, һәм (яисә) референдум билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырып чыгарылган) көнгә устав (җыелма) капиталында Татарстан Республикасы өлеше (кертеме), Россия Федерациясенең башка субъектлары белән бергә Татарстан Республикасы өлеше (кертеме) булган телерадиотапшырулар һәм вакытлы матбугат басмалары оешмалары исемлеген тапшыра.

5. Федераль закон нигезендә җирле үзидарә органы референдум билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан (бастырып чыгарылган) көннән соң бишенче көннән дә соңга калмыйча массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү

функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органына Федераль законның 47 статьясындагы 3 пунктының гамәли көче кагыла торган телерадиотапшырулар һәм вакытлы матбугат басмалары оешмаларының исемлеген тапшыра, референдум билгеләү хакындагы карар рәсми басылып чыккан (бастырып чыгарылган) көнгә кадәрге елда җирле бюджеттан эшләүләре өчен бюджет ассигнованиеләре (шул исәптән субсидияләр рәвешендә) бүлеп бирелгән телерадиотапшырулар оешмаларына һәм вакытлы матбугат басмаларына карата мондый ассигнованиеләрнең төре һәм күләме күрсәтелә.";

9) 34 статьяда:

а) 2 пунктның "а" пунктчасында "һәм вакытлы матбугат басмаларында" сүзләрен ", вакытлы матбугат басмаларында һәм "Интернет" челтәре басмаларында" сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 пунктта:

"б" пунктчасында "файдаланып;" сүзен "файдаланып. Агитация материалында мондый затның вазыйфасын күрсәтү әлеге тыюны бозу булып саналмый;" сүзләренә алмаштырырга;

"ж" пунктчасында "вәкилләренә" сүзеннән соң "һәм "Интернет" челтәре басмасы редакцияләре вәкилләренә" сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле 8 – 10 пунктлар өстәргә:

"8. Әлеге Закон нигезендә референдум мәсьәләләре буенча агитация үткәрергә хокук бирелмәгән физик затның референдум соравы буенча әйтелгән фикерләрен агитация материалларында куллану рөхсәт ителми.

9. Әлеге статьяның 8 пунктында күрсәтелмәгән физик затның референдум соравы буенча әйтелгән фикерләрен агитация материалларында куллану шушы физик затның язма ризалыгы белән генә рөхсәт ителә. Мондый ризалыкны раслый торган документ референдум комиссиясенә әлеге Законның 40 статьясындагы 3 пункты нигезендә бирелә торган агитация материаллары нөсхәләре белән бергә тапшырыла. Агитация материалын телерадиотапшырулар оешмасы каналында йә вакытлы матбугат басмасында урнаштырган очракта күрсәтелгән документ референдум комиссиясенә аның таләбе буенча тапшырыла.

10. Референдум уздырганда агитация материалларында физик зат сурәтләрен куллану шушы физик затның язма ризалыгы белән генә рөхсәт ителә. Мондый ризалыкны раслый торган документ референдум комиссиясенә әлеге Законның 40 статьясындагы 3 пункты нигезендә бирелә торган агитация материаллары нөсхәләре белән бергә тапшырыла. Агитация материалын телерадиотапшырулар оешмасы каналында йә вакытлы матбугат басмасында урнаштырган очракта күрсәтелгән документ референдум комиссиясенә аның таләбе буенча тапшырыла.";

10) 35 статьяда:

а) 1 пунктның икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Агитация чоры тавыш бирү көненә кадәрге көннең җирле вакыт белән ноль сәгатендә туктатыла.";

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Телерадиотапшырулар оешмалары каналларында, вакытлы матбугат басмаларында һәм “Интернет” челтәре басмаларында референдум мәсьәләләре буенча агитация тавыш бирү көненә 28 көн кала башлана һәм тавыш бирү көненә кадәрге көннең җирле вакыт белән ноль сәгатендә туктатыла торган чорда үткәрелә.”;

в) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Әлеге Закон нигезендә элек әзерләнгән һәм законда билгеләнгән тәртиптә әлеге Законның 40 статьясындагы 7 пунктында күрсәтелгән махсус урыннарга, әлеге Законның 40 статьясындагы 8 һәм 10 пунктлары нигезендә реклама конструкцияләренә яисә тотрыклы урнашкан башка объектларга урнаштырылган басма агитация материаллары (листовкалар, плакатлар һәм башка материаллар) тавыш бирү көнендә шул ук урыннарда сакланырга мөмкин.”;

г) 5 пунктта “кабат тавыш бирү көненә кадәр бер тәүлек кала ноль сәгатьтә” сүзләрен “әлеге статьяның 2 пункты нигезендә” сүзләренә алмаштырырга;

11) 36 статьяда:

а) исемендә “һәм вакытлы матбугат басмаларында” сүзләрен “, вакытлы матбугат басмаларында һәм “Интернет” челтәре басмаларында” сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 – 8 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Референдум кампаниясе башланырга кимендә бер ел кала теркәлгән массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы дәүләтнеке булмаган телерадиотапшырулар оешмалары, дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре һәм “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре, күрсәтелгән оешмалар һәм редакцияләр әлеге статьяның 4 һәм 5 пунктларында каралган таләпләрне үтәгән очракта, инициатив төркемгә һәм референдумда катнашучыларның башка төркемнәренә түләүле эфир вакыты, түләүле матбугат мәйданы бирергә, “Интернет” челтәре басмаларында агитация материалларын урнаштыру буенча түләүле хезмәтләр күрсәтергә хокуклы. Дәүләтнеке булмаган башка телерадиотапшырулар оешмалары, дәүләтнеке булмаган бүтән вакытлы матбугат басмалары редакцияләре, “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре инициатив төркемгә һәм референдумда катнашучыларның башка төркемнәренә эфир вакыты, матбугат мәйданы бирергә хокуксыз.

4. Дәүләтнеке булмаган телерадиотапшырулар оешмалары, дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре һәм “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре тарафыннан бирелә торган эфир вакыты, матбугат мәйданы, агитация материалларын урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү шартлары инициатив төркемгә һәм референдумда катнашучыларның башка төркемнәренә бертөрле булырга тиеш. Бу таләп инициатив төркемгә керүче гражданнар тарафыннан гамәлгә куелган дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләренә, “Интернет” челтәре басмалары редакцияләренә кагылмый.

5. Референдум үткәргәндә эфир вакыты, матбугат мәйданы, агитация материалларын урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең күләме (Россия Федерациясе валютасында) һәм башка шартлары турында белешмәләр

телерадиотапшырулар оешмасы, вакытлы матбугат басмасы редакциясе, “Интернет” челтәре басмасы редакциясе тарафыннан бастырып чыгарылырга һәм, беренче агитация материалын чыгару көненә кимендә бер көн кала, аларны бастырып чыгару көне һәм чыганагы турында мәгълүмат, массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү номеры һәм теркәү хакында таныклыкны бирү көне турында белешмәләр һәм референдум мәсьәләләре буенча агитация алып бару өчен эфир вакыты, матбугат мәйданы бирергә, “Интернет” челтәре басмасында агитация материалларын урнаштыру хезмәте күрсәтергә әзерлеге хакындагы хәбәрнамә белән бергә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырылырга тиеш.

6. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә әлеге статьяның 5 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәне шушы пунктта күрсәтелгән срокларда тапшырмау юлы белән белдереп, референдум мәсьәләләре буенча агитация алып бару өчен эфир вакыты, матбугат мәйданы бирүдән, “Интернет” челтәре басмасында агитация материалларын урнаштыру хезмәтләре күрсәтүдән түбәндәгеләр баш тартырга хокуклы:

а) дәүләтнеке булмаган телерадиотапшырулар оешмалары һәм дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре;

б) атнасына бер мәртәбәдән дә кимрәк чыга торган дәүләт вакытлы матбугат басмалары редакцияләре;

в) махсуслаштырылган телеканаллар, радиоканаллар, телетапшырулар, радиотапшырулар чыгаручы телерадиотапшырулар оешмалары һәм махсуслаштырылган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре;

г) “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре;

д) муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары һәм муниципаль вакытлы матбугат басмалары редакцияләре.

7. Массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар, “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре, милек рәвешенә бәйсез рәвештә, референдум мәсьәләләре буенча агитация алып бару өчен бирелгән эфир вакытының һәм матбугат мәйданының күләмнәрен һәм бәясен, “Интернет” челтәре басмаларында агитация материалларын урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләрнең күләмнәрен һәм бәясен исәпкә алуны мондый исәпкә алуның Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән рәвешләре нигезендә аерым исәпләп барырга һәм тавыш биргән көннән соң ун көннән дә соңга калмыйча мондый исәпкә алу күрсәткечләрен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырырга тиеш.

8. Массакүләм мәгълүмат чаралары чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар, “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре түләүсез һәм түләүле рәвештә эфир вакыты һәм матбугат мәйданы бирү, “Интернет” челтәре басмаларында агитация материалларын урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләр турында әлеге статьяның 7 һәм 10 пунктларында күрсәтелгән документларны тавыш бирү көненнән соң кимендә өч ел дәвамында сакларга тиеш.”;

в) 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“10. Референдум мәсьәләләре буенча агитация алып бару өчен телерадиотапшырулар оешмалары каналларында эфир вакыты һәм вакытлы

матбугат басмаларында матбугат мәйданы бирү, “Интернет” челтәре басмаларында агитация материалларын урнаштыру хезмәте күрсәтү телерадиотапшырулар оешмасы, вакытлы матбугат басмасы редакциясе, “Интернет” челтәре басмасы редакциясе һәм инициатив төркем, референдумда катнашучыларның бүтән төркеме вәкиле арасында язма рәвештә төзелгән шартнамә нигезендә әлеге эфир вакыты, матбугат мәйданы бирелгәнче, хезмәтләр күрсәтелгәнче гамәлгә ашырыла.”;

12) 37 статьяда:

а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Инициатив төркем уртак агитация чарасында катнашудан баш тартканда инициатив төркемгә уртак агитация чарасында катнашу өчен бирелгән эфир вакыты өлеше, федераль законда каралган очраклардан тыш, шушы уртак агитация чарасында башка катнашучылар (шул исәптән, әлеге чарада бер генә катнашучы катнаша алган очракта да) арасында бүленә.”;

б) 6 пунктның өченче җөмләсендә “булырга, яисә” сүзләреннән соң “әгәр федераль законда башкасы каралмаган булса,” сүзләрен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Түләүле эфир вакытын шулай бүлгәннән соң бүленмәгән эфир вакыты калса, ул түләү хисабына мондый эфир вакытын бирүгә гариза биргән инициатив төркемгә, референдумда катнашучыларның башка төркемнәренә бертигез шартларда бирелергә мөмкин.”;

13) 38 статьяның 2 пунктында түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Түләүле матбугат мәйданын шулай бүлгәннән соң бүленмәгән матбугат мәйданы калса, ул түләү хисабына мондый матбугат мәйданын биләүгә гариза биргән инициатив төркемгә, референдумда катнашучыларның башка төркемнәренә бертигез шартларда бирелергә мөмкин.”;

14) 40 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

“$1^1$. Басма агитация материаллары әзерләү эшләрен башкаручы яисә аларны әзерләү буенча хезмәт күрсәтүче оешмалар, индивидуаль эшкуарлар инициатив төркемгә, референдумда катнашучыларның башка төркемнәренә шушы материалларны әзерләү өчен түләүнең бертигез шартларын тәэмин итәргә тиеш. Күрсәтелгән оешмаларның, индивидуаль эшкуарларның басма агитация материалларын әзерләү эшләре яисә аларны әзерләү буенча хезмәт күрсәтүләре өчен түләү күләме (Россия Федерациясе валютасында) һәм башка шартлар турындагы белешмәләр тиешле оешма, тиешле индивидуаль эшкуар тарафыннан инициатив төркемне теркәү турындагы карар рәсми басылып чыккан (бастырып чыгарылган) көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарылырга һәм шул ук срокта Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырылырга тиеш. Күрсәтелгән белешмәләр белән бергә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә шулай ук оешманың исеме, юридик адресы һәм салым түләүченең идентификация номеры (индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның яшәү урыны урнашкан Россия Федерациясе субъектының, районның, шәһәрнең, башка торак пунктның исеме) булган белешмәләр тапшырылырга тиеш.”;

б) 3 пунктта “фотографияләре” сүзеннән соң “яисә нөсхәләре” сүзләрен, “белешмәләр” сүзеннән соң “һәм шушы агитация материалын әзерләү өчен тиешле референдум фондыннан түләү хакындагы документның күчермәсе” сүзләрен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Референдум үткәрелгәндә күрсәтелгән материаллар белән бергә комиссиягә бу агитация материалларының машинада укырлык электрон рәвешләре тапшырылырга тиеш.”;

в) 5 һәм 6 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Басма агитация материалларын әлеге статьяның $1^1$ пунктында каралган таләпләрне үтәмәгән оешмаларда һәм индивидуаль эшкуарларда йә индивидуаль эшкуарлар булмаган физик затлар белән шартнамә нигезендә әзерләү, шулай ук агитация материалларын тиешле референдум фонды акчалары исәбеннән алдан түләмичә, әлеге Законның 34 статьясындагы 5, 6 һәм 8 пунктларында, әлеге статьяның 2 пунктында билгеләнгән таләпләрне бозып әзерләү тыела.

6. Әлеге статьяның 5 пунктын бозып һәм (яисә) әлеге статьяның 3 пунктында, әлеге Законның 34 статьясындагы 9 һәм 10 пунктларында каралган таләпләрне бозып әзерләнгән агитация материалларын тарату тыела.”;

г) 8 пунктта “эленергә (ябыштырылырга, урнаштырылырга)” сүзләрен “урнаштырылырга” сүзләренә алмаштырырга;

д) 9 һәм 10 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9. Агитация материалларын әзерләү һәм урнаштыру эшләрен башкаручы (алар буенча хезмәт күрсәтүче) оешмалар, индивидуаль эшкуарлар инициатив төркемгә һәм референдумда катнашучыларның башка төркемнәренә үз эшләре (хезмәт күрсәтүләре) өчен түләүнең бертигез шартларын тәэмин итәргә тиеш.

10. Агитация материалларын һәйкәлләрдә, обелискларда, тарихи, мәдәни яисә архитектура ягыннан кыйммәткә ия биналарда, корылмаларда һәм урыннарда урнаштыру тыела. Агитация материалларын референдум комиссияләре, тавыш бирү урыннары урнашкан биналарда һәм аларга кереп йөрү юлларыннан 50 метрдан кимрәк булган урыннарда урнаштыру тыела.”;

15) 43 статьяда:

а) 6 пунктта “ә алар булмаган очракта – Россия Федерациясе Саклау банкы филиалларында” сүзләрен “референдум комиссиясе урнашкан торак пункт чикләрендә алар булмаган очракта – “Россия Саклык банкы” гавами акционер җәмгыяте филиалларында” сүзләренә алмаштырырга;

б) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9. Референдум уздырганда файдаланыла торган бюллетеньнәрне, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын, махсус билгеләрне (маркаларны), референдум комиссияләре биналарында һәм тавыш бирү урыннарында урнаштырыла торган мәгълүмат материалларын, референдум әзерләүгә һәм уздыруга бәйле документларны, референдум комиссиясенең җибәрелгән башка материалларын китереп бирү хезмәте күрсәтүләрне сатып алулар Федераль законда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.”;

16) 44 статьяда:

а) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9. Референдум фондын барлыкка китерүче барлык акчалар Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рөхсәте белән инициатив төркемнең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкиле тарафыннан “Россия Саклык банкы” гавами акционер җәмгыятенең филиалында, ә ул Татарстан Республикасы территориясендә булмаганда – Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан башка кредит оешмасында ачылган референдум фондының махсус счетына күчерелә. Татарстан Республикасы территориясендә кредит оешмалары булмаган очракта, инициатив төркем, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе белән килештереп, кредит оешмасын билгели, анда референдум фондының махсус счеты ачыла.”;

б) 11 пунктның беренче абзацында “сайтына” сүзен “рәсми сайтына” сүзләренә алмаштырырга:

в) түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

“13. Законда каралган һәм анда билгеләнгән тәртип нигезендә рәсмиләштерелгән документларны күрсәткәч, “Россия Саклык банкы” гавами акционер җәмгыятенең, ә Федераль законда билгеләнгән очракларда – башка кредит оешмасының филиаллары кичекмәстән референдум фондының махсус счетын ачырга тиеш. Счет ачу һәм счет буенча операцияләр башкару буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү алынмый. Счеттагы акчалардан файдаланган өчен процентлар алынмый һәм түләнми. Барлык акчалар счетка Россия Федерациясе валютасында күчерелә.”;

17) 46 статьяның 2 пунктында “Россия Федерациясе Саклау банкы” сүзләрен “Россия Саклык банкы” гавами акционер җәмгыяте” сүзләренә алмаштырырга;

18) 47 статьяда:

а) $4^1$ пунктның икенче җөмләсендә “референдум оештыручы комиссия” сүзләрен “Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе” сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 пунктта “барлык” сүзен төшереп калдырырга;

19) түбәндәге эчтәлекле $47^1$ статья өстәргә:

“$49^1$ статья. **Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы**

1. Әлеге Законның $50^1$ статьясындагы 2 пунктында каралган очракларда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү уздырыла.

2. Үзе референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдум участогының тавыш бирү бинасына тавыш бирү көнендә килү мөмкинлеге булмаган референдумда катнашучы тиешле федераль законда билгеләнгән срокларда территория комиссиясендә йә участок комиссиясендә бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын алырга һәм, референдумда катнашучы референдумда катнашу хокукына ия булган Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә тавыш бирү көнендә кайсы референдум участогында булса, шул референдум участогында тавыш бирүдә катнашырга хокуклы.

3. Закон нигезендә бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү каралган төрле дәрәҗәдәге сайлаулар һәм референдумнар

уздырганда әлеге сайлауларда һәм референдумнарда тавыш бирү көннәре берләштерелгән очракта, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары югарырак дәрәҗәдәге сайлаулар һәм (яисә) референдумнар уздыру тәртибен җайга сала торган законда билгеләнгән срокларда бирелә.

4. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары катгый хисаплылык документлары булып санала һәм референдум уздыруның бөтен территориясендә бердәй нумерациягә ия була. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы Федераль законның 2 нче кушымтасы нигезендәге рәвеш буенча әзерләнә. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы тексты, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының рәвеше, тавыш бирү көненә кадәр 60 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын әзерләгәндә шулай ук аларны охшатып ясаудан саклау алымнары да Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

5. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын охшатып ясаудан саклау максатларында, аларны әзерләгәндә су билгеләре булган һәм (яисә) типография ысулы белән төшерелгән микрошрифтлы язу һәм (яисә) саклау челтәре булган кәгазь һәм (яисә) бүтән махсус саклау элементлары кулланыла.

6. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын сатып алу Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан аның карары нигезендә үзәкләштерелгән рәвештә гамәлгә ашырыла.

7. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы комиссия тарафыннан референдумда катнашучының бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы таләп ителүнең сәбәбе күрсәтелгән язма гаризасы нигезендә тапшырыла. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы референдумда катнашучының шәхсән үзенә йә нотариаль таныкланган ышанычнамә нигезендә аның вәкиленә тапшырыла. Ышанычнамә шулай ук стационар дәвалау-профилактикалау учреждениесе администрациясе тарафыннан (әгәр референдумда катнашучы шул учреждениедә дәвалана торган булса), шик белдерелгән яисә гаепләнүче затлар сак астында тотыла торган учреждение администрациясе тарафыннан да (әгәр референдумда катнашучы шик белдерелгән яисә гаепләнүче зат буларак шул учреждениедә тотылса) таныкланырга мөмкин.

8. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын бирүче комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы аңа референдумда катнашучының фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, аның паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын, референдумда катнашучы референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдум участогының номерын, участок комиссиясенең адресын, муниципаль берәмлекнең һәм Россия Федерациясе субъектының исемен, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын биргән комиссиянең исемен кертә. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын бирүче комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгында үзенең фамилиясен һәм инициалларын, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән датаны күрсәтә, имза сала һәм тиешле комиссиянең мөһерен суга.

9. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын алганда референдумда катнашучы бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының яисә референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле графаларында үз паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын күрсәтә һәм имза сала. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрында референдумда катнашучының яшәү урыны адресы күрсәтелергә тиеш. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын референдумда катнашучының вәкиле ышанычнамә нигезендә алган очракта, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының яисә референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле графаларында референдумда катнашучы паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясе һәм номеры күрсәтелә, бу чакта референдумда катнашучының вәкиле үзенең фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын күрсәтә һәм имза сала. Шуннан соң референдумда катнашучының вәкиленнән ышанычнамә алына һәм тиешенчә бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрына, референдумда катнашучылар исемлегенә кушып куела.

10. Референдумда катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын биргән территория комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының тиешле графаларында бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтә һәм имза сала. Территория комиссиясе тавыш бирү көненә кадәр участок комиссияләренә референдумда катнашучылар исемлегенең беренче нөсхәсе белән бергә бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрыннан таныкланган өземтәләрне җибәрә, аларда тиешле референдум участоклары территорияләрендә теркәлгән, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары алган референдумда катнашучылар турында белешмәләр күрсәтелә. Тиешле өземтә нигезендә участок комиссиясе әгъзасы референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле графасында, бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтеп, “Территория комиссиясендә _____ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы алды” дигән тамга куя һәм имза сала.

11. Референдумда катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы участок комиссиясендә бирелгәндә, референдумда катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын биргән участок комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле графасында, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтеп, “_____ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы алды” дигән тамга куя һәм имза сала.

12. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән референдумда катнашучы (шул исәптән ышанычнамә нигезендә аның вәкиле аша) әлеге референдумда тиешле референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегеннән төшереп калдырыла һәм, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсе төзелгәндә, теркәлгән референдумда катнашучылар санында исәпкә алынмый.

13. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын кабат бирү рөхсәт ителми. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы югалган очракта, аның дубликаты бирелми.

14. Файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары тавыш бирү көнендә тавыш бирү вакыты башланганчы юкка чыгарыла. Файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын юкка чыгару турындагы белешмәләр тиешле комиссия тарафыннан аларның санын, шулай ук бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының номерларын күрсәтеп, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе раслаган рәвештә төзелгән актка кертелә.

15. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын тавыш бирү көнендә күрсәткәч, референдумда катнашучы тавыш бирү көнендә кайсы референдум участогында булса, шунда референдумда катнашучылар исемлегенә өстәмә рәвештә кертелә. Участок комиссиясе референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле графасында, референдумда катнашучы күрсәткән бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтеп, “_____ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш бирде” дигән тамга куя. Шуннан соң бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы референдумда катнашучыдан алына. Референдумда катнашучыларны референдумда катнашучылар исемлегенә кертү өчен нигез булган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары әлеге исемлек белән бергә саклана.

16. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының бланкы югалган очракта, мондый югалу фактын ачыклаган комиссия кичекмәстән тиешле акт төзи һәм карар кабул итә, карарда бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының югалган бланкы номеры, бланкның югалу факты һәм югалу сәбәбе күрсәтелә. Бу карар шул ук көнне турыдан-туры югарырак комиссиягә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә җиткерелә. Шушы карар нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тиешле бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын гамәлгә яраксыз дип таный, шул хакта барлык түбәнгерәк комиссияләргә кичекмәстән хәбәр ителә. Әгәр бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү гражданнарның референдумда катнашу хокукын бозуга китерсә, мондый бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары шулай ук башка очракларда да Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан гамәлгә яраксыз дип танылырга мөмкин. Гамәлгә яраксыз бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы референдумда катнашучыны референдумда катнашучылар исемлегенә кертү өчен нигез булып тормый. Референдумда катнашучы мондый бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын күрсәткәндә, бу таныклык алынырга тиеш.

17. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын комиссияләргә тапшыру һәм бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын исәпкә алу тәртибе, шул исәптән “Сайлаулар” ДАСтан файдаланып, Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана.”;

20) 49 статьяда:

а) $2^1$ пунктның икенче җөмләсендә “референдум оештыручы комиссия” сүзләрен “Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе” сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Үтә күренмәле тавыш бирү әрҗәләре кулланылган очракта, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча бу максатларда конвертлардан файдаланган очрактан тыш,

бюллетеньнең рәвеше тавыш бирү серен саклау кирәклеген исәпкә алып билгеләнә.";

21) 50 статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Референдумда тавыш бирү 7 сәгатьтән 20 сәгатькә кадәр үткәрелә. Эш вакытлары (өзлексез эшли торган яисә вахта ысулы белән эшли торган предприятиеләрдә) тавыш бирү вакытына туры килә торган референдумда катнашучыларның яшәү урыны (булу урыны) референдум участогы территориясендә урнашкан булса, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча референдумның әлеге участогында тавыш бирүне башлау вакыты иртәрәк вакытка, ләкин ике сәгатьтән дә артыкка түгел, күчерелергә мөмкин. Федераль законда билгеләнгән очракларда референдумда тавыш бирүнең башлану һәм тәмамлану вакытын билгеләгәндә, федераль закон нормалары кулланыла.".

б) 2 пунктта "Тавыш бирү вакыты" сүзләрен "Тавыш бирү көне, вакыты" сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

"$2^1$. Хәрби частьләрдә төзелгән референдум участокларында, әгәр референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән барлык референдумда катнашучылар тавыш бирсә, участок комиссиясе тавыш бирүне әлеге статьяның 1 пункты нигезендә билгеләнгән вакыттан иртәрәк тәмамланган дип игълан итәргә мөмкин.";

г) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Бюллетеньнәр референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучыларга паспортын яисә граждан паспортын алыштыручы документын күрсәткәч, әгәр референдумда катнашучы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш бирсә, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын күрсәткәч бирелә."

д) 6 пунктта түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче җөмлә өстәргә: "Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш биргән очракта, референдумда катнашучылар исемлегенә өстәмә тамгалар ясала.";

е) 11 пунктта түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әлеге Законның 49 статьясындагы 4 пункты нигезендә конвертлардан файдалану турында карар кабул итсә, референдумда катнашучы тутырылган бюллетеньне яшерен тавыш бирү кабинасыннан яисә мондый тавыш бирү өчен башка махсус җиһазландырылган урыннан читтә аңа участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы биргән конвертка сала, аны ябыштырып куя, шуннан соң бу конвертны тавыш бирү әрҗәсенә төшерә.";

ж) түбәндәге эчтәлекле $11^1$ һәм $11^2$ пунктлар өстәргә:

"$11^1$. Участок комиссиясе рәисе тавыш бирү урынында тәртипне саклый. Участок комиссиясе рәисенең үз компетенцияләре чикләрендә бирелгән күрсәтмәләре тавыш бирү урынындагы барлык булучылар өчен мәҗбүри. Участок комиссиясе рәисе булмаганда, аның вәкаләтләрен участок комиссиясе рәисе урынбасары, ә участок комиссиясе рәисе урынбасары булмаганда – участок

комиссиясе секретаре яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән шушы комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы башкара.

11². Тавыш бирүне уздырганда, референдумда катнашучыларның тавышларын санаганда һәм участок комиссиясенең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәсен төзегәндә участок комиссиясе бинасында әлеге Законның 22 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән затлар булырга хокуклы. Бу затлар күзәтүнең бөтен чоры дәвамында өзлексез дә, үзләре ирекле рәвештә сайлаган вакыт аралыкларында да күзәтергә хокуклы, аларга тавыш бирү һәм референдумда катнашучыларның тавышларын санау уздырыла торган бинага (биналарга) ирекле керү тәэмин ителә. Тавыш бирү барышын һәм референдумда катнашучыларның тавышларын санауны күзәткән затларның исемлеге участок комиссиясе тарафыннан әлеге затлар тапшырган документлар нигезендә төзелә.";

з) 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"12. Әгәр референдум турындагы законны бозсалар һәм мондый хокук бозу факты суд тәртибендә билгеләнсә, участок комиссиясе әгъзасы комиссия эшендә катнашудан кичекмәстән читләштерелә, ә күзәтүче һәм башка затлар тавыш бирү бинасыннан чыгарылалар. Тиешле суд карарын үтәүне Федераль закон нигезендә хокук саклау органнары тәэмин итәләр. Хокук саклау органнары шулай ук федераль законнар нигезендә тавыш бирү бинасында һәм референдум участогы территориясендә гражданнарның иминлеген һәм җәмәгать тәртибен тәэмин итәләр.";

22) 50¹ статьяда:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Законда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү каралган Татарстан Республикасы референдумында тавыш бирү, федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда тавыш бирү көннәре берләштерелгән очракта, Федераль закон нигезендә әлеге статьяның 1 пунктында каралган вакытыннан алда тавыш бирү үткәрелми. Күрсәтелгән Татарстан Республикасы референдумын уздырганда тавыш бирү бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча үткәрелә.";

б) 9 пунктта "тавыш бирү көненә кадәрге көннән" сүзләреннән соң "яисә участок комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш бирүне башлау көненә кадәрге көннән" сүзләрен өстәргә;

23) 51 статьяда:

а) 1 пунктта:

беренче җөмләдә "кертелгән" сүзен "кертелергә хокуклы яисә кертелгән" сүзләренә алмаштырырга;

икенче җөмләдә "кертелгән" сүзе татарча текстта үзгәрешсез кала;

б) 2 пунктта "(телдән мөрәҗәгатьләрне)" сүзләреннән соң "гариза (телдән мөрәҗәгать) биргән көнне үк" сүзләрен өстәргә;

в) 9 пунктта "гаризалар (телдән мөрәҗәгатьләр) буенча сайлаучылар янына барып йөрүче" сүзләрен "хәлиткеч тавыш хокукына ия, тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне уздыручы" сүзләренә алмаштырырга, "гомуми саны"

сүзләреннән соң “комиссия әгъзалары” сүзләрен, “китү” сүзеннән соң “(чыгу)” сүзен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче җөмлә өстәргә: “Референдумда катнашучылар исемлегенә референдумда тиешле катнашучы янына комиссия әгъзаларының китүе (чыгуы) хакында тамга салына.”;

24) 52 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

“$2^1$. Тавыш бирү бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча үткәрелгән очракта, тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә шулай ук түбәндәге юллар кертелә:

11а юл: участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

11б юл: тавыш бирү көненә кадәр референдум участогында референдумда катнашучыларга участок комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

11в юл: референдум участогында бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән референдумда катнашучылар саны;

11г юл: референдум участогында юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

11д юл: референдумда катнашучыларга территория комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

11е юл: югалган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны.”;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Әлеге статьяның 2 һәм $2^1$ пунктларында күрсәтелгән саннар тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә цифрлар һәм сүзләр белән кертелә.”;

25) 53 статьяда:

а) 1 пунктта түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Әлеге Законның 22 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән затларга референдумда катнашучыларның тавышларын санаганда булу һәм санауны күзәтү мөмкинлеге бирелергә тиеш.”;

б) 5 пунктта:

“а” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“а) тавыш бирү тәмамланган мизгелгә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучылар санын (территория комиссиясе һәм участок комиссиясе тарафыннан бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирелгән референдумда катнашучылар, шулай ук башка сәбәпләр белән катнашмаган референдумда катнашучылар санын исәпкә алмыйча);”;

түбәндәге эчтәлекле $в^2 – в^4$ пунктчалар өстәргә:

“$в^2$) референдум участогында референдумда катнашучыларга участок комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

$в^3$) референдумда катнашучыларга территория комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

$в^4$) референдум участогында бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән референдумда катнашучылар саны.”;

в) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6. Әлеге статьяның 5 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләр кертелгәннән соң референдумда катнашучылар исемлегенең һәр битенә комиссиянең әлеге күрсәткечләрне керткән әгъзасы имза сала, ул бу күрсәткечләрне кушып берләштерә, игълан итә һәм участок комиссиясенең рәисенә, рәис урынбасарына яисә секретарена һәм тавышларны санауда катнашучы затларга хәбәр итә. Участок комиссиясенең рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре әлеге статьяның 5 пункты нигезендә билгеләнгән күрсәткечләр суммасы буларак билгеләнүче йомгаклау күрсәткечләрен игълан итә, аларны референдумда катнашучылар исемлегенең соңгы битенә кертә, үзенең имзасы һәм участок комиссиясе мөһере белән таныклый. Игълан ителгән күрсәткечләр тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең тиешле юлларына кертелә, ә тавышларны техник чаралар кулланып санаганда – бары тик беркетмәнең зурайтылган рәвешенең тиешле юлларына гына кертелә:

а) 1 юлга – тавыш бирү тәмамланган мизгелгә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучылар саны;

б) 3 һәм 4 юлларга – вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

в) 5 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

г) 6 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

д) 11а юлга – участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

е) 11б юлга – референдум участогында референдумда катнашучыларга участок комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

ж) 11в юлга – референдум участогында бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән референдумда катнашучылар саны;

з) 11г юлга – референдум участогында юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

и) 11д юлга – референдумда катнашучыларга территория комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны.

Әлеге гамәлләрне башкарганнан соң түбәндәге контроль чагыштырманы тикшерү уздырыла: участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны тавыш бирү көненә кадәр референдум участогында референдумда катнашучыларга участок комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны һәм референдум участогында юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны суммасына тигез булырга тиеш. Әгәр әлеге контроль чагыштырма үтәлмәсә, участок комиссиясе референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән күрсәткечләрне һәм юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын өстәмә санау турында карар кабул итә. Әгәр өстәмә санау нәтиҗәсендә әлеге контроль чагыштырма тагын да үтәлмәсә, участок комиссиясе тиешле карар кабул итә, ул тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кушып бирелә, һәм аерма

турындагы күрсәткечләрне тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 11е юлына кертә. Әгәр әлеге контроль чагыштырма үтәлсә, 11е юлында “0” цифры куела.

Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 11а, 11б, 11в, 11г, 11д һәм 11е юлларына күрсәткечләр, әгәр законда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү каралган булса, кертелә.

Шуннан соң референдумда катнашучылар исемлеге белән күзәтүчеләр һәм әлеге Законның 22 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән башка затлар танышырга хокуклы, ә участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары башкарылган санауның дөреслегенә инанырга хокуклы.”;

г) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“11. Бюллетеньнәрне сортировкалаганда участок комиссиясе билгеләнмәгән рәвештәге, ягъни рәсми булмаган рәвештә әзерләнгән йә күрсәтелгән комиссия тарафыннан таныкланмаган яисә махсус билгесе (маркасы) булмаган, ул кулланылган очракта, бюллетеньнәрне аерым куя. Билгеләнмәгән рәвештәге бюллетеньнәр тавышларны санаганда исәпкә алынмый. Мондый бюллетеньнәр аерым төреп куела һәм аларга мөһер сугыла.”;

д) 20 пунктның беренче җөмләсендә “таныштырганнан соң” сүзләреннән соң “тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең юлларына законда каралган номер сугуны исәпкә алып” сүзләрен, “контроль чагыштырмаларын” сүзләреннән соң “(әлеге статьяның 6 пункты нигезендә тикшерелә торган контроль чагыштырмадан тыш)” сүзләрен өстәргә;

е) 21 пунктның бишенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Шул рәвешле җыеп куелган бюллетеньнәр, шулай ук әлеге статьяның 11 һәм 12 пунктлары нигезендә төргәкләнгән бюллетеньнәр, төргәкләнгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары, референдумда катнашучылар исемлеге капчыкларга яисә тартмаларга тутырыла, аларда референдум участогы номеры, барлык төргәкләнгән бюллетеньнәрнең гомуми саны, барлык төргәкләнгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының гомуми саны күрсәтелә.”;

ж) 27 пунктта түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Беркетмәнең күчермәсе копия алу техникасын кулланмыйча әзерләнгән очракта, беркетмәнең күчермәсендә участок комиссиясе әгъзаларының фамилияләрен, исемнәрен һәм аталарының исемнәрен күрсәтү һәм аларның имзаларын салу таләп ителми.”;

26) 54 статьяда:

а) 3 пунктта түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: “Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә шулай ук тиешле комиссия тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, түбәнгерәк комиссияләргә бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, тиешле комиссия тарафыннан юкка чыгарылган файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны һәм тиешле комиссиядә югалган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны хакында күрсәткечләр кертелә.”;

б) 8 пунктта “беркетмәнең 1 – 13 юлларына һәм (яисә) җыелма таблицага” сүзләрен “беркетмәнең 1 – 13 юлларына (әгәр законда бүтән участокта тавыш бирү

таныклыклары буенча тавыш бирү каралган булса, 11а – 11е юлларына) һәм (яисә) җыелма таблицага” сүзләренә, “хокуклы” сүзен “тиеш” сүзенә алмаштырырга;

27) 55 статьяда:

а) 1 пунктта:

беренче абзацта өченче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Референдум нәтиҗәләре турында ике нөсхәдә беркетмә һәм җыелма таблица төзелә.”, түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче һәм бишенче җөмләләр өстәргә: “Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия шунда катнашучы барлык әгъзалары имза сала. Җыелма таблицага Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең рәисе (рәис урынбасары) һәм секретаре имза сала.”;

түбәндәге эчтәлекле җиденче һәм сигезенче абзацлар өстәргә:

“Референдум нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә шулай ук тиешле комиссия тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, түбәнгерәк комиссияләргә бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, тиешле комиссия тарафыннан юкка чыгарылган файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны һәм тиешле комиссиядә югалган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны хакында күрсәткечләр кертелә.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан төзелә торган референдум нәтиҗәләре турындагы җыелма таблицага шулай ук территория комиссиясе беркетмәсенең тиешле территория комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, участок комиссияләренә бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, тиешле территория комиссиясе тарафыннан юкка чыгарылган файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны һәм тиешле территория комиссиясендә югалган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны хакындагы күрсәткечләре кертелә.”;

б) 4 пунктта “бюллетеньнәр” сүзеннән соң “, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын” сүзләрен өстәргә;

28) 58 статьяның 2 пунктында “Сайлаулар” ДАСка кертелүче” сүзләрен “Сайлаулар” ДАСка кертелә торган һәм тавыш бирү йомгакларын, референдум нәтиҗәләрен билгеләүгә бәйле рәвештә аннан чыгарыла торган” сүзләренә алмаштырырга;

29) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2 нче кушымта

ТАВЫШ БИРҮ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ БЕРКЕТМӘГӘ КЕРТЕЛГӘН КҮРСӘТКЕЧЛӘРНЕҢ КОНТРОЛЬ НИСБӘТЕ (САННАР БЕЛӘН БЕРКЕТМӘНЕҢ ӘЛЕГЕ ЗАКОННЫҢ 52 СТАТЬЯСЫ НИГЕЗЕНДӘ НОМЕР СУГЫЛГАН ЮЛЛАРЫ БИЛГЕЛӘНДЕ)

1) 1 күбрәк яисә тигез 3 + 5 + 6;

2) 2 тигез 3 – 4 + 5 + 6 + 7 + 12 – 13;

3) 8 + 9 тигез 10 + 11;

4) 11 тигез 14 + беркетмәнең аннан соңгы бөтен юллары;

5) 11а тигез 11б + 11г + 11е (референдум уздырганда бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларыннан файдалану каралган очракта).”.

**3 статья**

“Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (II өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (II өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8, № 12; 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 1 пунктында “Яшәү урыны муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан” сүзләреннән соң “тавыш бирү көненә” сүзләрен өстәргә, “референдум” сүзен “билгеләнгән референдумны” сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Референдумны билгеләгәнче референдум әзерләү һәм уздыру гамәлләрендә 18 яшькә җиткән граждан катнашырга хокуклы.”;

2) 20 статьяда түбәндәге эчтәлекле “е$^1$” пунктчасы өстәргә:

“е$^1$) “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда һәм әлеге Законда каралган очракларда референдумда тавыш бирү өчен бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы текстын раслый, референдумда тавыш бирү өчен бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын әзерләүне тәэмин итә;”;

3) 21 статьяда түбәндәге эчтәлекле “д$^1$” пунктчасы өстәргә:

“д$^1$) “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда һәм әлеге Законда каралган очракларда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирә;”;

4) 24 статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Референдум комиссиясенең барлык утырышларында, шулай ук референдумда катнашучыларның тавышларын санаганда һәм референдумда катнашучыларның исемлекләре, бюллетеньнәр, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары, тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләр һәм җыелма таблицалар белән участок комиссиясе тарафыннан эш башкарылганда югарырак комиссия әгъзалары һәм аның аппараты хезмәткәрләре, инициатив төркемнең әгъзасы яисә вәкаләтле вәкиле катнашырга хокуклы. Комиссия утырышларында һәм референдум әзерләүгә, уздыруга бәйле күрсәтелгән документлар буенча комиссия тарафыннан эш башкарылганда катнашу өчен әлеге затларга өстәмә рөхсәт таләп ителми. Референдум комиссиясе күрсәтелгән затларга хәбәр итүне һәм үз

утырышларына һәм референдумда катнашучылар тавышлары санала торган, референдум әзерләүгә, уздыруга бәйле күрсәтелгән документлар белән эш башкарыла торган бинага керергә мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.”;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ һәм $1^2$ пунктлар өстәргә:

“$1^1$. Комиссиянең барлык утырышларында һәм аның тарафыннан әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән документлар белән эш башкарылганда, әлеге статьяның $1^2$ пунктында каралган очрактан тыш, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашырга хокуклы.

$1^2$. Комиссия утырышларында аның тарафыннан тавыш бирү йомгаклары, референдум нәтиҗәләре билгеләнгәндә, шулай ук референдумда катнашучыларның тавышларын санаганда массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләрендә референдум билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан (бастырып чыгарылган) көнгә кадәр кимендә ике ай кала төзелгән хезмәт шартнамәсе яисә түләүле граждан-хокукый шартнамә нигезендә эшләүче, әлеге статьяның $11^2$ пункты нигезендә аккредитацияләнгән массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашырга хокуклы.”;

в) 3 пунктта “1 пунктында” сүзләрен “1 һәм $1^2$ пунктларында” сүзләренә алмаштырырга;

г) 4 пунктның икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Сайланулы вазыйфаи затлар, депутатлар, Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органнары җитәкчеләре), җирле администрация башлыклары, турыдан-туры шушы вазыйфаи затлар буйсынуындагы затлар, судьялар, прокурорлар, “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законның 29 статьясындагы 7 пункты нигезендә вәкаләтләре туктатып торылган комиссия әгъзаларыннан тыш, комиссияләрнең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары күзәтүчеләр итеп билгеләнеп куела алмый.”;

д) 5 пунктта “бу референдум участогындагы тавыш бирү бинасына” сүзләреннән соң “һәм референдумда катнашучыларның тавышларын санау үткәрелә торган бинага” сүзләрен өстәргә;

е) 7 пунктта бишенче җөмләне төшереп калдырырга;

ж) түбәндәге эчтәлекле $7^1$ пункт өстәргә:

“$7^1$. Участок комиссияләренә күзәтүчеләр билгеләп куйган инициатив төркем, әлеге статьяның 4 пунктында күрсәтелгән иҗтимагый берләшмә тавыш бирү (вакытыннан алда тавыш бирү) көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча муниципаль берәмлекнең тиешле сайлау комиссиясенә билгеләнеп куелган күзәтүчеләр исемлеген тапшыра. Әлеге исемлектә һәр күзәтүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, яшәү урыны адресы, референдум участогының номеры, күзәтүче җибәрелгән комиссиянең исеме күрсәтелә.”;

з) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“8. Инициатив төркем, әлеге статьяның 4 пунктында күрсәтелгән иҗтимагый берләшмә һәр комиссиягә икедән күбрәк күзәтүче билгеләп куярга хокуклы түгел, алар тавыш бирү бинасында чиратлашып күзәтергә хокуклы. Бер үк зат бер генә комиссиягә күзәтүче булып билгеләнеп куелырга мөмкин. Әлеге статьяның

7 пунктында күрсәтелгән юллама күзәтүче тарафыннан үзе билгеләнеп куелган комиссиягә тавыш бирү (вакытыннан алда тавыш бирү) көненә кадәрге көндә йә тавыш бирү (вакытыннан алда тавыш бирү) көнендә тапшырылырга тиеш. Участок комиссиясенә юллама әлеге статьяның $7^1$ пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән күзәтүче тарафыннан гына тапшырылырга мөмкин. "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законда күрсәтелгәннәрдән гайре, тавыш бирү бинасында күзәтүчеләр булуга, тавыш бирүне үткәрүне, референдумда катнашучыларның тавышларын санауны, тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрне төзүне күзәтүгә, шулай ук бу беркетмәләрнең күчермәләрен бирүгә кагылышлы башка чикләүләр билгеләү рөхсәт ителми.";

и) 9 пунктта:

"а" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"а) референдумда катнашучыларның исемлекләре, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирү реестры, комиссиядәге бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары, тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү турындагы гаризаларның (мөрәҗәгатьләрнең) реестры белән танышырга;";

түбәндәге эчтәлекле "к" пунктчасы өстәргә:

"к) участок комиссиясенең рәисенә, рәис урынбасарына яисә секретарена алдан хәбәр итеп, тавыш бирү бинасында (участок комиссиясе рәисе билгеләгән урыннан) фотога һәм (яисә) видеога төшерергә.";

к) 11 пунктта:

"а" пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

"б" пунктчасында "һәм аларга кушылып бирелгән документларның" сүзләрен төшереп калдырырга;

"г" пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

л) түбәндәге эчтәлекле $11^1$ – $11^3$ пунктлар өстәргә:

"$11^1$. Әлеге статьяның $1^2$ пунктында күрсәтелгән массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре тавыш бирү көнендә, вакытыннан алда тавыш бирү көннәрендә тавыш бирү бинасында булырга, шулай ук, тиешле комиссиянең рәисенә, рәис урынбасарына яисә секретарена алдан хәбәр итеп, фотога һәм видеога төшерергә хокуклы.

$11^2$. Әлеге статьяның $1^2$, 3, $11^1$ пунктларында күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән яисә аның йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аккредитацияләнәләр. Күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен аккредитацияләүгә гаризалар массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре тарафыннан комиссиягә тавыш бирү (вакытыннан алда тавыш бирү) көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча бирелергә тиеш.

$11^3$. Әлеге статьяның $11^2$ пункты нигезендә аккредитацияләнгән массакүләм мәгълүмат чарасы вәкиленә, әгәр тиешле мәгълүматны бастырып чыгару (игълан итү) турындагы закон таләпләре үтәлгән булса, комиссия чарасын үткәрү хакында хәбәр ителгән дип санала.";

5) 26 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“26 статья. **Референдумда катнашучыларны теркәү (исәпкә алу)**

1. Барлык референдумда катнашучылар теркәлергә (исәпкә алынырга) тиеш.

2. Тиешле муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче референдумда катнашучылар муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы тарафыннан теркәлә (исәпкә алына). Референдумда катнашучыларның яшәү урыны тиешле территориядә булу факты (көчеп килергә мәҗбүр булганнарга карата – тиешле территориядә вакытлыча булу факты) референдумда катнашучыларны муниципаль берәмлек территориясендә теркәү (исәпкә алу) өчен нигез була. Күрсәтелгән факт Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны һәм яшәү урыны буенча теркәүне гамәлгә ашыручы органнар тарафыннан тапшырыла торган белешмәләр нигезендә билгеләнә.

3. Референдумда катнашучылар – хәрби хезмәткәрләр, аларның гаилә әгъзалары һәм хәрби частьнең урнашу чикләрендә яшәүче референдумда башка катнашучылар хәрби часть командиры тарафыннан теркәлә (исәпкә алына). Хәрби частьнең тиешле хезмәте тарафыннан тапшырыла торган белешмәләр нигезендә билгеләнә торган референдумда катнашучыларның шушы категориясенең яшәү урыны хәрби частьнең урнашу чикләрендә булу факты аларны теркәү (исәпкә алу) өчен нигез була.

4. “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны һәм яшәү урыны буенча теркәүне, Россия Федерациясе территориясендә Россия Федерациясе гражданының шәхесен таныклаучы документлар бирүне һәм алмаштыруны гамәлгә ашыручы органнар айга кимендә бер тапкыр үзләренең булу урыны буенча муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгына, гражданның түбәндәге персональ белешмәләрен: фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, туган көнен, туган урынын, җенесен, гражданлыгын, яшәү урыны (күчеп килергә мәҗбүр булганнарга карата – булу урыны) адресын, шәхесне таныклаучы документ төрен, бу документның сериясен һәм номерын, документны биргән органның исемен яисә кодын, документны бирү көнен күрсәтеп, Россия Федерациясе гражданының паспортын бирү һәм алмаштыру, Россия Федерациясе гражданнарын яшәү урыны (күчеп килергә мәҗбүр булганнарга карата – булу урыны) буенча теркәү һәм теркәп исәпкә алудан төшерү, Россия Федерациясе гражданының паспортын билгеләнгән тәртипне бозып бирү фактлары турында белешмәләр тапшыра.

5. “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә граждан хәле актларын теркәү органнары айга кимендә бер тапкыр үзләренең булу урыны буенча муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгына Россия Федерациясе гражданнарының вафат булуы фактлары турында белешмәләр тапшыра.

6. “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм

референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон нигезендә өч айга кимендә бер тапкыр хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыручы органнар хәрби хезмәткә чакырылган (контракт буенча кергән) (хәрби хезмәттән азат ителгән) Россия Федерациясе гражданнары турында, ә җинаять-үтәтү системасы органнары (учреждениеләре) суд хөкеме буенча ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнар хакында гражданның яшәү урыны буенча муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгына хәбәр итәләр.

7. "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон нигезендә суд, гражданны хокукка сәләтсез дип тану турында карарны, шулай ук элек суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип танылган гражданны хокукка сәләтле дип тану хакында карарны кабул иткәч, кабул ителгән карар турында гражданның яшәү урыны буенча муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгына хәбәр итә.

8. Әлеге статьяның 4 – 7 пунктларында күрсәтелгән белешмәләр айга кимендә бер тапкыр муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә референдумда катнашучылар регистрын булдыру һәм алып бару өчен тапшырыла.

9. Референдумда катнашучыларны теркәү һәм муниципаль берәмлек территориясендә теркәлгән референдумда катнашучыларның санын билгеләү, "Сайлаулар" ДАСтан файдаланып, һәр елның 1 гыйнварына һәм 1 июленә гамәлгә ашырыла.

10. "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон нигезендә референдумда катнашучыларны теркәү (исәпкә алу), теркәлгән референдумда катнашучыларның санын билгеләү, референдумда катнашучылар регистрын булдыру һәм алып бару Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана торган сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәүнең (исәпкә алуның) дәүләт системасы турындагы нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

11. Референдумда катнашучы үзе турында документлаштырылган мәгълүматтан (персональ белешмәләрдән), шул исәптән машинада укыла торган саклагычлардагы мәгълүматтан, тоткарлыксыз файдаланырга, әлеге мәгълүматның тулылыгын һәм дөреслеген тәэмин итү максатларында аны төгәлләштерергә хокуклы, шулай ук бу мәгълүматны кем һәм нинди максатларда файдалануын яисә файдаланганын, аның кем тарафыннан һәм кемгә бирелгәнлеген белергә хокуклы.";

6) 27 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"27 статья. **Референдумда катнашучылар исемлекләрен төзү**

1. Референдумда катнашучыларның хокукларын гамәлгә ашыру максатларында тиешле комиссияләр сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәүнең (исәпкә алуның) дәүләт системасыннан файдаланып алынган һәм әлеге статьяның 6 пункты нигезендә тапшырыла торган белешмәләр нигезендә референдумда катнашучылар исемлекләре төзи.

2. Референдум участокларында референдумда катнашучылар исемлекләренә тавыш бирү көненә референдумда катнашу хокукына ия Россия Федерациясе гражданнары кертелә.

3. Әгәр Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә чит ил гражданнары референдумда катнашу хокукына ия булсалар, референдум үткәргәндә референдумда катнашучылар исемлекләренә тавыш бирү көненә 18 яшькә җиткән һәм әлеге Законның 5 статьясындагы 3 пунктындагы гамәлләргә кагылышы булмаган, күрсәтелгән референдум үткәрелә торган муниципаль берәмлек территориясендә даими яшәүче чит ил гражданнары закон нигезендә кертелә.

4. Референдумның конкрет участогы территориясендә Россия Федерациясе гражданының яшәү урыны булу факты, ә “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда, әлеге Законда, башка законда каралган очракларда – гражданның әлеге участок территориясендә булу (вакытлыча булу) факты (гражданның референдумда катнашу хокукы булганда) йә гражданның бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы булуы аны шушы участок территориясендә референдумда катнашучылар исемлегенә кертү өчен нигез була. Гражданның яшәү йә булу (вакытлыча булу) урыны референдумның аерым бер участогы территориясендә булу факты Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны һәм яшәү урыны буенча теркәп исәпкә алучы органнар тарафыннан, ә “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда, әлеге Законда, башка законда каралган очракларда – шуны эшләргә вәкаләтле органнар, оешмалар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан билгеләнә.

5. Тиешле муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан хәрби частьләрдә, хәрби оешмаларда һәм учреждениеләрдә чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләр, әгәр шушы хәрби хезмәткәрләрнең хәрби хезмәткә чакырылуга кадәрге яшәү урыны муниципаль берәмлек территориясендә булмаса, референдумда катнашучылар исемлекләренә кертелми һәм референдумда катнашучылар санын билгеләгәндә исәпкә алынмый.

6. Референдумда катнашучылар турында белешмәләрне муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы төзи һәм төгәлләштерә. Хәрби частьтәге референдумда катнашучылар – хәрби хезмәткәрләр, аларның гаилә әгъзалары һәм референдумда башка катнашучылар турында белешмәләрне, әгәр алар хәрби часть урнашкан территориядә яшәсәләр йә хәрби часть каршындагы хезмәт итү урыны буенча билгеләнгән тәртиптә теркәлгән булсалар, хәрби часть командиры төзи һәм төгәлләштерә. Вакытлыча булу урыннарындагы референдумда катнашучылар турында белешмәләрне референдум комиссиясенә референдумда катнашучы вакытлыча булган оешманың җитәкчесе тапшыра. Күрсәтелгән белешмәләр белешмәләрне тапшыруга вәкаләтле орган яисә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан территория комиссияләренә җибәрелә.

7. Референдумда катнашучылар исемлеге территория комиссиясе тарафыннан, шул исәптән “Сайлаулар” ДАСтан файдаланып, билгеләнгән рәвеш буенча белешмәләрне тапшыруга вәкаләтле орган яисә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан

тапшырыла торган белешмәләр нигезендә һәр референдум участогы буенча аерым төзелә.

8. Референдумда катнашучылар турында белешмәләр тапшыручы затлар бу белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылыгы өчен, шулай ук аларны вакытында тапшыру өчен җаваплы булалар.

9. Россия Федерациясе гражданы бары тик бер референдум участогында гына референдумда катнашучылар исемлегенә кертелә. Россия Федерациясе гражданын бер үк референдумда төрле референдум участокларында референдумда катнашучылар исемлекләренә кертү факты территория комиссиясе тарафыннан ачыкланганда, тиешле комиссия, референдумда катнашучылар исемлекләрен участок комиссияләренә тапшырганчы, әлеге исемлекләрдәге хаталарны яисә төгәлсезлекләрне бетерү эшләрен башкара.

10. Референдумда катнашучылар исемлеге ике нөсхәдә төзелә. Референдумда катнашучылар исемлегенә кертелә торган референдумда катнашучылар турындагы белешмәләр алфавит тәртибендә яисә бүтән тәртиптә (торак пунктлар, урамнар, йортлар, фатирлар буенча) урнаштырыла. Исемлектә референдумда катнашучының фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, туган елы (18 яшьтә булса – өстәмә рәвештә туган көне һәм ае), яшәү урынының адресы күрсәтелә. Референдумда катнашучылар исемлегендә һәр алынган бюллетененә референдумда катнашучы тарафыннан имза салу, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыра торган документының сериясен һәм номерын кую өчен, шулай ук референдумның һәр төре буенча суммар күрсәткечләрне кертү өчен һәм референдумда катнашучыга бюллетень биргән участок комиссиясе әгъзасына имза салу өчен урыннар булырга тиеш.

11. Референдумда катнашучылар исемлегенең беренче нөсхәсенә исемлекне төзегән комиссиянең рәисе һәм секретаре имза сала. Хәрби часть территориясендә оештырылган референдум участокларында референдумда катнашучылар исемлегенә участок комиссиясе рәисе һәм секретаре имза сала. Референдумда катнашучылар исемлеге тиешенчә территория комиссиясенең һәм (яисә) участок комиссиясенең мөһерләре белән таныклана. Референдумда катнашучылар исемлегенең икенче нөсхәсен төзү, куллану, аны тиешле участок комиссиясенә тапшыру, таныклау һәм төгәлләштерү тәртибе муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

12. Тиешле территория комиссиясе референдумның конкрет участогының референдумда катнашучылар исемлегенең беренче нөсхәсен, тавыш бирү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, акт буенча участок комиссияләренә тапшыра. Участок комиссиясе референдумда катнашучылар исемлегенең беренче нөсхәсен аерым китапларга бүләргә хокуклы. Һәр шундый китап, тавыш бирү көненә кадәрге көннән дә соңга калмыйча, брошюралар итеп тегелергә һәм тиешле участок комиссиясенең мөһере һәм аның рәисенең имзасы белән таныкланырга тиеш.

13. Участок комиссиясе комиссияләрнең референдумда катнашучыларны теркәүче (исәпкә алучы) җирле үзидарә органнары, учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара эшчәнлеген оештыруның билгеләнгән тәртибе нигезендә референдумда катнашучылар исемлеген төгәлләштерә. Референдумда катнашучыларның тикшерелгән һәм төгәлләштерелгән исемлеге, тавыш бирү көненә кадәрге көннән дә соңга калмыйча, участок комиссиясе рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана һәм

участок комиссиясе мөһере белән таныклана.

14. Участок комиссиясе тавыш бирү көненә кадәр 10 көн кала референдумда катнашучыларны таныштыру һәм өстәмә төгәлләштерүләр өчен референдумда катнашучылар исемлеген тапшыра.

15. Референдумда катнашу хокукына ия Россия Федерациясе гражданы үзен референдумда катнашучылар исемлегенә кертү турындагы, үзе хакында референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән белешмәләрдәге теләсә нинди хата яисә төгәлсезлек турындагы гариза белән участок комиссиясенә мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Мөрәҗәгать алынганнан соң 24 сәгать эчендә, ә тавыш бирү көнендә – ике сәгать эчендә, әмма тавыш бирү тәмамлану мизгеленнән дә соңга калмыйча, участок комиссиясе мөрәҗәгать итүче тарафыннан хәбәр ителгән белешмәләрне һәм тапшырылган документларны тикшерергә һәм йә хатаны яисә төгәлсезлекне бетерергә, йә гаризаны кире кагу хакында, аны кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, карар кабул итәргә, бу карарның таныкланган күчермәсен мөрәҗәгать итүчегә тапшырырга тиеш. Россия Федерациясе гражданын референдумда катнашучылар исемлегенә кертү турындагы гаризаны кире кагу хакында участок комиссиясе карарына карата югарырак комиссиягә яисә судка (участок комиссиясенең булу урыны буенча) шикаять белдерелергә мөмкин, алар шикаятьне (гаризаны) өч көн эчендә, ә тавыш бирү көненә кадәр өч көн һәм аннан да азрак вакыт калганда һәм тавыш бирү көнендә – кичекмәстән карарга тиеш. Шикаятьне (гаризаны) канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән очракта, референдумда катнашучылар исемлегендә участок комиссиясе тарафыннан кичекмәстән төзәтмәләр ясала. Әлеге статьяның 11 пунктында каралган тәртиптә тиешле комиссияләр рәисләре һәм секретарьләре референдумда катнашучылар исемлегенә имза салганнан һәм аны шушы комиссияләрнең мөһерләре белән таныклаганнан соң, Россия Федерациясе гражданы референдумда катнашучылар исемлегеннән бары тик рәсми документлар, шул исәптән референдумда катнашучыны референдумның бүтән участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертү турында югарырак комиссия хәбәре нигезендә, шулай ук референдумда катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән очракта гына төшереп калдырыла. Референдумда катнашучылар исемлегендә, шулай ук “Сайлаулар” ДАС мәгълүмат базасында Россия Федерациясе гражданын исемлектән төшереп калдыру датасы, шулай ук мондый төшереп калдыруның сәбәбе күрсәтелә. Референдумда катнашучылар исемлегендәге язма участок комиссиясе рәисенең имзасы, ә бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгәндә бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы биргән комиссия әгъзасының имзасы белән, бу имзаны салган датаны күрсәтеп, таныклана. Һәр Россия Федерациясе гражданы тиешле участокта референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучылар хакындагы әлеге Законның 26 статьясындагы 4 пунктында күрсәтелгән белешмәләрнең үзгәрүе турында участок комиссиясенә хәбәр итәргә хокуклы.

16. Вакытлыча булу урыннарындагы, өзлексез циклда эшләүче предприятиеләрдә һәм эш (смена) дәвамлылыгын киметү мөмкин булмаган аерым төр эшләрдә эшләүче референдумда катнашучылар, шулай ук хәрби часть урнашкан урыннан читтәге хәрби хезмәткәрләр булган референдумда катнашучылар, тавыш

бирү көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча, участок комиссиясенә шәхсән бирелгән гаризалары нигезендә аларның вакытлыча булу урыны буенча референдум участогында участок комиссиясе карары белән референдумда катнашучылар исемлегенә кертелергә мөмкин. Бу хакта мәгълүмат тиешле территория комиссиясе аша референдумда әлеге катнашучының яшәү урыны буенча референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән участок комиссиясенә тапшырыла. Участок комиссиясе референдумда катнашучылар исемлегендәге тиешле юлында, референдум участогының номерын күрсәтеп, "___ номерлы референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертелде" дигән тамга куя.

17. Тавыш бирү тәмамланганнан соң һәм референдумда катнашучыларның тавышларын санау башланганнан соң референдумда катнашучылар исемлекләренә нинди дә булса үзгәрешләр кертү тыела.

18. Референдум нәтиҗәләре рәсми басылып чыкканнан соң референдумда катнашучылар исемлекләрендәге референдумда катнашучылар турындагы мәгълүматтан референдумда катнашучылар регистрында референдумда катнашучылар турындагы белешмәләрне төгәлләштерү өчен файдаланырга мөмкин.";

7) 33 статьяда:

а) 1 пунктта "оешмалар," сүзеннән соң "Интернет" челтәре басмалары редакцияләре," сүзләрен өстәргә;

б) 4 һәм 5 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Массакүләм мәгълүмат чаралары чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмаларның, "Интернет" челтәре басмалары редакцияләренең федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла торган референдумда катнашучыларга мәгълүмат бирү эшчәнлеге ирекле башкарыла.

5. Мәгълүмат бирүче телепрограммаларда һәм радиопрограммаларда, вакытлы матбугат басмалары язмаларында, "Интернет" челтәре басмасының саннарында йә яңартылган саннарында референдумга бәйле чаралар уздыру турындагы хәбәрләр бары тик аерым мәгълүмат блогы рәвешендә, комментарийларсыз, бирелергә тиеш. Мондый мәгълүмат блоклары өчен инициатив төркем, референдумда катнашучыларның башка төркеме түләми. Аларда инициатив төркемгә, референдумда катнашучыларның башка төркеменә өстенлек бирелмәскә, шул исәптән аларның референдум үткәрүгә бәйле эшчәнлекләрен яктырту вакыты, мондый хәбәрләргә бирелгән матбугат мәйданының күләме буенча дискриминацияләү (хокукларны кысрыклау) рөхсәт ителмәскә тиеш.";

в) 6 пунктта "катнашкан журналист, башка иҗади хезмәткәр, вазыйфаи зат" сүзләрен "катнашучы (катнашкан) журналист, башка иҗади хезмәткәр, вазыйфаи зат, "Интернет" челтәре басмалары редакцияләре" сүзләренә алмаштырырга;

8) 35 статьяда түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

"4. "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон нигезендә җирле үзидарә органы, референдум билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырып чыгарылган) көннән соң бишенче көннән дә соңга

калмыйча, федераль башкарма хакимиятнең массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле органының территориаль органына, референдум билгеләү хакындагы карар рәсми басылып чыккан (бастырып чыгарылган) көнгә кадәрге елда җирле бюджеттан эшчәнлекләренә бюджет ассигнованиеләре (шул исәптән субсидияләр рәвешендә) бүлеп бирелгән телерадиотапшырулар оешмаларына һәм вакытлы матбугат басмаларына карата мондый ассигнованиеләрнең төрен һәм күләмен күрсәтеп, "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 47 статьясындагы 3 пунктындагы гамәлләргә кагылышы булган телерадиотапшырулар оешмаларының һәм вакытлы матбугат басмаларының исемлеген тапшыра.";

9) 36 статьяда:

а) 2 пунктның "а" пунктчасында "һәм вакытлы матбугат басмаларында" сүзләрен ", вакытлы матбугат басмаларында һәм "Интернет" челтәре басмаларында" сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 пунктта:

"б" пунктчасында "файдаланып;" сүзен "файдаланып. Агитация материалында мондый затның вазыйфасын күрсәтү әлеге тыюны бозу булмый." сүзләренә алмаштырырга;

"ж" пунктчасында "оешмалар вәкилләренә" сүзләреннән соң "һәм "Интернет" челтәре басмалары редакцияләре вәкилләренә" сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле 8 – 10 пунктлар өстәргә:

"8. Әлеге Закон нигезендә референдум мәсьәләләре буенча агитация үткәрү хокукына ия булмаган физик затның референдум мәсьәләләре буенча әйткән фикерләрен агитация материалларында куллану рөхсәт ителми.

9. Әлеге статьяның 8 пунктында күрсәтелмәгән физик затның референдум мәсьәләсе буенча әйткән фикерләрен агитация материалларында куллану бары тик шушы физик затның язма ризалыгы белән генә рөхсәт ителә. Мондый ризалыкны раслый торган документ референдум комиссиясенә әлеге Законның 42 статьясындагы 3 пункты нигезендә тапшырыла торган агитация материалларының нөсхәләре белән бергә тапшырыла. Агитация материалы телерадиотапшырулар оешмасы каналында йә вакытлы матбугат басмасында урнаштырылган очракта, күрсәтелгән документ референдум комиссиясенә аның таләбе буенча тапшырыла.

10. Референдум уздырганда агитация материалларында физик затның сурәтләрен куллану бары тик шушы физик затның язма ризалыгы белән генә рөхсәт ителә. Мондый ризалыкны раслый торган документ референдум комиссиясенә әлеге Законның 42 статьясындагы 3 пункты нигезендә тапшырыла торган агитация материалларының нөсхәләре белән бергә тапшырыла. Агитация материалы телерадиотапшырулар оешмасы каналында йә вакытлы матбугат басмасында урнаштырылган очракта, күрсәтелгән документ референдум комиссиясенә аның таләбе буенча тапшырыла.";

10) 37 статьяда:

а) 1 пунктның икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Агитация чоры тавыш бирү көненә кадәрге көннең җирле вакыт белән ноль сәгатендә туктатыла.”;

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Телерадиотапшырулар оешмалары каналларында, вакытлы матбугат басмаларында һәм “Интернет” челтәре басмаларында референдум мәсьәләләре буенча агитация тавыш бирү көненә 28 көн кала башланган һәм тавыш бирү көненә кадәрге көннең җирле вакыт белән ноль сәгатендә туктатылган чорда үткәрелә.”;

в) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Әлеге Закон нигезендә элек әзерләнгән һәм законда билгеләнгән тәртиптә әлеге Законның 42 статьясындагы 7 пунктында күрсәтелгән махсус урыннарга, әлеге Законның 42 статьясындагы 8 һәм 10 пунктлары нигезендә реклама конструкцияләренә яисә башка тотрыклы урнашкан объектларга урнаштырылган басма агитация материаллары (листовкалар, плакатлар һәм башка материаллар) тавыш бирү көнендә шул ук урыннарда сакланырга мөмкин.”;

г) 5 пунктта “кабат тавыш бирү көненә кадәр бер тәүлек кала ноль сәгатьтә” сүзләрен “әлеге статьяның 2 пункты нигезендә” сүзләренә алмаштырырга;

11) 38 статьяда:

а) исемендә “һәм вакытлы матбугат басмаларында” сүзләрен “, вакытлы матбугат басмаларында һәм “Интернет” челтәре басмаларында” сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 – 8 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Референдум кампаниясе башланырга кимендә бер ел кала теркәлгән массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы дәүләтнеке булмаган телерадиотапшырулар оешмалары, дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре һәм “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре, күрсәтелгән оешмалар һәм редакцияләр әлеге статьяның 4 һәм 5 пунктларында каралган таләпләрне үтәгән очракта, инициатив төркемгә һәм референдумда катнашучыларның башка төркемнәренә түләүле эфир вакыты, түләүле матбугат мәйданы бирергә, “Интернет” челтәре басмаларында агитация материалларын урнаштыру буенча түләүле хезмәтләр күрсәтергә хокуклы. Дәүләтнеке булмаган башка телерадиотапшырулар оешмалары, дәүләтнеке булмаган бүтән вакытлы матбугат басмалары редакцияләре, “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре инициатив төркемгә һәм референдумда катнашучыларның башка төркемнәренә эфир вакыты, матбугат мәйданы бирергә хокуксыз.

4. Дәүләтнеке булмаган телерадиотапшырулар оешмалары, дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре һәм “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре тарафыннан бирелә торган эфир вакыты, матбугат мәйданы, агитация материалларын урнаштыру буенча күрсәтелә торган хезмәтләр өчен түләү шартлары инициатив төркемгә һәм референдумда катнашучыларның башка төркемнәренә бертөрле булырга тиеш. Бу таләп инициатив төркемгә керүче гражданнар тарафыннан гамәлгә куелган дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләренә, “Интернет” челтәре басмалары редакцияләренә кагылмый.

5. Референдум үткәргәндә эфир вакыты, матбугат мәйданы, агитация материалларын урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең күләме (Россия Федерациясе валютасында) һәм башка шартлары турында белешмәләр телерадиотапшырулар оешмасы, вакытлы матбугат басмасы редакциясе, “Интернет” челтәре басмасы редакциясе тарафыннан чыгарылырга һәм, беренче агитация материалын чыгару көненә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча, аларны чыгару көне һәм чыганагы турындагы мәгълүмат, теркәү номеры һәм массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү хакында таныклык бирү көне турындагы белешмәләр һәм референдум мәсьәләләре буенча агитация алып бару өчен эфир вакыты, матбугат мәйданы бирү, “Интернет” челтәре басмасында агитация материалларын урнаштыру буенча хезмәтләр күрсәтү әзерлеге хакындагы хәбәрнамә белән бергә муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә тапшырылырга тиеш.

6. Әлеге статьяның 5 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәне муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә шушы пунктта күрсәтелгән срокларда тапшырмау юлы белән белдереп, референдум мәсьәләләре буенча агитация алып бару өчен эфир вакыты, матбугат мәйданы бирүдән, “Интернет” челтәре басмасында агитация материалларын урнаштыру буенча хезмәтләр күрсәтүдән түбәндәгеләр баш тартырга хокуклы:

а) дәүләтнеке булмаган телерадиотапшырулар оешмалары һәм дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре;

б) атнасына бер мәртәбәдән дә кимрәк чыга торган дәүләт вакытлы матбугат басмалары редакцияләре;

в) махсуслаштырылган телеканаллар, радиоканаллар, телепрограммалар, радиопрограммалар чыгаруны гамәлгә ашыручы телерадиотапшырулар оешмалары һәм махсуслаштырылган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре;

г) “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре.

7. Массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар, “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре милек рәвешенә карамастан, референдум мәсьәләләре буенча агитация алып бару өчен бирелгән эфир вакыты һәм матбугат мәйданы күләмнәренең һәм бәясенең, “Интернет” челтәре басмаларында агитация материалларын урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләр күләмнәренең һәм бәясенең муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән исәпкә алу рәвешләре нигезендә аерым исәбен алып барырга, һәм тавыш бирү көненнән алып ун көннән дә соңга калмыйча, мондый исәпкә алу күрсәткечләрен муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә тапшырырга тиеш.

8. Массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар, “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре әлеге статьяның 7 һәм 10 пунктларында күрсәтелгән түләүсез һәм түләүле эфир вакыты һәм матбугат мәйданы бирү, “Интернет” челтәре басмаларында агитация материалларын урнаштыру буенча хезмәтләр күрсәтү турындагы документларны тавыш бирү көненнән соң кимендә өч ел дәвамында сакларга тиеш.”;

в) 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“10. Референдум мәсьәләләре буенча агитация алып бару өчен телерадиотапшырулар оешмалары каналларында эфир вакыты һәм вакытлы

матбугат басмаларында матбугат мәйданы бирү, “Интернет” челтәре басмаларында агитация материалларын урнаштыру буенча хезмәтләр күрсәтү, телерадиотапшырулар оешмасы, вакытлы матбугат басмасы редакциясе, “Интернет” челтәре басмасы редакциясе белән инициатив төркемнең, референдумда катнашучыларның башка төркеменең вәкиле арасында күрсәтелгән эфир вакыты, матбугат мәйданы бирелгәнче, хезмәтләр күрсәтелгәнче язма рәвештә төзелгән шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.”;

12) 39 статьяда:

а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Инициатив төркем бергәләп уздырылучы агитация чарасында катнашудан баш тартканда бергәләп уздырылучы агитация чарасында катнашу өчен инициатив төркемгә бирелгән эфир вакытының өлеше, федераль законда каралган очраклардан тыш, шушы бергәләп уздырылучы агитация чарасында башка катнашучылар (шул исәптән әгәр әлеге чарада бер генә катнашучы катнаша алса да) арасында бүленә.”;

б) 6 пунктта өченче җөмләдә “Резервланучы” сүзе алдыннан “Әгәр федераль законда башкасы каралмаган булса,” сүзләрен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Түләүле эфир вакыты шул рәвешле бүленгәннән соң бүленмәгән эфир вакыты калса, ул түләү хисабына мондый эфир вакытын бирүгә гариза биргән инициатив төркемгә, референдумда катнашучыларның башка төркемнәренә бертигез шартларда бирелергә мөмкин.”;

13) 40 статьяның 2 пунктында түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Түләүле матбугат мәйданы шул рәвешле бүленгәннән соң бүленмәгән матбугат мәйданы калса, ул түләү хисабына мондый матбугат мәйданын бирүгә гариза биргән инициатив төркемгә, референдумда катнашучыларның башка төркемнәренә бертигез шартларда бирелергә мөмкин.”;

14) 42 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

“$1^1$. Басма агитация материаллары әзерләү эшләрен башкаручы яисә аларны әзерләү буенча хезмәтләр күрсәтүче оешмалар, индивидуаль эшкуарлар инициатив төркемгә, референдумда катнашучыларның башка төркемнәренә шушы материалларны әзерләү өчен түләүнең бертигез шартларын тәэмин итәргә тиеш. Күрсәтелгән оешмаларның, индивидуаль эшкуарларның басма агитация материалларын әзерләү эшләре яисә аларны әзерләү буенча хезмәт күрсәтүләре өчен түләүнең күләме (Россия Федерациясе валютасында) һәм башка шартлары турындагы белешмәләр тиешле оешма, тиешле индивидуаль эшкуар тарафыннан инициатив төркемне теркәү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырып чыгарылган) көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарылырга һәм шул ук вакытта муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә тапшырылырга тиеш. Күрсәтелгән белешмәләр белән бергә муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә шулай ук оешманың исеме, юридик адресы һәм салым түләүченең идентификация номеры (индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, аның яшәү урыны булган Россия Федерациясе субъекты, район, шәһәр,

башка торак пункт исеме) булган белешмәләр тапшырылырга тиеш.”;

б) 3 пунктта “фотографияләре” сүзеннән соң “яисә нөсхәләре” сүзләрен, икенче җөмләдә “белешмәләр” сүзеннән соң “һәм шушы агитация материалын әзерләү өчен референдумның тиешле фондыннан түләү хакындагы документның күчермәсе” сүзләрен өстәргә;

в) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Басма агитация материалларын әлеге статьяның $1^1$ пунктында каралган таләпләрне үтәмәгән оешмаларда һәм индивидуаль эшкуарларда йә индивидуаль эшкуарлар булмаган физик затлар белән шартнамә нигезендә әзерләү, шулай ук агитация материалларын референдумның тиешле фонды акчалары исәбеннән алдан түләмичә, әлеге Законның 36 статьясындагы 5, 6 һәм 8 пунктларында, әлеге статьяның 2 пунктында билгеләнгән таләпләрне бозып әзерләү тыела.”;

г) $5^1$ пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

д) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6. Әлеге статьяның 5 пунктын бозып һәм (яисә) әлеге статьяның 3 пунктында, әлеге Законның 36 статьясындагы 9 һәм 10 пунктларында каралган таләпләрне бозып әзерләнгән агитация материалларын тарату тыела.”;

е) 8 пунктта “эленергә (ябыштырылырга, урнаштырылырга)” сүзләрен “урнаштырылырга” сүзенә алмаштырырга;

ж) 9 һәм 10 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9. Агитация материалларын әзерләү һәм урнаштыру эшләрен башкаручы (алар буенча хезмәтләр күрсәтүче) оешмалар, индивидуаль эшкуарлар инициатив төркемгә һәм референдумда катнашучыларның башка төркемнәренә үз эшләре (хезмәт күрсәтүләре) өчен түләүнең бертигез шартларын тәэмин итәргә тиеш.

10. Агитация материалларын ядкарьләрдә, обелискларда, тарихи, мәдәни яисә архитектура ягыннан әһәмияткә ия биналарда, корылмаларда һәм урыннарда урнаштыру тыела. Агитация материалларын референдум комиссияләре, тавыш бирү урыннары урнашкан биналарда һәм аларга кереп йөрү юлларыннан 50 метрдан кимрәк булган урыннарда урнаштыру тыела.”;

15) 45 статьяның 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“10. Референдум уздырганда файдаланыла торган бюллетеньнәрне, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын, махсус билгеләрне (маркаларны), референдум комиссияләре биналарында һәм тавыш бирү биналарында урнаштырыла торган мәгълүмати материалларны сатып алулар, референдум әзерләүгә һәм уздыруга бәйле документларны, референдум комиссиясенең башка җибәрелгән әйберләрен китереп кую буенча хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.”;

16) 46 статьяда:

а) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9. Референдум фондын барлыкка китерүче барлык акчалар муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе рөхсәте белән инициатив төркемнең финанс

мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкиле тарафыннан "Россия Саклык банкы" гавами акционер җәмгыятенең филиалында, ә ул тиешле муниципаль район, шәһәр округы территориясендә булмаганда тиешенчә муниципаль район, шәһәр округы территориясендә урнашкан башка кредит оешмасында ачылган референдум фондының махсус счетына күчерелә. Тиешенчә муниципаль район, шәһәр округы территориясендә кредит оешмалары булмаган очракта, инициатив төркем, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе белән килештереп, референдум фондының махсус счеты ачыла торган кредит оешмасын билгели.";

б) 12 пунктның беренче абзацында "сайтына" сүзен "рәсми сайтына" сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

"14. Законда каралган һәм анда билгеләнгән тәртип нигезендә рәсмиләштерелгән документларны күрсәткәч, "Россия Саклык банкы" гавами акционер җәмгыятенең, ә "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законда билгеләнгән очракларда – башка кредит оешмасының филиаллары кичекмәстән референдум фондының махсус счетын ачарга тиеш. Счет ачу һәм счет буенча операцияләр башкару буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү алынмый. Счеттагы акчалардан файдаланган өчен процентлар саналмый һәм түләнми. Барлык акчалар счетка Россия Федерациясе валютасында күчерелә.";

17) 48 статьяның 2 пунктында "Россия Федерациясе Саклык банкы" сүзләрен "Россия Саклык банкы" гавами акционер җәмгыяте" сүзләренә алмаштырырга;

18) 49 статьяда:

а) $4^1$ пунктның икенче җөмләсендә "референдум оештыручы комиссия" сүзләрен "муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе" сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 пунктта "барлык" сүзен төшереп калдырырга;

19) түбәндәге эчтәлекле $49^1$ статья өстәргә:

"$49^1$ статья. **Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы**

1. Әлеге Законның $52^1$ статьясындагы 2 пунктында каралган очракларда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү уздырыла.

2. Үзен референдумда катнашучылар исемлегенә керткән референдум участогының тавыш бирү бинасына тавыш бирү көнендә килү мөмкинлеге булмаган референдумда катнашучы тиешле федераль законда билгеләнгән срокларда муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә йә участок комиссиясендә бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын алырга һәм, референдумда катнашучы референдумда катнашу хокукына ия булган муниципаль берәмлек территориясе чикләрендә тавыш бирү көнендә кайсы референдум участогында булса, шул референдум участогында тавыш бирүдә катнашырга хокуклы.

3. Законда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү каралган төрле дәрәҗәдәге сайлаулар һәм референдумнар уздырганда әлеге тавыш бирү көннәре берләштерелгән очракта, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары

югарырак дәрәҗәдәге сайлаулар һәм (яисә) референдумнар уздыру тәртибен җайга сала торган законда билгеләнгән срокларда бирелә.

4. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары катгый хисаплылык документлары булып тора һәм референдум уздыруның бөтен территориясендә бердәй нумерациягә ия була. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законның 2 нче кушымтасы нигезендәге рәвеш буенча әзерләнә. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы тексты, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирү реестрының рәвеше, тавыш бирү көненә кадәр 60 көннән дә соңга калмыйча, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан раслана. Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан шулай ук бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын әзерләгәндә аларны охшатып ясаудан саклау ысуллары да билгеләнә.

5. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын әзерләгәндә аларны охшатып ясаудан саклау максатларында су билгеләре булган һәм (яисә) типография ысулы белән төшерелгән микрошрифтлы язу һәм (яисә) саклау челтәре булган кәгазь һәм (яисә) башка махсус саклау элементлары кулланыла.

6. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын сатып алу муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан аның карары нигезендә үзәкләштерелгән рәвештә гамәлгә ашырыла.

7. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы комиссия тарафыннан референдумда катнашучының бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы таләп ителү сәбәбен күрсәткән язма гаризасы нигезендә бирелә. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы референдумда катнашучының шәхсән үзенә йә нотариаль таныкланган ышанычнамә нигезендә аның вәкиленә бирелә. Ышанычнамә шулай ук стационар дәвалау-профилактикалау учреждениесе администрациясе (әгәр референдумда катнашучы шул учреждениедә дәвалана торган булса), шик белдерелгән яисә гаепләнүче затлар сак астында тотыла торган учреждениенең администрациясе тарафыннан да (әгәр референдумда катнашучы шик белдерелгән яисә гаепләнүче зат буларак шул учреждениедә тотылса) таныкланырга мөмкин.

8. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын бирүче комиссиянең рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы аңа референдумда катнашучының фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, аның паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын, референдумда катнашучы референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдум участогының номерын, участок комиссиясенең адресын, муниципаль берәмлекнең һәм Россия Федерациясе субъектының исемнәрен, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын биргән комиссиянең исемен кертә. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын бирүче комиссиянең рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгында үзенең фамилиясен һәм инициалларын, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән датаны күрсәтә, имза сала һәм тиешле комиссиянең мөһерен суга.

9. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын алганда, референдумда

катнашучы бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирү реестрының яисә референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле графаларында үз паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын күрсәтә һәм имза сала. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирү реестрында референдумда катнашучының яшәү урынының адресы күрсәтелергә тиеш. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын ышанычнамә нигезендә референдумда катнашучының вәкиле алган очракта, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирү реестрының яисә референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле графаларында референдумда катнашучының паспорты яисә граждан паспортын алмаштыручы документы сериясе һәм номеры күрсәтелә, бу чакта референдумда катнашучының вәкиле үзенең фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын күрсәтә һәм имза сала. Шуннан соң референдумда катнашучының вәкиленнән ышанычнамә алына һәм тиешенчә бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирү реестрына, референдумда катнашучылар исемлегенә кушып куела.

10. Референдумда катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын биргән территория комиссиясенең рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирү реестрының тиешле графаларында күрсәтә һәм имза сала. Территория комиссиясе тавыш бирү көненә кадәр участок комиссияләренә референдумда катнашучылар исемлегенең беренче нөсхәсе белән бергә бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирү реестрыннан таныкланган өземтәләрне җибәрә, аларда референдумның тиешле участоклары территорияләрендә теркәлгән, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын алган референдумда катнашучылар турында белешмәләр күрсәтелә. Тиешле өземтә нигезендә участок комиссиясе әгъзасы референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле графасында, бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтеп, “Территория комиссиясендә _____ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы алды” дигән тамга ясый һәм имза сала.

11. Референдумда катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы участок комиссиясендә бирелгәндә, референдумда катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын биргән участок комиссиясенең рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле графасында, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтеп, “_____ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы алды” дигән тамга ясый һәм имза сала.

12. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән референдумда катнашучы (шул исәптән ышанычнамә нигезендә аның вәкиле аша) участок комиссиясе тарафыннан әлеге референдумда референдумның тиешле участогында референдумда катнашучылар исемлегеннән төшереп калдырыла һәм, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясенең беркетмәсе төзелгәндә, теркәлгән референдумда катнашучылар санында исәпкә алынмый.

13. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын кабат бирү рөхсәт ителми. Бүтән

участокта тавыш бирү таныклыгы югалган очракта, аның дубликаты бирелми.

14. Файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары тавыш бирү көнендә тавыш бирү вакыты башланганчы юкка чыгарыла. Файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын юкка чыгару турындагы белешмәләр аларның санын, шулай ук бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының номерларын күрсәтеп, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе раслаган рәвеш буенча төзелгән актка тиешле комиссия тарафыннан кертелә.

15. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын тавыш бирү көнендә күрсәткәч, референдумда катнашучы тавыш бирү көнендә кайсы референдум участогында булса, шул референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә өстәмә рәвештә кертелә. Участок комиссиясе референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле графасында, референдумда катнашучы күрсәткән бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтеп, "_____ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш бирде" дигән тамга ясый. Шуннан соң бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы референдумда катнашучыдан алына. Референдумда катнашучыларны референдумда катнашучылар исемлегенә кертү өчен нигез булган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары әлеге исемлек белән бергә саклана.

16. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының бланкы югалган очракта, мондый югалу фактын ачыклаган комиссия кичекмәстән тиешле акт төзи һәм карар кабул итә, анда бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының югалган бланкы номеры, бланкның югалу факты һәм югалу сәбәбе күрсәтелә. Бу карар шул ук көнне муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе игътибарына җиткерелә. Шушы карар нигезендә муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тиешле бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын гамәлгә яраксыз дип таный, шул хакта барлык түбәнгерәк комиссияләргә кичекмәстән хәбәр итела. Әгәр бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү гражданнарның референдумда катнашу хокукын бозуга китерсә, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары шулай ук башка очракларда да муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан гамәлгә яраксыз дип танылырга мөмкин. Гамәлгә яраксыз бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы референдумда катнашучыны референдумда катнашучылар исемлегенә кертү өчен нигез булмый. Референдумда катнашучы мондый бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын күрсәткәндә, ул алынырга тиеш.

17. Комиссияләргә бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын тапшыру һәм бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын исәпкә алу тәртибе, шул исәптән "Сайлаулар" ДАСтан файдаланып, "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана.";

20) 51 статьяда:

а) $2^1$ пунктның икенче җөмләсендә "референдум оештыручы комиссия" сүзләрен "муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктта түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Үтә күренмәле тавыш бирү әрҗәләре кулланылган очракта, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе карары

буенча бу максатларда конвертлардан файдаланган очрактан тыш, бюллетеньнең рәвеше тавыш бирү серен саклау кирәклеген исәпкә алып билгеләнә.”;

21) 52 статьяда:

а) 1 пунктта түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Әлеге Законның 24 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән затларга тавыш бирү биналарына керү тавыш бирү башланганчы кимендә бер сәгать кала тәэмин ителергә тиеш.”;

б) 2 пунктта “Тавыш бирү вакыты” сүзләрен “Тавыш бирү көне, вакыты” сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

“$2^1$. Хәрби частьләрдә төзелгән референдум участокларында, әгәр референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән барлык референдумда катнашучылар тавыш бирсә, участок комиссиясе тавыш бирүне әлеге статьяның 1 пункты нигезендә билгеләнгән вакыттан иртәрәк тәмамланган дип игълан итәргә мөмкин.”;

г) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Бюллетеньнәр референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучыларга паспорт яисә граждан паспортын алмаштыручы документ күрсәткәч, әгәр референдумда катнашучы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш бирсә, шулай ук бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын күрсәткәч бирелә.”;

д) 6 пунктта түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче җөмлә өстәргә: “Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш биргән очракта, референдумда катнашучылар исемлегенә өстәмә тамгалар ясала.”;

е) 11 пунктта түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе әлеге Законның 51 статьясындагы 4 пункты нигезендә конвертлардан файдалану турында карар кабул итсә, референдумда катнашучы тутырылган бюллетеньне яшерен тавыш бирү кабинасыннан яисә мондый тавыш бирү өчен башка махсус җиһазландырылган урыннан читтә аңа участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы биргән конвертка сала, аны ябыштырып куя, шуннан соң бу конвертны тавыш бирү әрҗәсенә төшерә.”;

ж) түбәндәге эчтәлекле $11^1$ һәм $11^2$ пунктлар өстәргә:

“$11^1$. Участок комиссиясе рәисе тавыш бирү бинасында тәртипне саклый. Участок комиссиясе рәисенең үз компетенцияләре чикләрендә бирелгән күрсәтмәләре тавыш бирү бинасындагы барлык булучылар өчен мәҗбүри. Участок комиссиясе рәисе булмаганда аның вәкаләтләрен участок комиссиясенең рәис урынбасары, ә участок комиссиясенең рәис урынбасары булмаганда – участок комиссиясе секретаре яисә участок комиссиясе тарафыннан вәкаләт бирелгән шушы комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы башкара.

$11^2$. Тавыш бирүне уздырганда, референдумда катнашучыларның тавышларын санаганда һәм тавыш бирү бинасында тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясенең беркетмәсен төзегәндә участок комиссиясе бинасында әлеге Законның 24 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән затлар булырга хокуклы. Бу затлар күзәтүнең бөтен чоры дәвамында өзлексез дә, үзләре ирекле рәвештә сайлаган вакыт аралыкларында да күзәтергә хокуклы, аларга тавыш бирү һәм

референдумда катнашучыларның тавышларын санау уздырыла торган бинага (биналарга) ирекле керү тәэмин ителә. Тавыш бирү барышын һәм референдумда катнашучыларның тавышларын сануны күзәткән затларның исемлеге участок комиссиясе тарафыннан әлеге затлар тапшырган документлар нигезендә төзелә.”;

з) 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“12. Әгәр референдум турындагы законны бозсалар һәм мондый хокук бозу факты суд тәртибендә билгеләнсә, участок комиссиясе әгъзасы комиссия эшендә катнашудан кичекмәстән читләштерелә, ә күзәтүче һәм башка затлар тавыш бирү бинасыннан чыгарылалар. Тиешле суд карарын үтәүне “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә хокук саклау органнары тәэмин итәләр. Хокук саклау органнары шулай ук федераль законнар нигезендә тавыш бирү бинасында һәм референдум участогы территориясендә гражданнарның иминлеген һәм җәмәгать тәртибен тәэмин итәләр.”;

22) $52^1$ статьяда:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Законда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү каралган референдумда тавыш бирү, федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда тавыш бирү көннәре берләштерелгән очракта, “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә әлеге статьяның 1 пунктында каралган вакытыннан алда тавыш бирү үткәрелми. Күрсәтелгән референдумны уздырганда, чикләре референдумның бер участогы чикләрендә булган референдум округындагы референдумнан тыш, тавыш бирү бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча үткәрелә.”;

б) 9 пунктта “тавыш бирү көненә кадәрге көннән” сүзләреннән соң “яисә участок комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш бирүне башлау көненә кадәрге көннән” сүзләрен өстәргә;

23) 53 статьяда:

а) 1 пунктта:

беренче җөмләдә “кертелгән” сүзен “кертелергә хокуклы яисә кертелгән” сүзләренә алмаштырырга;

икенче җөмләдә “кертелгән” сүзе татарча текстта үзгәрешсез кала;

б) 2 пунктта “(телдән мөрәҗәгатьләрне)” сүзләреннән соң “гариза (телдән мөрәҗәгать) биргән көнне үк” сүзләрен өстәргә;

в) 9 пунктта “гаризалар (телдән мөрәҗәгатьләр) буенча референдумда катнашучылар янына чыгып йөрүче” сүзләрен “хәлиткеч тавыш хокукына ия, тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне уздыручы” сүзләренә алмаштырырга, “гомуми саны” сүзләреннән соң “комиссия әгъзалары” сүзләрен, “китү” сүзеннән соң “(чыгу)” сүзен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче җөмлә өстәргә: “Референдумда катнашучылар исемлегенә референдумда тиешле катнашучы янына комиссия әгъзаларының китүе (чыгуы) хакында тамга салына.”;

24) 54 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

“$2^1$. Тавыш бирү бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча үткәрелгән очракта, тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә шулай ук түбәндәге юллар кертелә:

11а юл: участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

11б юл: тавыш бирү көненә кадәр референдум участогында референдумда катнашучыларга участок комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

11в юл: референдум участогында бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән референдумда катнашучылар саны;

11г юл: референдум участогында юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

11д юл: референдумда катнашучыларга муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

11е юл: югалган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны.”;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Әлеге статьяның 2 һәм $2^1$ пунктларында күрсәтелгән саннар тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә цифрлар һәм сүзләр белән кертелә.”;

25) 55 статьяда:

а) 1 пунктта түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Әлеге Законның 24 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән затларга референдумда катнашучыларның тавышларын санаганда булу һәм санауны күзәтү мөмкинлеге бирелергә тиеш.”;

б) 5 пунктта:

“а” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“а) тавыш бирү тәмамланган мизгелгә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучылар санын (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе һәм участок комиссиясе тарафыннан бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирелгән референдумда катнашучылар, шулай ук башка сәбәпләр белән катнашмаган референдумда катнашучылар санын исәпкә алмыйча);”;

түбәндәге эчтәлекле $в^2$ – $в^4$ пунктчалар өстәргә:

“$в^2$) референдум участогында референдумда катнашучыларга участок комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

$в^3$) референдумда катнашучыларга муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

$в^4$) референдум участогында бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән референдумда катнашучылар саны.”;

в) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6. Әлеге статьяның 5 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләр кертелгәннән соң референдумда катнашучылар исемлегенең һәр битенә комиссиянең әлеге күрсәткечләрне керткән әгъзасы имза сала, ул бу күрсәткечләрне кушып

берләштерә, игълан итә һәм участок комиссиясенең рәисенә, рәис урынбасарына яисә секретарена һәм тавышларны санауда катнашучы затларга хәбәр итә. Участок комиссиясенең рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре әлеге статьяның 5 пункты нигезендә билгеләнгән күрсәткечләр суммасы буларак билгеләнүче йомгаклау күрсәткечләрен игълан итә, аларны референдумда катнашучылар исемлегенең соңгы битенә кертә, үзенең имзасы һәм участок комиссиясе мөһере белән таныклый. Игълан ителгән күрсәткечләр тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең тиешле юлларына кертелә, ә тавышларны техник чаралар кулланып санаганда – бары тик беркетмәнең зурайтылган рәвешенең тиешле юлларына гына кертелә:

а) 1 юлга – тавыш бирү тәмамланган мизгелгә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучылар саны;

б) 3 һәм 4 юлларга – вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

в) 5 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

г) 6 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

д) 11а юлга – участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

е) 11б юлга – референдум участогында референдумда катнашучыларга участок комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

ж) 11в юлга – референдум участогында бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән референдумда катнашучылар саны;

з) 11г юлга – референдум участогында юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

и) 11д юлга – референдумда катнашучыларга территория комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны.

Әлеге гамәлләрне башкарганнан соң түбәндәге контроль чагыштырманы тикшерү уздырыла: участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны тавыш бирү көненә кадәр референдум участогында референдумда катнашучыларга участок комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны һәм референдум участогында юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны суммасына тигез булырга тиеш. Әгәр әлеге контроль чагыштырма үтәлмәсә, участок комиссиясе референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән күрсәткечләрне һәм юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын өстәмә санау турында карар кабул итә. Әгәр өстәмә санау нәтиҗәсендә әлеге контроль чагыштырма тагын да үтәлмәсә, участок комиссиясе тиешле карар кабул итә, ул тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кушып бирелә, һәм аерма турындагы күрсәткечләрне тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 11е юлына кертә. Әгәр әлеге контроль чагыштырма үтәлсә, 11е юлында “0” цифры куела.

Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган

рәвешенең 11а, 11б, 11в, 11г, 11д һәм 11е юлларына күрсәткечләр, әгәр законда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү каралган булса, кертелә.

Шуннан соң референдумда катнашучылар исемлеге белән күзәтүчеләр һәм әлеге Законның 24 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән башка затлар танышырга хокуклы, ә участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары башкарылган санауның дөреслегенә инанырга хокуклы.";

г) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"11. Бюллетеньнәрне сортировкалаганда участок комиссиясе билгеләнмәгән рәвештәге, ягъни рәсми булмаган рәвештә әзерләнгән йә күрсәтелгән комиссия тарафыннан таныкланмаган яисә махсус билгесе (маркасы) булмаган, ул кулланылган очракта, бюллетеньнәрне аерым куя. Билгеләнмәгән рәвештәге бюллетеньнәр тавышларны санаганда исәпкә алынмый. Мондый бюллетеньнәр аерым төреп куела һәм аларга мөһер сугыла.";

д) 20 пунктның беренче җөмләсендә "таныштырганнан соң" сүзләреннән соң "тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең юлларына законда каралган номер сугуны исәпкә алып" сүзләрен, "контроль чагыштырмаларын" сүзләреннән соң "(әлеге статьяның 6 пункты нигезендә тикшерелә торган контроль чагыштырмадан тыш)" сүзләрен өстәргә;

е) 21 пунктның бишенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Шул рәвешле җыеп куелган бюллетеньнәр, шулай ук әлеге статьяның 11 һәм 12 пунктлары нигезендә төргәкләнгән бюллетеньнәр, төргәкләнгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары, референдумда катнашучылар исемлеге капчыкларга яисә тартмаларга тутырыла, аларда референдум участогы номеры, барлык төргәкләнгән бюллетеньнәрнең гомуми саны, барлык төргәкләнгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының гомуми саны күрсәтелә.";

ж) 27 пунктта түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Беркетмәнең күчермәсе копия алу техникасын кулланмыйча әзерләнгән очракта, беркетмәнең күчермәсендә участок комиссиясе әгъзаларының фамилияләрен, исемнәрен һәм аталарының исемнәрен күрсәтү һәм аларның имзаларын салу таләп ителми.";

26) 56 статьяда:

а) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6. Референдум нәтиҗәләре турында ике нөсхәдә беркетмә һәм җыелма таблица төзелә. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия шунда катнашучы барлык әгъзалары имза сала. Җыелма таблицага муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең рәисе (рәис урынбасары) һәм секретаре имза сала. Референдум нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә түбәндәге күрсәткечләр кертелә:

а) муниципаль берәмлек территориясендәге участок комиссияләре саны;

б) тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләре беркетмәләренең саны;

в) тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләре беркетмәләрендәге юлларның суммар күрсәткечләре.

Референдум нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә шулай ук тиешле комиссия

тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, түбәнгерәк комиссияләргә бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, тиешле комиссия тарафыннан юкка чыгарылган файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны һәм тиешле комиссиядә югалган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны хакында күрсәткечләр кертелә.";

б) 12 пунктта "беркетмәнең 1 – 13 юлларына һәм (яисә) җыелма таблицага" сүзләрен "беркетмәнең 1 – 13 юлларына (әгәр законда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү каралган булса, 11а – 11е юлларына) һәм (яисә) җыелма таблицага" сүзләренә алмаштырырга;

27) 58 статьяның 1 пунктында "бюллетеньнәрне" сүзеннән соң ", бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын" сүзләрен өстәргә;

28) 61 статьяда:

а) 1 пунктның икенче һәм өченче җөмләләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Сайлаулар" ДАСка һәм аннан файдалануга, аны үстерүгә карата таләпләр федераль закон, ә федераль закон белән җайга салынмаган өлештә – Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Тавыш бирү йомгаклары, референдум нәтиҗәләре турында референдум комиссияләре беркетмәләрендәге күрсәткечләрне "Сайлаулар" ДАСка кертү мәҗбүри.";

б) 2 пунктта "Сайлаулар" ДАСка кертелүче" сүзләрен "Сайлаулар" ДАСка кертелә торган һәм тавыш бирү йомгакларын, референдум нәтиҗәләрен билгеләүгә бәйле рәвештә аннан чыгарыла торган" сүзләренә алмаштырырга;

29) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2 нче кушымта

ТАВЫШ БИРҮ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ БЕРКЕТМӘГӘ КЕРТЕЛГӘН КҮРСӘТКЕЧЛӘРНЕҢ КОНТРОЛЬ НИСБӘТЕ (САННАР БЕЛӘН БЕРКЕТМӘНЕҢ ӘЛЕГЕ ЗАКОННЫҢ 54 СТАТЬЯСЫ НИГЕЗЕНДӘ НОМЕР СУГЫЛГАН ЮЛЛАРЫ БИЛГЕЛӘНДЕ)

1) 1 күбрәк яисә тигез 3 + 5 + 6;

2) 2 тигез 3 – 4 + 5 + 6 + 7 + 12 – 13;

3) 8 + 9 тигез 10 + 11;

4) 11 тигез 14 + беркетмәнең аннан соңгы бөтен юллары;

5) 11а тигез 11б + 11г + 11е (референдум уздырганда бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларыннан файдалану каралган очракта).".

**4 статья**

"Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе турында" 2012 елның 25 декабрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 5; 2015, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 18 статьяда түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:

“$5^1$) “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда һәм әлеге Законда каралган очракларда чакыртып алу буенча тавыш бирү өчен бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын әзерләүне тәэмин итә һәм аларны территория комиссияләренә тапшыра;”;

2) 20 статьяда түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:

“$5^1$) “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда һәм әлеге Законда каралган очракларда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирә;”;

3) 22 статьяда:

а) 1 өлештә:

“чакыртып алу буенча тавыш бирү бюллетеньнәре,” сүзләреннән соң “бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары,” сүзләрен өстәргә;

дүртенче җөмләне төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ һәм $1^2$ өлешләр өстәргә:

“$1^1$. Комиссиянең барлык утырышларында һәм аның тарафыннан әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән документлар белән эш башкарылганда, әлеге статьяның $1^2$ өлешендә каралган очрактан тыш, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашырга хокуклы.

$1^2$. Комиссия утырышларында аның тарафыннан тавыш бирү йомгаклары, чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре билгеләнгәндә, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын санаганда массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләрендә чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан (бастырып чыгарылган) көнгә кадәр кимендә ике ай кала төзелгән хезмәт шартнамәсе яисә түләүле граждан-хокукый шартнамә нигезендә эшләүче, әлеге статьяның $16^2$ өлеше нигезендә аккредитацияләнгән массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашырга хокуклы.”;

в) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

“$2^1$. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайты “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон һәм “Россия Федерациясенең “Сайлаулар” дәүләт автоматлаштырылган системасы турында” 2003 елның 10 гыйнварындагы 20-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары белән булдырыла торган бердәм порталында урнаштырыла.”;

г) 3 өлештә “1 өлешендә” сүзләрен “1 һәм $1^2$ өлешләрендә” сүзләренә алмаштырырга;

д) 10 өлешнең өченче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Сайланулы вазыйфаи затлар, депутатлар, Россия Федерациясе субъектларының иң

югары вазыйфаи затлары (Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органнары җитәкчеләре), җирле администрация башлыклары, турыдан-туры шушы вазыйфаи затлар буйсынуындагы затлар, судьялар, прокурорлар, "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 29 статьясындагы 7 пункты нигезендә вәкаләтләре туктатып торылган комиссия әгъзаларыннан тыш, комиссияләрнең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары күзәтүчеләр итеп билгеләнеп куела алмый.";

е) 11 өлештә бишенче җөмләне төшереп калдырырга;

ж) түбәндәге эчтәлекле $11^1$ өлеш өстәргә:

"$11^1$. Участок комиссияләренә күзәтүчеләр билгеләп куйган инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның һәр башка төркеме, әлеге статьяның 10 өлешендә күрсәтелгән иҗтимагый берләшмә тавыш бирү (вакытыннан алда тавыш бирү) көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча тиешле территория комиссиясенә билгеләнеп куелган күзәтүчеләр исемлеген тапшыра. Әлеге исемлектә һәр күзәтүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, яшәү урыны адресы, чакыртып алу буенча тавыш бирү участогының номеры, күзәтүче җибәрелгән комиссиянең исеме күрсәтелә.";

з) 12 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

и) 13 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"13. Инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның һәр башка төркеме, әлеге статьяның 10 өлешендә күрсәтелгән иҗтимагый берләшмә һәр комиссиягә икедән күбрәк күзәтүче билгеләп куярга хокуклы түгел, алар тавыш бирү бинасында чиратлашып күзәтергә хокуклы. Бер үк зат бер генә комиссиягә күзәтүче булып билгеләнеп куелырга мөмкин. Әлеге статьяның 11 өлешендә күрсәтелгән юллама күзәтүче тарафыннан үзе билгеләнеп куелган комиссиягә тавыш бирү (вакытыннан алда тавыш бирү) көненә кадәрге көндә йә тавыш бирү (вакытыннан алда тавыш бирү) көнендә тапшырылырга тиеш. Участок комиссиясенә юллама әлеге статьяның $11^1$ өлешендә каралган исемлектә күрсәтелгән күзәтүче тарафыннан гына тапшырылырга мөмкин. "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законда күрсәтелгәннәрдән гайре, тавыш бирү бинасында күзәтүчеләр булуга, тавыш бирүне үткәрүне, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын санауны, тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрне төзүне күзәтүгә, шулай ук бу беркетмәләрнең күчермәләрен бирүгә кагылышлы башка чикләүләр билгеләү рөхсәт ителми.";

к) 14 өлештә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның исемлекләре, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирү реестры, комиссиядәге бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары, тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү турындагы гаризаларның (мөрәҗәгатьләрнең) реестры белән танышырга;";

түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

"10) участок комиссиясенең рәисенә, рәис урынбасарына яисә секретарена

алдан хәбәр итеп, тавыш бирү бинасында (участок комиссиясе рәисе билгеләгән урыннан) фотога һәм (яисә) видеога төшерергә.";

л) 16 өлештә:

1 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3 пунктта "һәм аларга кушылып бирелә торган документларның" сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

м) түбәндәге эчтәлекле $16^1$ – $16^3$ өлешләр өстәргә:

"$16^1$. Әлеге статьяның $1^2$ өлешендә күрсәтелгән массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре тавыш бирү көнендә, вакытыннан алда тавыш бирү көннәрендә тавыш бирү бинасында булырга, шулай ук, тиешле комиссиянең рәисенә, рәис урынбасарына яисә секретарена алдан хәбәр итеп, фотога һәм видеога төшерергә хокуклы.

$16^2$. Әлеге статьяның $1^2$, 3, $16^1$ өлешләрендә күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе яисә аның йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә аккредитация узалар. Күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен аккредитация узуга заявкалар комиссиягә массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре тарафыннан тавыш бирү (вакытыннан алда тавыш бирү) көненә кимендә өч көн кала тапшырылырга тиеш.

$16^3$. Әлеге статьяның $16^2$ өлеше нигезендә аккредитация узган массакүләм мәгълүмат чарасы вәкиленә, әгәр тиешле мәгълүматны бастырып чыгару (халыкка игълан итү) турындагы закон таләпләре үтәлгән булса, комиссия чарасын үткәрү турында хәбәр ителгән дип санала.";

4) 24 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"24 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны теркәү (исәпкә алу)**

1. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның һәркайсы теркәлергә (исәпкә алынырга) тиеш.

2. Тиешле муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы терки (исәпкә ала). Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның яшәү урынының тиешле территориядә булуы факты (күченеп килергә мәҗбүр булганнарга карата – тиешле территориядә вакытлыча булуы факты) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны муниципаль берәмлек территориясендә теркәү (исәпкә алу) өчен нигез була. Күрсәтелгән факт Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны һәм яшәү урыны буенча теркәүне гамәлгә ашыручы органнар тарафыннан билгеләнә.

3. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар – хәрби хезмәткәрләр, аларның гаилә әгъзалары һәм хәрби частьнең урнашу чикләрендә яшәүче бүтән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар хәрби часть командиры тарафыннан теркәлә (исәпкә алына). Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә

катнашучыларның яшәү урынының хәрби частьнең урнашу чикләрендә булуы факты, әлеге факт хәрби частьнең тиешле хезмәте тарафыннан бирелә торган мәгълүматларга нигезләнеп билгеләнә, шушы категорияне теркәү (исәпкә алу) өчен нигез була.

4. “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны һәм яшәү урыны буенча теркәүне, Россия Федерациясе территориясендә Россия Федерациясе гражданының шәхесен таныклаучы документлар бирүне һәм алмаштыруны гамәлгә ашыручы органнар айга кимендә бер тапкыр үзләренең урнашу урыны буенча муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгына Россия Федерациясе гражданы паспортын бирү һәм алмаштыру, Россия Федерациясе гражданнарын яшәү урыны (күченеп килергә мәҗбүр булганнарга карата – булу урыны) буенча теркәү һәм теркәүне исәпкә алудан төшерү, Россия Федерациясе гражданының паспортын билгеләнгән тәртипне бозып бирү фактлары турында белешмәләрне гражданның персональ белешмәләрен: фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, туган көнен, туган урынын, җенесен, гражданлыгын, яшәү урыны (күченеп килергә мәҗбүр булганнарга карата – булу урыны) адресын, шәхесне таныклаучы документ төрен, бу документның сериясен һәм номерын, документны биргән органның исемен яисә кодын, документны бирү көнен күрсәтеп тапшыра.

5. “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә граждан хәле актларын теркәү органнары айга кимендә бер тапкыр үзләренең урнашу урыны буенча муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгына Россия Федерациясе гражданнарының вафат булуы фактлары турында белешмәләр тапшыра.

6. “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә өч айга кимендә бер тапкыр хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыручы органнар гражданның яшәү урыны буенча муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгына хәрби хезмәткә чакырылган (контракт буенча кергән) (хәрби хезмәттән азат ителгән) Россия Федерациясе гражданнары, җинаять-үтәү системасының органнары (учреждениеләре) суд хөкеме буенча ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнар турында хәбәр итә.

7. “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә суд, гражданны хокукка сәләтсез дип тану турында карарны, шулай ук элек суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип танылган гражданны хокукка сәләтле дип тану хакында карарны кабул иткәч, кабул ителгән карар турында гражданның яшәү урыны буенча муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгына хәбәр итә.

8. Әлеге статьяның 4 – 7 өлешләрендә күрсәтелгән белешмәләр чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар регистрын булдыру һәм алып бару өчен айга кимендә бер тапкыр Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә

муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы тарафыннан тапшырыла.

9. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны теркәү һәм Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның санын билгеләү, “Сайлаулар” ДАСтан файдаланып, һәр елның 1 гыйнварына һәм 1 июленә гамәлгә ашырыла.

10. “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны теркәү (исәпкә алу), теркәлгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның санын билгеләү, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар регистрын булдыру һәм алып бару Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе раслый торган сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны дәүләт теркәве (исәпкә алуы) системасы турындагы нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

11. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы үзе турында документлаштырылган мәгълүматтан (персональ белешмәләрдән), шул исәптән машинада укыла торган чыганаклардагы мәгълүматтан, тоткарлыксыз файдаланырга, әлеге мәгълүматның тулылыгын һәм дөреслеген тәэмин итү максатларында аны төгәлләштерергә хокуклы, шулай ук әлеге мәгълүматны кем һәм нинди максатларда файдалануын яисә файдаланганын, аның кем тарафыннан һәм кемгә бирелгәнлеген белергә хокуклы.”;

5) 25 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“25 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләрен төзү**

1. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның хокукларын гамәлгә ашыру максатларында тиешле комиссияләр, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны дәүләт теркәве (исәпкә алуы) системасыннан файдаланып алынган һәм әлеге статьяның 5 өлеше нигезендә бирелә торган белешмәләргә нигезләнеп, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләрен төзи.

2. Чакыртып алу буенча тавыш бирү участокларында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләренә тавыш бирү көненә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашу хокукына ия Россия Федерациясе гражданнары кертелә.

3. Чакыртып алу буенча тавыш бирүнең конкрет участогында Россия Федерациясе гражданын чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертү өчен аның яшәү урынының әлеге участок территориясендә булуы факты, ә “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда, әлеге Законда, башка законда каралган очракларда – гражданның әлеге участок территориясендә булуы (вакытлыча булуы) факты (гражданның чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашу хокукы булганда) йә гражданның бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы булуы нигез була. Гражданның яшәү йә булу (вакытлыча булу) урынының чакыртып алу буенча тавыш бирүнең аерым бер участогы

территориясендә булуы факты Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны буенча һәм яшәү урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәп исәпкә ала торган органнар, ә “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда, әлеге Законда, башка законда каралган очракларда – шуңа вәкаләтле органнар, оешмалар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан билгеләнә.

4. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашу хокукына ия, тавыш бирү көненә кадәр кимендә өч ай кала чакыртып алу буенча тавыш бирүнең тиешле участогы территориясендә булу урыны буенча теркәлгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы, шул исәптән көндезге бүлектә укучы, тавыш бирү көненә кадәр 60 – 21 көн кала тиешле территория комиссиясенә бирелгән шәхси язма гаризасы нигезендә әлеге участокта чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелергә мөмкин. Гаризада чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының яшәү урыны адресы күрсәтелә. Гариза биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы, участок комиссиясенә исемлек тапшырылганчы, шул участокта чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелә. Участок комиссиясе тарафыннан чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеге төзелгән очракта, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы территория комиссиясеннән тапшырылган гариза нигезендә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелә. Бу хакта мәгълүмат әлеге чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы яшәү урыны буенча чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирү участогының участок комиссиясенә территория комиссиясе аша тапшырыла. Участок комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең тиешле юлында, чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы номерын һәм муниципаль район (шәһәр округы) исемен күрсәтеп, “____ номерлы чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелде” дигән тамга куя.

5. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар турында белешмәләрне муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы барлый һәм төгәлләштерә. Хәрби частьтәге чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы хәрби хезмәткәрләр турында, аларның гаилә әгъзалары һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә башка катнашучылар турында белешмәләр, әгәр алар хәрби часть урнашкан территориядә яшәсәләр йә хәрби часть каршындагы хезмәт итү урыны буенча билгеләнгән тәртиптә теркәлгән булсалар, хәрби часть командиры тарафыннан барлана һәм төгәлләштерелә. Вакытлыча булу урыннарындагы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар турында белешмәләрне комиссиягә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы вакытлыча булган оешманың җитәкчесе тапшыра. Күрсәтелгән белешмәләр шуңа вәкаләтле орган яисә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан территория комиссияләренә җибәрелә.

6. Территория комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеген билгеләнгән рәвеш буенча белешмәләр бирергә вәкаләтле орган яисә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан бирелә торган белешмәләр нигезендә, шул

исәптән “Сайлаулар” ДАСтан файдаланып, һәр чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы буенча аерым төзи.

7. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар турында белешмәләр бирүче затлар бу белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылыгы өчен, шулай ук аларны вакытында тапшыру өчен җаваплы булалар.

8. Россия Федерациясе гражданы бары тик бер чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында гына чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелә. Россия Федерациясе гражданының чакыртып алу буенча тавыш бирүнең төрле участокларында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләренә кертелү факты территория комиссиясе тарафыннан ачыкланганда, тиешле комиссия, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләрен участок комиссияләренә тапшырганчы, әлеге исемлекләрдәге хаталарны яисә төгәлсезлекләрне бетерү эшләрен башкара.

9. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеге ике нөсхәдә төзелә. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелүче чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар турындагы белешмәләр алфавит тәртибендә яисә бүтән тәртиптә (торак пунктлар, урамнар, йортлар, фатирлар буенча) урнаштырыла. Исемлектә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы (18 яшьтә булса – өстәмә буларак туган көне һәм ае), яшәү урынының адресы күрсәтелә. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегендә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы алган һәр бюллетень өчен имза салу, үз паспортының яисә граждан паспортын алмаштыра торган документының сериясен һәм номерын язу өчен, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирү буенча суммар күрсәткечләр кертү өчен һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыга чакыртып алу буенча тавыш бирү бюллетенен биргән участок комиссиясе әгъзасына имза салу өчен урыннар каралган булырга тиеш.

10. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең беренче нөсхәсенә исемлекне төзегән комиссия рәисе һәм секретаре имза сала. Хәрби часть территориясендә оештырылган чакыртып алу буенча тавыш бирү участокларында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә участок комиссиясе рәисе һәм секретаре имза сала. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеге тиешенчә территория комиссиясенең һәм (яисә) участок комиссиясенең мөһерләре белән таныклана. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең икенче нөсхәсен эшләү, куллану, аны тиешле участок комиссиясенә тапшыру, таныклау һәм төгәлләштерү тәртибе һәм сроклары Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

11. Тиешле территория комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүнең конкрет участогының чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең беренче нөсхәсен, тавыш бирү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, акт буенча участок комиссияләренә тапшыра. Участок комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең беренче нөсхәсен аерым китапларга бүләргә хокуклы. Һәр шундый китап, тавыш бирергә бер көннән дә соңга калмыйча, брошюраланырга (тегелергә) һәм тиешле участок комиссиясенең мөһере һәм аның рәисенең имзасы белән таныкланырга тиеш.

12. Участок комиссиясе комиссияләрнең җирле үзидарә органнары белән, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны теркәүче (исәпкә алучы) учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген оештыруның билгеләнгән тәртибе нигезендә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеген төгәлләштерә. Тикшерелгән һәм төгәлләштерелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеге, тавыш бирергә бер көннән дә соңга калмыйча, участок комиссиясе рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана һәм участок комиссиясе мөһере белән таныклана.

13. Участок комиссиясе тавыш бирү көненә кадәр 10 көн кала чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны таныштыру һәм өстәмә төгәлләштерүләр өчен чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеген тапшыра.

14. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашу хокукына ия Россия Федерациясе гражданы үзен чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертү турындагы, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә үзе хакында кертелгән белешмәләрдәге теләсә нинди хата яисә төгәлсезлек турындагы гариза белән участок комиссиясенә мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Участок комиссиясе мөрәҗәгать алынганнан соң 24 сәгать эчендә, ә тавыш бирү көнендә – ике сәгать эчендә, әмма тавыш бирү тәмамлану мизгеленнән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүче тарафыннан хәбәр ителгән белешмәләрне һәм тапшырылган документларны тикшерергә һәм йә хатаны яки төгәлсезлекне бетерергә, йә гаризаны кире кагу турында, аның кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, карар кабул итәргә, бу карарның таныкланган күчермәсен мөрәҗәгать итүчегә тапшырырга тиеш. Россия Федерациясе гражданын чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертү турындагы гаризаны кире кагу хакында участок комиссиясе карарына карата югарырак комиссиягә яисә судка (участок комиссиясе урнашкан урындагы) шикаять белдерелергә мөмкин, алар шикаятьне (гаризаны) федераль закон нигезендә өч көн эчендә, ә тавыш бирү көненә кадәр өч көн һәм аннан да азрак вакыт калганда һәм тавыш бирү көнендә – кичекмәстән карарга тиеш. Шикаятьне (гаризаны) канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән очракта, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә участок комиссиясе тарафыннан кичекмәстән төзәтмәләр кертелә. Тиешле чакыртып алу буенча тавыш бирү комиссияләре рәисләре һәм секретарьләре чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә имза салганнан һәм ул әлеге статьяның 10 өлешендә каралган тәртиптә мөһерләр белән таныкланганнан соң, Россия Федерациясе гражданын чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегеннән төшереп калдыру бары тик рәсми документлар, шул исәптән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыны бүтән чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертү турында югарырак комиссия хәбәре нигезендә, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән очракта гына башкарыла. Мондый очракта чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегендә, шулай ук “Сайлаулар” ДАС мәгълүматлар базасында Россия Федерациясе гражданын исемлектән төшереп калдыру датасы, шулай ук мондый төшереп калдыруның сәбәбе күрсәтелә. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегендәге язма участок

комиссиясе рәисенең имзасы, ә бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгәндә – бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын биргән комиссия әгъзасының имзасы белән бу имзаны куйган датаны күрсәтеп таныклана. Россия Федерациясенең һәр гражданы чакыртып алу буенча тавыш бирүнең тиешле участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар хакындагы әлеге Законның 24 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрнең үзгәрүе турында участок комиссиясенә хәбәр итәргә хокуклы.

15. Вакытлыча булу урыннарындагы, өзлексез эш циклы булган предприятиеләрдә һәм эш (смена) дәвамлылыгын кыскарту мөмкин булмаган аерым төр эшләрдә эшләүче чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар, шулай ук хәрби часть урнашкан урыннан читтәге хәрби хезмәткәрләр булган чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар, тавыш бирү көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча, участок комиссиясенә шәхсән бирелгән язма гаризалары нигезендә аларның вакытлыча тору урыны буенча чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында участок комиссиясе карары белән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелергә мөмкин. Бу хакта мәгълүмат тиешле территория комиссиясе аша әлеге чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының яшәү урыны буенча чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән участок комиссиясенә тапшырыла. Участок комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегендәге тиешле юлда: "__ номерлы чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелде" дигән тамга куя, чакыртып алу буенча тавыш бирү участогының номерын күрсәтә.

16. Тавыш бирү тәмамланганнан соң һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын санау башланганнан соң чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә нинди дә булса үзгәрешләр кертү тыела.

17. Чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре рәсми басылып чыкканнан соң чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләрендәге чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар турындагы мәгълүматтан чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар регистрында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар турындагы белешмәләрне төгәлләштерү өчен файдаланырга мөмкин.";

6) 28 статьяда:

а) 1 өлештә "оешмалар," сүзеннән соң "Интернет" челтәре басмалары редакцияләре," сүзләрен өстәргә;

б) 4 һәм 5 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмаларның, "Интернет" челтәре басмалары редакцияләренең чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга мәгълүмат җиткерүдәге федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлеге ирекле башкарыла.

5. Хәбәри телетапшыруларда һәм радиотапшыруларда, вакытлы матбугат басмаларындагы публикацияләрдә, "Интернет" челтәре басмаларының куелган саннарында яисә яңартылган саннарында чакыртып алу буенча тавыш бирүгә бәйле

чаралар үткәрү турындагы хәбәрләр бары тик аерым мәгълүмат блогы белән, комментарийларсыз, бирелергә тиеш. Мондый мәгълүмат блоклары өчен инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркеме акча түләми. Аларда төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркеменә өстенлек бирелмәскә тиеш, дискриминациягә (хокукларны кысуга), шул исәптән аларның чакыртып алу буенча тавыш бирүне үткәрү белән бәйле эшчәнлеген яктырту вакыты, мондый хәбәрләргә бирелгән матбугат мәйданының күләме буенча, юл куелмаска тиеш.";

в) 8 өлештә "катнашучы" сүзен "катнашучы (катнашкан)" сүзләренә алмаштырырга, "оешманың" сүзеннән соң ", "Интернет" челтәре басмасы редакциясенең" сүзләрен өстәргә;

7) 30 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 һәм 5 өлешләр өстәргә:

"4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон нигезендә, чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турында карар рәсми бастырып чыгарылган (басылган) көннән соңгы бишенче көннән дә соңга калмыйча, мәгълүмат чараларын теркәү функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының массакүләм территориаль органына чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырылган) көнгә Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм оешмалары гамәлгә куючылары (уртак гамәлгә куючылары) яисә редакцияләрен гамәлгә куючылар (уртак гамәлгә куючылар) булып торган һәм (яисә) чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турында карар рәсми бастырып чыгарылган (басылган) көнгә кадәрге елда Татарстан Республикасы бюджетыннан аларның эшләве өчен каралган бюджет ассигнованиеләре (шул исәптән субсидияләр рәвешендә) бирелгән (мондый ассигнованиеләрнең төре һәм күләме турында белешмәләр күрсәтелә), һәм (яисә) чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турында карар рәсми бастырып чыгарылган (басылган) көнгә устав (җыелма) капиталында Татарстан Республикасының өлеше (кертеме), Татарстан Республикасының Россия Федерациясенең башка субъектлары белән уртак өлеше (кертеме) булган телерадиотапшырулар оешмаларының һәм вакытлы матбугат басмаларының исемлеген тапшыра.

5. Җирле үзидарә органы "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон нигезендә массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органына "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 47 статьясындагы 3 пункты шартларына туры килә торган телерадиотапшырулар оешмаларының һәм вакытлы матбугат басмаларының исемлеген чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турында карар рәсми бастырып чыгарылган (басылган) көннән соң бишенче көннән дә соңга калмыйча тапшыра, анда аларның эшләве өчен чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турында карар рәсми

бастырып чыгарылган (басылган) көнгә кадәрге елда җирле бюджеттан каралган бюджет ассигнованиеләре (шул исәптән субсидияләр рәвешендә) бирелгән телерадиотапшырулар оешмаларын һәм вакытлы матбугат басмаларын, мондый ассигнованиеләрнең төрен һәм күләмен күрсәтә.”;

8) 31 статьяда:

а) 2 өлешнең 1 пунктында “һәм вакытлы матбугат басмаларында” сүзләрен “, вакытлы матбугат басмаларында һәм “Интернет” челтәре басмаларында” сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 өлештә:

2 пунктта “файдаланып;” сүзен “файдаланып. Агитация материалында мондый затның вазыйфасын күрсәтү әлеге тыюны бозу дип саналмый;” сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта “оешмалар вәкилләренә” сүзләреннән соң “һәм “Интернет” челтәре басмалары вәкилләренә” сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле $7^1$ өлеш өстәргә:

“$7^1$. Агитация материалларында әлеге Закон нигезендә чакыртып алу буенча агитация алып барырга хокукы булмаган физик затның чакыртып алу буенча тавыш бирү уздыру мәсьәләләренә кагылышлы сүзләрен куллану рөхсәт ителми.”;

г) 8 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“8. Агитация материалларында әлеге статьяның $7^1$ өлешендә күрсәтелмәгән физик затның чакыртып алу буенча тавыш бирү уздыру мәсьәләләренә кагылышлы сүзләрен куллану әлеге физик затның язма ризалыгы белән генә рөхсәт ителә. Мондый ризалыкны раслый торган документ Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә әлеге Законның 37 статьясындагы 4 өлеше нигезендә тапшырыла торган агитация материаллары нөсхәләре белән бергә тапшырыла. Агитация материалы телерадиотапшырулар оешмасы каналына яисә вакытлы матбугат басмасына урнаштырылган очракта, күрсәтелгән документ Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә аның таләбе буенча тапшырыла.”;

д) түбәндәге эчтәлекле 9 өлеш өстәргә:

“9. Чакыртып алу буенча тавыш бирү уздырганда, агитация материалларында физик затның сурәтен куллану әлеге физик затның язма ризалыгы белән генә рөхсәт ителә. Мондый ризалыкны раслый торган документ Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә әлеге Законның 37 статьясындагы 4 өлеше нигезендә тапшырыла торган агитация материаллары нөсхәләре белән бергә тапшырыла. Агитация материалы телерадиотапшырулар оешмасы каналына яисә вакытлы матбугат басмасына урнаштырылган очракта, күрсәтелгән документ Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә аның таләбе буенча тапшырыла.”;

9) 32 статьяда:

а) 1 һәм 2 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Агитация чоры чакыртып алуны уздыру буенча инициатив төркемне теркәгән көннән башлана һәм тавыш бирү көненә кадәрге көндә җирле вакыт белән ноль сәгатьтә тәмамлана.

2. Телерадиотапшырулар оешмалары каналларында, вакытлы матбугат басмаларында һәм “Интернет” челтәре басмаларында чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация тавыш бирү көненә кадәр 28 көн кала башлана һәм тавыш бирү көненә кадәрге көндә җирле вакыт белән ноль сәгатьтә тәмамлана.”;

б) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Әлеге Закон нигезендә алдан әзерләнгән һәм әлеге Законның 37 статьясындагы 7 өлешендә күрсәтелгән махсус урыннарга, реклама конструкцияләренә яисә әлеге Законның 37 статьясындагы 8 һәм 10 өлешләре нигезендә даими торучы башка объектларга законда билгеләнгән тәртиптә урнаштырылган агитация материаллары (листовкалар, плакатлар һәм башка материаллар) тавыш бирү көнендә шул ук урыннарында калдырылырга мөмкин.”;

в) түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

“5. Тавыш бирү яңадан уздырылган очракта, агитация чоры тавыш бирүне яңадан уздыру көне билгеләнгән көннән яңадан башлана һәм әлеге статьяның 2 өлеше нигезендә тәмамлана.”;

10) 33 статьяда:

а) исемдә “һәм вакытлы матбугат басмаларында” сүзләрен “, вакытлы матбугат басмаларында һәм “Интернет” челтәре басмаларында” сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 – 8 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Чакыртып алу кампаниясе башланырга кимендә бер ел кала теркәлгән массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы дәүләтнеке булмаган телерадиотапшырулар оешмалары, дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре һәм “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре, күрсәтелгән оешмалар һәм редакцияләр әлеге статьяның 4 һәм 5 өлешләрендә каралган таләпләрне үтәгән очракта, инициатив төркемгә һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә түләүле эфир вакыты, түләүле матбугат мәйданы бирергә, “Интернет” челтәре басмаларында агитация материалларын урнаштыру буенча түләүле хезмәтләр күрсәтергә хокуклы. Дәүләтнеке булмаган бүтән телерадиотапшырулар оешмалары, дәүләтнеке булмаган бүтән вакытлы матбугат басмалары редакцияләре, “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә эфир вакыты, матбугат мәйданы бирергә хокуксыз.

4. Дәүләтнеке булмаган телерадиотапшырулар оешмалары, дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре һәм “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре тарафыннан бирелә торган эфир вакыты, матбугат мәйданы, агитация материалларын урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү шартлары инициатив төркем һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәре өчен бердәй булырга тиеш. Бу таләп инициатив төркемгә керүче гражданнар тарафыннан гамәлгә куелган дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләренә, “Интернет” челтәре басмалары редакцияләренә кагылмый.

5. Чакыртып алу буенча тавыш бирү уздырганда, эфир вакыты, матбугат мәйданы, агитация материалларын урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү күләме (Россия Федерациясе валютасында) һәм башка шартлары турындагы белешмәләр телерадиотапшырулар оешмасы, вакытлы матбугат басмасы редакциясе, “Интернет” челтәре басмасы редакциясе тарафыннан бастырып чыгарылырга һәм беренче агитация материалы бастырып чыгару көненә кимендә бер көн кала Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә аларны бастырып чыгару көне һәм чыганагы турындагы мәгълүмат, массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турындагы таныклыкның теркәү номеры һәм бирү датасы хакындагы белешмәләр һәм чакыртып алу буенча тавыш бирү мәсьәләләре буенча агитация алып бару өчен эфир вакыты, матбугат мәйданы бирергә, “Интернет” челтәре басмасында агитация материалларын урнаштыру буенча хезмәтләр күрсәтергә әзер булуы турындагы хәбәрнамә белән бергә тапшырылырга тиеш.

6. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән хәбәрнамәне шул өлештә билгеләнгән срокларда тапшырмау юлы белән белдереп, түбәндәгеләр чакыртып алу буенча тавыш бирү мәсьәләләре буенча агитация алып бару өчен эфир вакыты, матбугат мәйданы бирүдән, “Интернет” челтәре басмасында агитация материалларын урнаштыру буенча хезмәтләр күрсәтүдән баш тарта ала:

а) дәүләтнеке булмаган телерадиотапшырулар оешмалары һәм дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре;

б) атнасына бер мәртәбәдән сирәгрәк чыга торган дәүләтнеке булган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре;

в) махсуслаштырылган телеканаллар, радиоканаллар, телетапшырулар, радиотапшырулар чыгаруны гамәлгә ашыручы телерадиотапшырулар оешмалары һәм махсуслаштырылган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре;

г) “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре;

д) муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары һәм муниципаль вакытлы матбугат басмалары редакцияләре.

7. Массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар, “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре, милек рәвеше нинди булуга карамастан, чакыртып алу буенча агитация алып бару өчен бирелгән эфир вакытының һәм матбугат мәйданының күләмнәрен һәм хакын, “Интернет” челтәре басмаларында агитация материалларын урнаштыру буенча хезмәтләр күрсәтү күләмнәрен һәм хакын исәпкә алуны, мондый исәпкә алуларны башкаруның Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән рәвешләренә туры китереп, аерым-аерым алып барырга һәм шундый исәпкә алу күрсәткечләрен, тавыш биргән көннән соңгы ун көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырырга тиеш.

8. Массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар, “Интернет” челтәре басмалары редакцияләре түләүсез һәм түләүле рәвештә эфир вакыты һәм матбугат мәйданын бирү, “Интернет” челтәре басмаларында агитация материалларын урнаштыру буенча хезмәтләр күрсәтү турындагы әлеге статьяның 7 һәм 10 өлешләрендә күрсәтелгән документларны тавыш биргән көннән соң кимендә өч ел сакларга тиеш.”;

в) 10 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“10. Чакыртып алу буенча агитация алып бару өчен телерадиотапшырулар оешмалары каналларында эфир вакытын, вакытлы матбугат басмаларында матбугат мәйданын бирү, “Интернет” челтәре басмаларында агитация материалларын урнаштыру буенча хезмәтләр күрсәтү, телерадиотапшырулар оешмасы, вакытлы матбугат басмасы редакциясе, “Интернет” челтәре басмасы редакциясе белән инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркеме вәкиле арасында язма рәвештә төзелгән шартнамәгә нигезләнеп, эфир вакыты, матбугат мәйданы бирелгәнче, хезмәтләр күрсәтелгәнче гамәлгә ашырыла.”;

11) 34 статьяда:

а) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Инициатив төркем бергәләп уздырылучы агитация чарасында катнашудан баш тартканда, бергәләп уздырылучы агитация чарасында катнашу өчен инициатив төркемгә бирелгән эфир вакытына туры килгән өлеш, федераль законда каралган очраклардан тыш, шушы бергәләп уздырылучы агитация чарасында башка катнашучылар арасында бүленә (шул исәптән әгәр әлеге чарада бер генә катнашучы катнаша алса да).”;

б) 7 өлешнең өченче җөмләсендә “Резервта” сүзен “Әгәр федераль законда башкасы каралмаган булса, резервта” сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Түләүле эфир вакыты шул рәвешле бүленгәннән соң бүленмәгән эфир вакыты калса, ул мондый эфир вакытын бирүгә гариза биргән инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемнәренә бертигез шартларда түләүле бирелергә мөмкин.”;

12) 35 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Түләүле матбугат мәйданы шул рәвешле бүленгәннән соң бүленмәгән матбугат мәйданы калса, ул мондый матбугат мәйданын бирүне сорап гариза язган инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемнәренә бертигез шартларда түләүле бирелергә мөмкин.”;

13) 37 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Басма агитация материалларын әзерләү буенча эшләр башкаручы яисә хезмәтләр күрсәтүче оешмалар, индивидуаль эшкуарлар инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә бу материалларны әзерләү өчен түләүнең бертигез шартларын тәэмин итәргә тиеш. Басма агитация материалларын әзерләү буенча әлеге оешмаларның, индивидуаль эшкуарларның эшләре һәм хезмәт күрсәтүләре өчен түләү күләме (Россия Федерациясе валютасында) һәм башка шартлар турындагы белешмәләр инициатив төркемне теркәү турындагы карар рәсми бастырып чыгарылган (басылган) көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча тиешле оешма, тиешле индивидуаль эшкуар тарафыннан бастырып чыгарылырга һәм шул ук срокта Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырылырга тиеш. Татарстан Республикасы Үзәк

сайлау комиссиясенә әлеге белешмәләр белән бергә шулай ук оешманың исемен, юридик адресын һәм салым түләүче идентификация номерын (индивидуаль эшкуарның фамилиясен, исемен, атасының исемен, аның яшәү урыны булган Россия Федерациясе субъекты, район, шәһәр, башка торак пункт исемен) үз эченә алган белешмәләр тапшырылырга тиеш.";

б) 4 өлештә "фотографияләре" сүзеннән соң "яисә нөсхәләре" сүзләрен, икенче җөмләдә "белешмәләр" сүзеннән соң "һәм шушы агитация материалын әзерләгән өчен чакыртып алу буенча тавыш бирүнең тиешле фондыннан түләү хакындагы документның күчермәсе" сүзләрен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Чакыртып алу буенча тавыш бирү уздырганда комиссиягә күрсәтелгән материаллар белән бергә әлеге агитация материалларының машина укый алырлык рәвештәге электрон рәсемнәре тапшырылырга тиеш.";

в) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Басма агитация материалларын әлеге статьяның 2 өлешендә каралган таләпләрне үтәмәгән оешмаларда һәм индивидуаль эшкуарларда йә индивидуаль эшкуарлар булмаган физик затлар белән төзелгән шартнамә нигезендә әзерләү, шулай ук агитация материалларын чакыртып алу буенча тавыш бирүнең тиешле фонды акчалары исәбеннән алдан түләмичә, әлеге Законның 31 статьясындагы 5, 6 һәм $7^1$ өлешләрендә, әлеге статьяның 3 өлешендә билгеләнгән таләпләрне бозып әзерләү тыела.";

г) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6. Әлеге статьяның 5 өлешен бозып һәм (яисә) әлеге статьяның 4 өлешендә, әлеге Законның 31 статьясындагы 8 һәм 9 өлешләрендә каралган таләпләрне бозып әзерләнгән агитация материалларын тарату тыела.";

д) 8 өлештә "эленергә (ябыштырылырга, урнаштырылырга)" сүзләрен "урнаштырылырга" сүзенә алмаштырырга;

е) 9 һәм 10 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9. Агитация материалларын әзерләү һәм урнаштыру эшләрен башкаручы (алар буенча хезмәт күрсәтүче) оешмалар, индивидуаль эшкуарлар инициатив төркемгә һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемнәренә үз эшләре (хезмәт күрсәтүләре) өчен түләүнең бертигез шартларын тәэмин итәргә тиеш.

10. Агитация материалларын һәйкәлләргә, обелискларга, биналарга, корылмаларга һәм тарихи, мәдәни һәм архитектура кыйммәте булган урыннарга урнаштыру тыела. Агитация материалларын чакыртып алу комиссияләре урнашкан биналарга, тавыш бирү өчен каралган урыннарга һәм аларга керә торган җирдән 50 метрдан якынрак урнаштыру тыела.";

14) 39 статьяда:

а) 4 өлештә "ә алар булмаган очракта Россия Федерациясе Саклык банкы филиалларында" сүзләрен "ә алар чакыртып алу буенча комиссия урнашкан торак пунктта булмаган очракта – "Россия Саклык банкы" гавами акционер җәмгыяте филиалларында" сүзләренә алмаштырырга;

б) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“7. Чакыртып алу буенча комиссия бүлмәләренә куела торган бюллетеньнәр, чакыртып алу буенча бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары, махсус билгеләр (маркалар), мәгълүмат бирә торган материалларны, чакыртып алу буенча тавыш бирүгә әзерләнүгә һәм аны уздыруга бәйле документларны китерү буенча хезмәт күрсәтүләрне, чакыртып алу буенча комиссияләрнең чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздырганда файдаланыла торган башка җибәрелергә тиешле материалларны сатып алу “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.”;

15) 40 статьяда:

а) 10 өлешнең беренче һәм икенче җөмләләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Чакыртып алу буенча тавыш бирү фондын барлыкка китерүче барлык акчалар чакыртып алу буенча тавыш бирү фондының Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рөхсәте белән инициатив төркемнең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкиле тарафыннан “Россия Саклык банкы” гавами акционер җәмгыяте филиалында, ә ул Татарстан Республикасы территориясендә булмаганда – Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан башка кредит оешмасында ачылган махсус счетына күчерелә. Татарстан Республикасы территориясендә кредит оешмалары булмаган очракта, инициатив төркем, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе белән килештереп, чакыртып алу буенча тавыш бирү фондының махсус счеты ачылачак кредит оешмасын билгели.”;

б) 14 өлешнең беренче абзацында “сайтына” сүзен “рәсми сайтына” сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 16 өлеш өстәргә:

“16. Законда каралган һәм анда билгеләнгән тәртипкә туры китереп рәсмиләштерелгән документларны күрсәткәннән соң “Россия Саклык банкы” гавами акционер җәмгыятенең, ә “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда билгеләнгән очракларда – башка кредит оешмасының филиаллары кичекмәстән чакыртып алу буенча тавыш бирү фондының махсус счетын ачарга тиеш. Счет ачу һәм счет буенча операцияләр башкару хезмәтләрен күрсәткән өчен түләү алынмый. Счеттагы акчалардан файдаланган өчен процентлар исәпләнми һәм түләнми. Счетка барлык акчалар да Россия Федерациясе валютасында күчерелә.”;

16) 42 статьяның 2 өлешендә “Россия Федерациясе Саклык банкы” сүзләрен “Россия Саклык банкы” гавами акционер җәмгыяте” сүзләренә алмаштырырга;

17) 43 статьяның 6 өлешендә “барлык” сүзен төшереп калдырырга;

18) түбәндәге эчтәлекле $43^1$ статья өстәргә:

“$43^1$ статья. **Чакыртып алу буенча бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы**

1. Әлеге Законның 46[1] статьясындагы 2 өлешендә каралган очракларда тавыш бирү бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча уздырыла.

2. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирү участогының тавыш бирү бинасына тавыш бирү көнендә килә алмаган чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы тиешле федераль законда билгеләнгән срокларда территория комиссиясендә йә участок комиссиясендә бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын алырга һәм, тавыш бирү көнендә Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашу хокукы булган чакыртып алу буенча тавыш бирүнең кайсы участогында булса, шул участокта тавыш бирүдә катнашырга хокуклы.

3. Федераль законда билгеләнгән очракларда, чакыртып алу буенча бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү срокларын билгеләгәндә федераль закон нормалары кулланыла.

4. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары катгый хисаплылык документлары була һәм чакыртып алу буенча тавыш бирү уздырыла торган бөтен территориядә бердәм нумерациягә ия. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы әлеге Законның 1[1] кушымтасы нигезендәге рәвеш буенча әзерләнә. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы тексты, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының рәвеше тавыш бирү көненә кимендә 60 көн кала Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе шулай ук бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын әзерләгәндә аларны охшатып ясаудан саклау ысулларын да билгели.

5. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын охшатып ясаудан саклау максатларында, аларны әзерләгәндә су билгеләре булган һәм (яисә) типография ысулы белән төшерелгән микрошрифтлы язу һәм (яисә) саклагыч челтәр булган кәгазь һәм (яисә) бүтән махсус саклау чаралары кулланыла.

6. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын сатып алу Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан аның карары нигезендә үзәкләштерелгән рәвештә гамәлгә ашырыла.

7. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы комиссия тарафыннан чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы таләп ителү сәбәбен күрсәткән язма гаризасы нигезендә бирелә. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының шәхсән үзенә йә нотариаль таныкланган ышанычнамә нигезендә аның вәкиленә тапшырыла. Ышанычнамә шулай ук стационар дәвалау-профилактикалау учреждениесе администрациясе тарафыннан (әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы шул учреждениедә дәвалана торган булса), шик белдерелгән яисә гаепләнүче затлар сак астында тотыла торган учреждение администрациясе тарафыннан (әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы шик белдерелгән яисә гаепләнүче зат буларак шул учреждениедә тотылса) таныкланырга мөмкин.

8. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын бирүче комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы таныклыкка чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, аның паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирү участогының номерын, участок комиссиясенең адресын, муниципаль берәмлекнең һәм Россия Федерациясе субъектының исемнәрен, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын биргән комиссия исемен кертә. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын бирүче комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгында үзенең фамилиясен һәм инициалларын, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән датаны күрсәтә, имза сала һәм тиешле комиссиянең мөһерен суга.

9. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын алганда, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының яисә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең тиешле графаларында үз паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын күрсәтә һәм имза сала. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының яшәү урынының адресы күрсәтелергә тиеш. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының вәкиле ышанычнамә нигезендә алган очракта, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының яисә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең тиешле графаларында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының паспорты яисә граждан паспортын алмаштыручы документы сериясе һәм номеры күрсәтелә, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының вәкиле үзенең фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын күрсәтә һәм имза сала. Шуннан соң чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының вәкиленнән ышанычнамә алына һәм тиешенчә бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрына, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә теркәп куела.

10. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын биргән территория комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының тиешле графаларында күрсәтә һәм имза сала. Территория комиссиясе тавыш бирү көненә кадәр участок комиссияләренә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең беренче нөсхәсе белән бергә бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрыннан таныкланган өземтәләрне җибәрә, аларда чакыртып алу буенча тавыш бирүнең тиешле участоклары территорияләрендә теркәлгән, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары алган чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар турында белешмәләр күрсәтелә. Тиешле өземтә нигезендә участок комиссиясе әгъзасы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең тиешле графасында, бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын

күрсәтеп, “Территория комиссиясендә _____ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы алды” дигән тамга куя һәм имза сала.

11. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы участок комиссиясендә бирелгәндә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын биргән участок комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең тиешле графасында, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтеп, “_____ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы алды” дигән тамга куя һәм имза сала.

12. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы (шул исәптән ышанычнамә нигезендә аның вәкиле аша) әлеге чакыртып алу буенча тавыш бирүдә чакыртып алу буенча тавыш бирүнең тиешле участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегеннән төшереп калдырыла һәм, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсе төзелгәндә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә теркәлгән катнашучылар санында исәпкә алынмый.

13. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын кабат бирү рөхсәт ителми. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы югалган очракта, аның дубликаты бирелми.

14. Файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары тавыш бирү көнендә тавыш бирү вакыты башланганчы юкка чыгарыла. Файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын юкка чыгару турындагы белешмәләр, аларның санын, шулай ук бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының номерларын күрсәтеп, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе раслаган форма буенча төзелгән актка тиешле комиссия тарафыннан кертелә.

15. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын тавыш бирү көнендә күрсәткәч, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы тавыш бирү көнендә чакыртып алу буенча тавыш бирүнең кайсы участогында булса, шул чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә өстәмә рәвештә кертелә. Участок комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең тиешле графасында, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы күрсәткән бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын язып куеп, “_____ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш бирде” дигән тамга куя. Шуннан соң бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыдан алына. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертү өчен нигез булган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары әлеге исемлек белән бергә саклана.

16. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының бланкы югалган очракта, мондый югалу фактын ачыклаган комиссия кичекмәстән тиешле акт төзи һәм карар кабул итә, карарда бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының югалган бланкы номеры, бланкның югалу факты һәм югалу сәбәбе күрсәтелә. Бу карар шул ук көнне турыдан-туры югарырак комиссиягә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә җиткерелә. Шушы карар нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе бүтән участокта тавыш бирүнең тиешле таныклыгын гамәлдә

түгел дип таный, шул хакта кичекмәстән барлык түбәнгерәк комиссияләргә хәбәр итеlә. Әгәр бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү гражданнарның чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашу хокукын бозуга китерсә, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары шулай ук башка очракларда да Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан гамәлгә яраксыз дип танылырга мөмкин. Бүтән участокта тавыш бирүнең гамәлгә яраксыз таныклыгы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыны чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертү өчен нигез булмый. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы бүтән участокта тавыш бирүнең мондый таныклыгын күрсәтсә, бу таныклык аннан алынырга тиеш.

17. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын комиссияләргә тапшыру һәм бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының исәбен алып бару тәртибе, шул исәптән "Сайлаулар" ДАСтан файдаланып, "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана.";

19) 45 статьяның 4 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Үтә күренмәле тавыш бирү әрҗәләре кулланылган очракта, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча бу максатларда конвертлардан файдаланган очрактан тыш, бюллетеньнең рәвеше тавыш бирү серен саклау ихтыяҗын исәпкә алып билгеләнә.";

20) 46 статьяда:

а) 1 өлештә "яшәү урыны" сүзләреннән соң "(булу урыны)" сүзләрен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән затларга тавыш бирү урыннарына керү тавыш бирү башланганчы кимендә бер сәгать кала тәэмин ителергә тиеш.";

б) 2 өлештә "Тавыш бирү вакыты" сүзләрен "Тавыш бирү көне, вакыты" сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

"$2^1$. Хәрби частьләрдә төзелгән чакыртып алу буенча тавыш бирү участокларында, әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән барлык чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тавыш бирсә, участок комиссиясе тавыш бирүне әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә билгеләнгән вакыттан иртәрәк тәмамланган дип игълан итәргә мөмкин.";

г) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Бюллетеньнәр чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга паспортын яисә граждан паспортын алмаштыручы документын күрсәткәч, әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш бирсә, – бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын күрсәткәч бирелә.";

д) 6 өлешкә түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче җөмлә өстәргә: “Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш биргән очракта, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә өстәмә тамгалар куела.”;

е) 11 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әлеге Законның 45 статьясындагы 4 өлеше нигезендә конвертлардан файдалану турында карар кабул итсә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы тутырылган бюллетеньне яшерен тавыш бирү кабинасыннан яисә мондый тавыш бирү өчен махсус җиһазландырылган башка урыннан читтә аңа участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы биргән конвертка сала, аны ябыштырып куя, шуннан соң бу конвертны тавыш бирү әрҗәсенә төшереп җибәрә.”;

ж) түбәндәге эчтәлекле $11^1$ һәм $11^2$ өлешләр өстәргә:

“$11^1$. Участок комиссиясе рәисе тавыш бирү урынында тәртипне саклый. Участок комиссиясе рәисенең үз компетенциясе чикләрендә бирелгән күрсәтмәләре тавыш бирү урынындагы һәркем өчен мәҗбүри. Участок комиссиясе рәисе булмаганда, аның вәкаләтләрен участок комиссиясенең рәис урынбасары, ә участок комиссиясенең рәис урынбасары булмаганда – участок комиссиясе секретаре яисә участок комиссиясенең аның тарафыннан вәкаләт бирелгән хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы башкара.

$11^2$. Тавыш бирүне уздырганда, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын санаганда һәм участок комиссиясенең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәсен төзегәндә участок комиссиясе бүлмәсендә әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән затлар булырга хокуклы. Бу затлар күзәтүнең бөтен чоры дәвамында өзлексез дә, үзләре ирекле рәвештә сайлаган вакыт аралыкларында да күзәтергә хокуклы, аларга тавыш бирү һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын санау уздырыла торган бүлмәгә (бүлмәләргә) ирекле керү тәэмин ителә. Тавыш бирү барышын һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын санауны күзәткән затларның исемлеге участок комиссиясе тарафыннан әлеге затлар тапшырган документларга нигезләнеп төзелә.”;

з) 12 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“12. Әгәр участок комиссиясе әгъзасы, күзәтүче һәм башка затлар законны бозсалар һәм мондый хокук бозу факты суд тәртибендә билгеләнсә, участок комиссиясе әгъзасы кичекмәстән комиссия эшендә катнашудан читләштерелә, ә күзәтүче һәм башка затлар тавыш бирү урыныннан чыгарыла. Тиешле суд карарын үтәүне “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә хокук саклау органнары тәэмин итәләр. Хокук саклау органнары федераль законнар нигезендә шулай ук тавыш бирү урынында һәм чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы территориясендә гражданнарның иминлеген һәм җәмәгать тәртибен тәэмин итәләр.”;

21) $46^1$ статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Законда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү каралган чакыртып алу буенча тавыш бирү көне федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда тавыш бирү көне белән берләштерелгән очракта, әлеге статьяның 1 өлешендә каралган вакытыннан алда тавыш бирү үткәрелми. Чакыртып алу буенча күрсәтелгән тавыш бирүне уздырганда, тавыш бирү бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча үткәрелә.”;

б) 9 өлештә “көннән дә соңга калмыйча” сүзләреннән соң “яисә участок комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш бирүне башлау көненә кадәрге көннән дә соңга калмыйча” сүзләрен өстәргә;

22) 47 статьяда:

а) 1 өлешнең беренче җөмләсендә “кертелгән” сүзен “кертелергә хокуклы яисә кертелгән” сүзләренә алмаштырырга, икенче җөмләсендә “кертелгән” сүзе татарча текстта үзгәрешсез кала;

б) 2 өлешкә “(телдән мөрәҗәгатьләрне)” сүзләреннән соң “гариза (телдән мөрәҗәгать) бирелгән көнне үк” сүзләрен өстәргә;

в) 10 өлештә “гаризалар (телдән мөрәҗәгатьләр) буенча чыгучы” сүзләрен “хәлиткеч тавыш хокукына ия, тавыш бирүне тавыш бирү бинасыннан читтә уздыручы” сүзләренә алмаштырырга, “чыгып китү” сүзләрен “комиссия әгъзалары китү (чыгу)” сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче җөмлә өстәргә: “Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә тиешле катнашучы янына участок комиссиясе әгъзаларының китүе (чыгуы) хакында тамга куела.”;

23) 48 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

“$2^1$. Тавыш бирү бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча үткәрелгән очракта, тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә шулай ук түбәндәге юллар кертелә:

11а юлы: участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

11б юлы: тавыш бирү көненә кадәр чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга участок комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

11в юлы: бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар саны;

11г юлы: чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

11д юлы: чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга территориаль комиссия тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

11е юлы: югалган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны.”;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Әлеге статьяның 2 һәм $2^1$ өлешләрендә күрсәтелгән саннар тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә цифрлар һәм сүзләр белән кертелә.”;

24) 49 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән затларга, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын санаганда, булу һәм санауны күзәтү мөмкинлеге бирелергә тиеш.”;

б) 5 өлештә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) тавыш бирү тәмамланган мизгелгә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар санын (бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары территория комиссиясе һәм участок комиссиясе тарафыннан бирелгән, шулай ук башка сәбәпләр аркасында төшеп калган чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар санын исәпкә алмыйча);”;

түбәндәге эчтәлекле $3^2 – 3^4$ пунктлар өстәргә:

“$3^2$) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында участок комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

$3^3$) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга территория комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

$3^4$) бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар саны.”;

в) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6. Әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән күрсәткечләр кертелгәннән соң чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең һәр битенә комиссиянең әлеге күрсәткечләрне керткән әгъзасы имза сала, ул бу күрсәткечләрне кушып берләштерә, игълан итә һәм участок комиссиясе рәисенә, рәис урынбасарына яисә секретарена һәм тавышларны санауда катнашкан затларга хәбәр итә. Участок комиссиясе рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре әлеге статьяның 5 өлеше нигезендә билгеләнгән күрсәткечләр суммасын тәшкил иткән йомгак күрсәткечләрне игълан итә, аларны чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең соңгы битенә кертә, үзенең имзасы һәм участок комиссиясе мөһере белән таныклый. Игълан ителгән күрсәткечләр тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең тиешле юлларына кертелә, ә тавышларны техник чаралар кулланып санаганда – зурайтылган беркетмәнең бары тик тиешле юлларына гына кертелә:

а) 1 юлга – тавыш бирү тәмамланган мизгелгә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар саны;

б) 3 һәм 4 юлларга – вакытыннан алда тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

в) 5 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга тапшырылган бюллетеньнәр саны;

г) 6 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга тапшырылган бюллетеньнәр саны;

д) 11а юлына – участок комиссиясе алган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

е) 11б юлына – чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга участок комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

ж) 11в юлына – бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар саны;

з) 11г юлына – чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

и) 11д юлына – чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга территория комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны.

Әлеге гамәлләрне башкарганнан соң түбәндәге контроль чагыштырманы тикшерү уздырыла: участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны тавыш бирү көненә кадәр чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга участок комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны һәм чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны суммасына тигез булырга тиеш. Әгәр әлеге контроль чагыштырма үтәлмәсә, участок комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән күрсәткечләрне һәм юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын өстәмә санау турында карар кабул итә. Әгәр өстәмә санау нәтиҗәсендә әлеге контроль чагыштырма тагын да үтәлмәсә, участок комиссиясе тиешле карар кабул итә, ул тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә теркәп куела, һәм участок комиссиясе аерма турындагы мәгълүматны тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 11е юлына кертә. Әгәр контроль чагыштырма үтәлсә, 11е юлына “0” цифры куела.

Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 11а, 11б, 11в, 11г, 11д һәм 11е юлларына күрсәткечләр, әгәр законда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү каралган булса, кертелә.

Шуннан соң чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеге белән күзәтүчеләр һәм әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затлар танышырга хокуклы, ә участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары башкарылган санауның дөреслегенә инанырга хокуклы.”;

г) 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“11. Бюллетеньнәрне сортларга аерганда участок комиссиясе билгесез рәвештәге, ягъни рәсми булмаган юл белән әзерләнгән йә күрсәтелгән комиссия тарафыннан таныкланмаган яисә махсус билгесе (маркасы) булмаган бюллетеньнәрне, әгәр алар кулланылган булса, аерып куя. Билгесез рәвештәге

бюллетеньнәр тавышларны санаганда исәпкә алынмый. Мондый бюллетеньнәр аерым төреп куела һәм аларга мөһер сугыла.”;

д) 20 өлешнең беренче җөмләсендә “таныштырганнан соң” сүзләреннән соң “тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең юлларына законда каралган номер сугуны исәпкә алып” сүзләрен, “контроль чагыштырмаларына” сүзләреннән соң “(әлеге статьяның 6 өлеше нигезендә тикшерелә торган контроль чагыштырмаларыннан тыш)” сүзләрен өстәргә;

е) 21 өлешнең дүртенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Шул рәвешле җыеп куелган бюллетеньнәр, шулай ук әлеге статьяның 11 һәм 12 өлешләре нигезендә төргәкләнгән бюллетеньнәр, төргәкләнгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеге капчыкларга яисә тартмаларга тутырыла, аларда чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы номеры, барлык төргәкләнгән бюллетеньнәрнең гомуми саны, барлык төргәкләнгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының гомуми саны күрсәтелә.”;

ж) 27 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Беркетмәнең күчермәсе күчермә алу техникасын кулланмыйча әзерләнгән очракта, беркетмәнең күчермәсендә участок комиссиясе әгъзаларының фамилияләрен, исемнәрен һәм аталарының исемнәрен күрсәтү һәм аларның имзаларын салу таләп ителми.”;

25) 50 статьяда:

а) 8 өлешкә түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: “Чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә шулай ук тиешле комиссия алган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, түбәнгерәк комиссияләргә бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, тиешле комиссия тарафыннан юкка чыгарылган файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны һәм тиешле комиссиядә югалган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны хакында күрсәткечләр кертелә.”;

б) 13 өлештә “хокуклы” сүзен “тиеш” сүзенә, “беркетмәнең 1 – 13 юлларына һәм (яисә) җыелма таблицага” сүзләрен “беркетмәнең 1 – 13 юлларына (әгәр бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү каралган булса, 11а – 11е юлларына) һәм (яисә) җыелма таблицага” сүзләренә алмаштырырга;

26) 51 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе территория комиссияләреннән алынган тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрнең беренче нөсхәләре нигезендә, бу беркетмәләрдәге күрсәткечләрне кушып берләштерү юлы белән, тавыш биргән көннән башлап 10 көннән дә соңга калмыйча, чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен билгели. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен шәхсән үзләре билгелиләр. Чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында ике нөсхәдә беркетмә һәм җыелма таблица төзелә. Чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия булган,

шунда катнашкан барлык әгъзалары имза сала. Җыелма таблицага Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе (рәис урынбасары) һәм секретаре имза сала. Чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында карар кабул итә. Чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә түбәндәге күрсәткечләр кертелә:

1) Татарстан Республикасы территориясендә территория комиссияләренең саны;

2) территория комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләре саны;

3) территория комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрендәге барлык юллар буенча кушып бирелгән күрсәткечләр.";

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ һәм $1^2$ өлешләр өстәргә:

"$1^1$. Чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә шулай ук тиешле комиссия алган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, түбәнгерәк комиссияләргә бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, тиешле комиссия тарафыннан юкка чыгарылган файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының саны һәм тиешле комиссиядә югалган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының саны хакында күрсәткечләр кертелә.

$1^2$. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан төзелә торган чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы җыелма таблицага шулай ук тиешле территория комиссиясе алган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, участок комиссияләренә бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, тиешле территория комиссиясе тарафыннан юкка чыгарылган файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны һәм тиешле территория комиссиясендә югалган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны хакындагы территория комиссиясе беркетмәсе күрсәткечләре кертелә.";

в) 9 өлештә "бюллетеньнәрне" сүзеннән соң ", бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын" сүзләрен өстәргә;

27) 54 статьяның 2 өлешендә "Сайлаулар" ДАСка кертелүче" сүзләрен "тавыш бирү йомгакларын, чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен билгеләүгә бәйле рәвештә "Сайлаулар" ДАСка кертелә торган һәм аннан алына торган" сүзләренә алмаштырырга;

28) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ нче кушымта өстәргә:

“Татарстан Республикасы
Президентын чакыртып алу
тәртибе турында” Татарстан
Республикасы Законына
1[1] нче кушымта

Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу буенча тавыш бирү

______________________________
(тавыш бирү датасы)

БҮТӘН УЧАСТОКТА ТАВЫШ БИРҮ ТАНЫКЛЫГЫ

№__________

______________________________
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең исеме) <1>
______________________________ территориясендә төзелгән
______________________________адресы буенча урнашкан __________ номерлы
(участок комиссиясе адресы) <2>

чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән

______________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

______________________________
(паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясе һәм номеры)

бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын алды һәм тавыш бирү көнендә үзе була торган чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында тавыш бирүдә катнашу хокукына ия.

______________________________
(комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә әгъзасы)

______________________________
(комиссия исеме)

__________ ______________________________
(имза) (фамилиясе һәм инициаллары)

МУ

__________ елның “___” __________
(бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын бирү датасы)

Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыдан тавыш бирү көнендә күрсәткәннән соң алына.

----------------------------
<1> Әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы җирлек территориясендә урнашса, шулай ук муниципаль район исеме күрсәтелә.
<2> Урам исеме, йорт номеры һәм торак пункт исеме күрсәтелә.

”;

29) 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы
Президентын чакыртып алу
тәртибе турында” Татарстан
Республикасы Законына
3 нче кушымта

ТАВЫШ БИРҮ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ БЕРКЕТМӘГӘ КЕРТЕЛГӘН КҮРСӘТКЕЧЛӘРНЕҢ КОНТРОЛЬ ЧАГЫШТЫРМАЛАРЫ
(ӘЛЕГЕ ЗАКОННЫҢ 48 СТАТЬЯСЫ НИГЕЗЕНДӘ НОМЕРЛАНГАН БЕРКЕТМӘ ЮЛЛАРЫ САННАР БЕЛӘН БИЛГЕЛӘНДЕ)

1) 1 зуррак яисә тигез 3 + 5 + 6;
2) 2 тигез 3 – 4 + 5 + 6 + 7 + 12 – 13;
3) 8 + 9 тигез 10 + 11;
4) 11 тигез 14 + беркетмәнең аннан соңгы бөтен юллары;
5) 11а тигез 11б + 11г + 11е (чакыртып алу буенча тавыш бирү уздырганда бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларыннан файдалану каралган очракта).”.

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 елның 18 июне
№ 45-ТРЗ